# Ильдар Юзеев

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В ПЯТИ ТОМАХ

1
**ТОМ**

Стихи

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# Илдар Юзеев

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

БИШ ТОМДА

1
**ТОМ**

Шигырьләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ю25

Р е д к о л л е г и я:

*З. Р. Вәлиева, Р. М. Миңнуллин, Ф. Г. Галимуллин, Ш.Г. Галиев, Д. С. Шакиров, Х. Г. Әюпов, Р. Х. Корбанов*

**Юзеев Илдар**

Ю25 Сайланма әсәрләр. 5 томда, 1 том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.— 383 б.

ISBN 5-298-01214-0

©Татарстан китап нәшрияты, 2002



## АЛГЫ САФТАГЫ ШАГЫЙРЬ

20 нче елларда тынгысыз Такташның әдәбиятка килүе олы вагыйга буларак кабул ителгән иде. Аның кебек үк, беренче адымнарыннан үзенә игътибарны җәлеп итәрлек шагыйрь күренгәнче, шактый озак көтәргә туры килде.

1955 елда шагыйрь Илдар Юзеевның «Таныш моңнар» поэмасы басылып чыкты. Ул шунда ук киң катлам укучылар арасында шөһрәт казанды. Чыннан да, Илдар Юзеев башка бик күп каләмдәшләреннән үзенчәлекле тавышы белән аерылып тора. Бу тавышта Такташ авазы да тоемлана. Илдар Юзеев халык шагыйренең җанга ятышлы традицияләрен остазы туктап калган ноктадан алып китте. Шул ук вакытта ул, шагыйрь буларак, Җәлил шигърияттен дә чит итмәде. Кыскасы, Илдар Юзеев турында һич тә икеләнмичә, ул — заман шигъриятенең иң матур традицияләрен үзенә туплаган бәхетле шагыйрьләрнең берсе дип әйтәсе килә. Илдар Юзеев иҗатында җылы лирика, героика һәм патетика белән үрелеп, үзенә генә хас стиль барлыкка китерә. Юзеев реализмы романтик ашкыну белән заман яшьләренең бай рухи дөньясын җырлауга юнәлгән.

Минемчә, Илдар Юзеев — без яшәгән көннәрнең көен, аһәңен тапкан шагыйрь. (Бу җәһәттән ул халыкчанлыгы, ихласлыгы, тирән моңы белән әсир иткән Илһам Шакировка бик якын.)

Аның шигырьләре, балладалары һәм поэмалары модернизм арбасына тагылган кайбер тәҗрибәсез яшь шагыйрьләргә дөрес юнәлеш табарга, поэзиядә үз юлыннан барырга һәм Тукай, Такташ, Җәлил линкорына күчәргә ярдәм итәрләр.

Әмма Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге лауреаты дигән исем шагыйрьгә гомерлеккә бирелә.

Илдар Юзеев комсомол бүләгенә тәкъдим ителгән «Миләүшә» җыентыгыннан соң, Муса Җәлил тормышыннан «Соңгы сынау» дигән гүзәл драматик легенда иҗат итте. Моның белән ул киләчәктә яңа биеклекләр яулау мөмкинлеген янә бер раслады.

Юзеев шигърияте әдәбиятыбыз Иделенә челтерәп аккан саф чишмәне хәтерләтә. Шагыйрь — олы бүләккә лаек...

***Хәсән Туфан,***
*Тукай бүләге лауреаты,*
*«Комсомолец Татарии» газетасы*
*23 октябрь, 1968*

## ЯНАР ЧӘЧӘКЛӘРНЕҢ ЯКТЫСЫ

Мин сугыштан кайткач очраткан яшь шагыйрьләрнең берсе Илдар Юзеев булды. Сугыштан соң миңа бар да сәер иде. Арча белән Әтнә арасында май аенда бәрәңге утыртып ятучыларны күреп тә гаҗәпләнеп торган идем. Сугыш иң зур вакыйга булып калган, әйтерсең шуннан башка эш, һөнәр бик кечкенә нәрсә. Бәрәңге утырту нindидер яңалык булып тоелды миңа. Мин сугышта шагыйрьлегемне дә онытa язган идем инде. Дөресен әйткәндә, дөньяга яңа туган кеше итеп сиздем үземне. Белмәгән яшь шагыйрьне очрату да миңа сәер иде. Шуның өстенә мин иске буын шагыйрьләренә күнеккән кеше. Такташлар, Туфаннар, Җәлилләр, Кутуйлар, Фатих Кәрим, Әхмәт Фәйзиләргә ияләшкән кеше. Минем күз алдымда һаман шулар әле. Барысы да исән-сау кайтыр да кабат шуларга кушылып китәрмен төсле тоела иде... Нindидер бушлык урнашты күңелдә. Менә шул вакытта «Совет әдәбияты» журналы редакциясенең ишеген кагучыларның берсе — Шәүкәт Галиев, икенчесе — Илдар Юзеев, өченчесе Хисам Камалов булды. Үзем укып чыккан педагогия институтының әдәби түгәрәге Илдарлар, Хисамнар вакытында шаулады. Аннан Илдар яшьлеккә, мәхәббәткә алып кереп киткән «Таныш моңнар» белән очраштык. Һәр шагыйрьнең поэзия дөньясына сихерләп алып кергән бер әсәре бардыр. Минем үземдә алар — «Пар ат», «Шагыйрьнең балачагы». Илдарда — «Таныш моңнар». Шуннан бирле Илдарның мәхәббәттән айныганы юк.

Илдар минем күз алдымда үскән шагыйрь дип әйтә алам. Мин аннан егерме яшькә олы. Хикмәт анда түгел. Рухы белән якын. Авылның моңнарыннан аерыла алмый газапланган кешенең хисләре анда. Яшьлеге, мәхәббәте шунда, авылда. Хәтта бераз сентименталь романтика белән өртелгән моңсулык, Такташка якынаям дигәндә генә аерылып киткән моңсулык. Ул хисләрнең дәвамы «Миләүшә»ләргә күчте. Торабара Илдар икенче шагыйрьгә әйләнде дисәм, дөрес булмастыр. Хәзер ул егермеләп поэма авторы. Егермесе егерме характерда. Темалары төрле, хисләрнең яңгырашы төрле... Яза башлап, бер-ике әсәр яки бер-ике шигырь җыентыгы чыгару белән бер урында озак таптанган шагыйрьләрне беләм. Әйбәт башлыйлар, яшьлекнең бөтен хисләрен беренче җыентыкларга салып бетерәләр дә аптырап калалар. Илдар — шигырьдән шигырьгә, поэмадан поэмага үскән шагыйрь. Җырларын поэмаларыннан, поэмаларын драматик әсәрләреннән аерып бул-

мый. Рухлары белән алар бер-берсеннән үсеп чыгалар. Барысы да ләкин Илдарча, фәкать Илдарча. Баягы фикеремә яңадан кире кайтып әйтәм: аларда бернинди кабатлану юк. Тирәнәйгәннән-тирәнәя бара Илдар. «Язылмаган поэма» романтик-патетик тонда иҗат ителсә, «Соңгы сынау» — фәлсәфи характердагы драматик легенда. «Карурман», «Таш диварлар авазы», «Өзелмәс кыллар» кебек төрле яңгыраштагы әсәрләрдән соң ул яңадан «Мәхәббәт китабы»на борылып кайта. Яшьлеккә мәңге тугры икәнен раслаган шикелле, «Яшь наратлар», «Янар чәчәк», «Кыр казлары артыннан», «Серле чәчәк» җырлары белән әйтерсең бөтен язганнарын беркетеп куйды. Юмор, кызык фикер, экспромт шигырь юлларын адым саен сибеп-чәчеп йөргән, әрәм иткән бу шагыйрьнең рухы гаҗәеп дәрәҗәдә бай. Мине сокландырган, шатландырган нәрсә шул. Чөнки бөтен хикмәт шул рухи байлыкта. Бу яктан ул бәхетле. Бик бәхетле. Шунсыз шагыйрьне күз алдына китерүе кыен.

Туфан ни өчен яратты икән Илдарны? Туфанча ягымлылык белән башыннан сыйпап сөя иде. Гадилеге, тыйнаклыгы, халыкчанлыгы өчендер, мөгаен. Поэзиягә Туфанның үзе кебек тугры. Шөһрәт, дан артыннан кумый. Тәрҗемәләре аз. Монысы, бәлки, кимчелегедер. Шулай дим дә, икенче уй килә башка. Башта бит үз халкың сынавы аша узарга кирәк. Аннан инде, ышаныч тугач, икенче халыкларга күренергәдер. Их, Илдар урынында берәү булса, ул поэмаларын күптән тәрҗемә иттереп, киң дөньяга чыгарып җибәрер иде. Талант һәркемгә дә тигез бирелми икән шул!

Илдарга әле илле генә яшь. Миңа әле бөтенләй күтелмәгән яңа әсәрләрен укырга насыйп булыр дип ышанып калам.

***Сибгат Хәким,***<br>
*Татарстанның халык шагыйре,*<br>
*Тукай бүләге лауреаты*<br>
*«Яшә, борчулы җаным!» китабыннан*<br>
*Декабрь, 1982*

## ДРАМАТУРГИЯДӘ ДӘ ШАГЫЙРЬ

...Бер талантның шигырьдә дә, драматургиядә дә бердәй эш алып баруы алай сирәк күренеш түгел. Әйтик, Маяковский, Бурнаш, Такташ, Исәнбәт, Әхмәт Фәйзи, Мостай Кәрим...

И.Юзеев — шундый талантларның берсе. Ул драматургиядә дә шагыйрь булып калган, бу ике әдәбият төрен һич тә аерып карамый торган, сәхнәне шигърият белән баеткан иҗатчыларның берсе. И.Юзеев драматургиягә килгән 60нчы ел-

ларда, хәтта аннан соңгы унъеллык башларында да театрга шигърият, ай-һай, җитми иде...

1982 елның декабрендә Мәскәүдә РСФСР Язучылар союзында татар драматургиясе турында киңәшмә уздырылды. Анда доклад белән чыккан драматургия белгече, сәнгать фәннәре докторы Владимир Фролов һәм башка театр белгечләре, тәнкыйтьчеләр И.Юзеевнең трагедия жанры өлкәсендә алып барган эзләнүләрен бик кызыклы һәм нәтиҗәле дип билгеләп үттеләр. Чыннан да, Г.Тукай турындагы «Очты дөнья читлегеннән» (1980—1981) исемле һәм М.Җәлилгә багышланган «Соңгы төн» (1972) дигән шигъри-фәлсәфи трагедияләр безнең драматургиябездә җитешмәгән, бездә генә түгел, Бөтен союз күләмендә сирәк языла торган жанрда уңыш дип саналырга хаклы...

*Азат Әхмәдуллин,*
*филология фәннәре докторы, профессор*
*«Шигъриятле драматургия» мәкаләсеннән 1983*

## ЯШЬЛЕКЛӘРНЕҢ ЯШЬТӘШЕ

Шагыйрь Илдар Юзеевның яшьлек, саф мәхәббәт бөркелеп торган романтик иҗаты — бөтен татар дөньясын хисләндергән чор минем яшүсмер елларыма — беренче мәхәббәттән иләсләнгән, шул иләслектән күңелдә шигырьләр тәлгәшләнгән көннәремә туры килде. Илдә Хрущевның яз җилләре исә башлаган чорлар. Ялтыравык-шалтыравык шигырьләрдән ялыккан яшь йөрәкләргә табигать һәм заман шундый лирик талантны бик белеп биргәндер. Баксаң, шигырьләрнең көче сәхнәгә чыгып кычкыруда гына түгел икән. Шигырьне күзең-күңелең төшкән кызга «мәктүб» язганда, кызны тәмам эретер өчен өстәп язарга да мөмкин икән әле. Ай яктысында шул кызга иң үтемле сүз шигырь икән ләбаса. Безнең буынга ягымлы лириканың шаукымы әнә шулай килеп кагыла башлады.

Ул чорда илне, әдәбиятны дер селкеткән, бөтенләй үзгәрткән-яңарткан хәл-әхвәлләрне хәзер барыбыз да бик яхшы беләбез инде. Әмма нәфислекнең, хиссиятнең күңелләр өчен никадәр тансык булуын шул шаукымлы чорны үзләре кичергән кешеләр генә тулаем беләдер, мөгаен.

Язмышым, шөкер, татар шигыре дөньясында шагыйрьнең үзе белән очраштырды.

Илдар абый туктаусыз иҗатта, һәм бу иҗат гаять тә колачлы. Дөнья классикасына аһәңдәш шигъри фаҗигаләр. Җәлилнең, Тукайның фаҗигале һәм бөек язмышларын татарны гына түгел, бүтән халыкларны да тетрәтерлек колачлы һәм фәлсәфи поэмалар-трагедияләр.

Һәм мондый яңгырашлы шагыйрьнең сәхнә әсәрләре төрки телле театр сәхнәләрендә әле дә яңгырый икән, бу һич тә гаҗәп түгел.

Поэзиядә һәм, гомумән, әдәбиятта трагедия һәм юмор бергә үрелсә, сискәндергеч әсәрләр дөньяга килә. Илдар абыйга Ходай юмор хисен дә, трагизм хисен дә мулдан биргән. Шушы ике агым бергә кушылмаса, тоташ елау һәм тоташ көлү генә торып калыр иде. Фәлсәфи акылы һәм уйнак йөрәге шагыйрьгә шул ике агымны колачлы-күләмле әсәрләрендә нәкъ кирәгенчә кушарга ярдәм итә, күрәсең. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела.

Шактый еллар инде мин — «Чаян»ның әдәбият бүлегендә. Һәм мин беләбелгәннән бирле Илдар абыйның шук каләме «Чаян»га җан өрә килә.

Гомумән, аның белән «нормально» гына сөйләшеп булмый. Шагыйрь һичтуктаусыз каламбурлар сибә, экспромт рәвешендә иҗатташларына эпиграммалар «тондыра». Кыскасы, юмор җене һаман кытыклап тора аны.

Юморга аерата балалар хирыс. Шуңа күрә дә И.Юзеевның балалар өчен язганнары «Пони малае Җирәнкәй» белән генә чикләнми. Балалар бакчалары тәрбиячеләре, мәктәпләрнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары кулында һаман сез И.Юзеев язган китапларны күрерсез.

Мин ышанам: аның иҗаты безнең яшьлек өчен нинди серле яңалык булса, яңа буыннарның яшьлеге өчен дә ул иҗат шундый ук серле яңалыктыр.

Кыскасы, яшьлекләргә яшьтәш иҗат бу... Чорның төсмере булырлык иҗат. Зур, чын иҗат кына чор төсмере була ала.

Киләчәк буын И.Юзеев поэзиясенә карап, безне — чорыбызны аңларга, күз алдына китерергә теләсә:

— Шигъри заманда яшәгән болар, билләһи! — дип уйга калыр.

Шагыйрьнең китаплары безнең хакта сөйли. Һәм сөйләячәк әле.

Кырыс, болгавыр заманга юлыктык әле бүген...

Иманым камил: чор кырысланган саен, күңелләрдә шигъ-

риятнең кадере артачак. Күңел дигәнең һәрчак җылыга мохтаҗ. Мондый дәвердә бигрәк тә. Бик тә кыен чакларыгызда, «бисмилла»гызны әйтеп, ачыгыз шигырь китабын! Җылыныгыз шигырь җылысында!

***Зөлфәт,***
*М.Җәлил һәм Г.Тукай бүләкләре лауреаты*
*18 март, 2002*



*Урам ташларыннан әкрен атлап,*
*Тоеп барам заман агышын.*
*Сыгылам да кайчак, бөгеләм дә,—*
*Төяп барам заман сагышын.*

## Җырлар бирәм

Ядкәр итеп сиңа нәрсә генә
Бүләк итим туган көнеңдә?
Болыннардан өзеп, букет тезеп,
Гөлләр бүләк итәр идем дә,
Шиңәрләр шул алар,
Чәчәкләрен
Алып китәр шаян җил генә...
Син җилләргә карап калырсың да
Онытырсың...
Кайнар яшьлегеңә ямь өстәрлек
Бирим икән сиңа ни генә?
Мә, ал, дускай,
Ямьле яшьлегебез
Истәлеге итеп карарга
Җырлар бирәм,
Ихлас җырлар бирәм,
Җил дә алмый
Һәм кырау да тими аларга.

*1951*

## Җырлап уздым урман арасын...

Чыгып киттем,
Болыннарга җиттем,
Артта борылмалы юл калды.
Зәңгәр косынкасын селки-селки,
Урман итәгендә ул калды.
Артка карадым да каерылып,
Түзәлмәдем, җырлап җибәрдем...
«Син каласың миннән аерылып,
Йә, хуш инде, җаным, чибәрем».
Туган якларымның чәчәкләре,
Ак каеннар,
                таллар,
                          тирәкләр!
Сау булыгыз,
Минем төсем итеп, сөйгәнемнең
Йөрер юлын бизәп торыгыз,
Җырлый-җырлый эшкә барган чакта,
Кара толымнарын үбегез!
Сез, шомыртлар, аның зифа буен
Ап-ак чәчәк белән төрегез,
Мине сагынып әгәр яшь тамызса,
Иркәләгез аны, сөегез!
«Сөрт яшеңне, гүзәл,
Вуз тәмамлап,
Кайтып җитәр ярың",— диегез!
...Җырлап уздым урман арасын:
«Сау бул инде, китәм... каласың.»
Зәңгәр косынкасын селки-селки,
Озатып калды
Яшьлек дустым,
                      иркәм,
                            җанашым.

*1951*

## Ә син...

Карлар ява...
Юк ла,
Җир өстенә
Шомырт чәчәкләре түгелә...
Син, Сәлимә дустым, яшьлегемнең
Яме булып кердең күңелгә.
Кыш бизәге — карлар
уйный-уйный
Иңнәреңә куна, шәлеңә...
Ә син
Үпкәләгән сыман барасың да
Елмаясың...
Карлар сине матурлыйлар гына,
Үпкәләмә, яме, Сәлимә?
Кар кызыдай булып,
Вак-вак атлап,
Киләсең син...
Керфекләрең тулган кар белән.
Нинди рәхәт
Бергә барулары
Җаның сөйгән матур яр белән.
Карлар ява,
Юк ла,
Җир өстенә
Шомырт чәчәкләре түгелә.
Әллә нигә бүген бар нәрсә дә
Миңа матур булып күренә.
Әйт, Сәлимә,
Шулай җитәкләшеп,
Таңга кадәр йөрсәк,
арыр идеңме?
Якты юллар буйлап синең белән
Гомерем буе барыр идем мин.
Ә син?..

*1952*

## Сәйдәш урамында уйлану

Исән чакта сине күрәлмәдем,
Баралмадым синең янына.
Әмма күңел, көннәр үткән саен,
Якын дустай сине сагына.
Гөлләр,
Назлы гөлләр
Язны сагынып чәчәк аталар.
Урам.
Хәсрәтләрне бик күп күргән урам
Синең исемең белән аталган.
Якын дусларыңны уйлый-уйлый,
Бу урамнан күпме үттең син?
Урамнарда гына түгел, күңелләрдә
Күпме моң калдырып киттең син.
Менә берәү җилләр исүенә
Тәрәзәсен ачып куйган да
Өзелеп-өзелеп синең көйне уйный
Чумган килеш тирән уйларга.
Юк,
Бер без генә түгел, көйләрең дә
Сагына сине — язлар җырчысын.
Салих абый,
Кабатланмас бер матурлык булып,
Син тормышны бизәп торырсың,
Ул яраткан изге Казаныбыз
Көйләреннән аның нурланган.
Менә Сәйдәш,
Безнең күңелләрдә дәрт уятып,
Марш булып уза урамнан.
Уйланалар: моңнар даһиена
Кайда һәйкәл кую турында...
Ерактагы чорлар үрендә ул,
Һәммәбезгә якын урында ул:
Халкыбызның йөрәк түрендә!

*1954—1999*

## Авторучка

*Англия делегатына*

Мин онытмам
Шушы очрашуны,
Чын дусларча куллар кысканны.
Мәгез,
Сезгә
Фестивальнең бер ядкәре итеп
Бүләк итәм авторучкамны.
Сезнең илгә баргач,
                зур көрәшнең
Сафларына бассын иде ул,
Ул татарча язды
                «Тынычлык» дип,
Инглизчә дә
«Peace» дип язсын иде ул!
Без яшь әле,
Килер елларда
Зур сынаулар булыр юлларда.
Очрашырга язсын киләчәктә,
Автоматлар түгел,
Авторучка тотып кулларга!

*1957*

## Һаман көтә

Күпме еллар инде бер урында
Искә төшереп шомлы ел турында
Гармун тора.
Телләре бар — берни сөйләми ул,
Көйләре бар — никтер көйләми ул,—
Тып-тын тора.
Соңгы тапкыр июнь, 41 дә,
Кара болыт баскан җәйге төндә
Уйналган ул.
Ялгыз калып, көннәр, еллар үткән,
Тәрәзәгә карап һаман көткән,
Моңланган ул.
Гармунчыны бик нык сагынганда,
Көмеш телләренә кагылганда —
Дерелдәп китә.
Егет тиздән кайтып җитәр кебек,
Көмеш телләр биеп китәр кебек —
Һаман көтә.

*1956*

# *Кайтмый...*

«Үз көнеңне үзең күрерсең»,— дип,
Ташлап калдырган да анасын...
Кайтмый.
Ак каеным,
Юкка гына аны юатасың
Ана аңа күкрәк сөтен биргән,
Ә ак каен
Рәнҗи-рәнҗи суын эчергән.
Ә ул
Әнисен дә,
Каенын да
Кайгы диңгезенә төшергән.
Ялгыз каен, юатырга теләп,
Тәрәзәгә иелә моңаеп,
Әйткән кебек:
Ул шук малай минем суны эчте,
Үзәгемә үтте, корытты.
Әнисен дә,
каенын да,
намусын да хәзер онытты.
...Җилләр исә,
Җилләр иссә,
Каен иелә җилләрискәндә.
Күз яшьләрен яшереп
кешеләрдән,
Ана елый исенә төшкәндә.
Ә ул кайтмый.

*1955*

* * *

Җилфердәтеп ефәк яулыгыңны,
Китеп югалдың да тауларга,
Ник килмисең тагын?
Әй, чибәр кыз,
Син йөрисең хәзер кайларда?
Киткән юлларыңда моңаешып,
Урман чәчәкләре сөйләшә:
«Син кил тагын безнең авылга,
Син ташлама безне, Миләүшә».
Күрше авыл кызын сагынам да
Менеп карыйм биек тауларга,
Миңа тагын мөмкин булыр
микән
Аның күзләренә карарга?
Җилләр исә,
Ярсып урман шаулый,
Урман шулай шаулар,
шаулар да
Тагын тынар...
Күрше авыл кызы
Тагын чыгар әле тауларга.
Биек тауга басып тыңлап торам
Карурманның шавын.
Күрше авыл кызы, әй, Миләүшә,
Ник килмисең тагын?
Кил инде...

*1952*

* * *

— Сөйгәнеңнең күзе нинди? — диеп,
Сез сорыйсыз миннән,
Белмим шул.
Айлар буе сөеп йөрим үзен,
Тик күзләрен генә күрмим шул.
Ә шагыйрьләр барлык кызларны да
Зәңгәр күзле диеп язалар.
Зәңгәр күзле кызлар барын бардыр,
Тик, минемчә, бик, бик аз алар.
Тәүге күрүдә үк сөйгәнеңнең
Күзен күреп буламыни ул?
Оялмыйча, күзем зәңгәр, дигән кебек,
Сиңа карап торамыни ул?..

*1953*

* * *

Бер яшь миләш үсә иде
Яр буенда.
Яр буенда, карт миләшнең
Куенында.
Бервакытны көзге усал
Җилләр исте
Һәм яшь миләш биек ярдан
Егылып төште.
Ята миләш, ябь-яшь башын
Суга салган,
Карт анасы аңа карап
Уйга талган.
Сыкранса да, сиздерми ул,
Яшен тыя,
Яшен тыя, яшь урынына
Миләш коя.

*1955*

## Егет күңеле далада

Туп-туры карап тордылар,—
Күзләр алдашмадылар,
Ачыктан-ачык тойдылар:
Алар аңлашмадылар.
Егет күңеле — далада,
Кыз күңеле — калада.
Әйтте кыз: «Ни ямь бар анда
Бәхетле кыз балага?»
Чибәр кыз калды калада
Бар матурлыгы белән,
Ир-егет китте далага
Бар батырлыгы белән.
«Бәхет эзләргә» килмәде,
Егет бәхетле иде,
«Үземә түгел, кешегә
Эзлим бәхетне»,— диде.
Нишлисең, кала түгел шул,
Күңелсез бераз гына.
Күңелле җырлар көйли ул,
Текәлеп буразнага.
Чибәр кыз биек үкчәле
Туфлиләр даулап йөри,
Ә егет аңа тын гына
Матурлык яулап йөри.

*1958*

* * *

Буран,
Бөтерелеп-бөтерелеп,
Сызгыра да
карлар туздыра...
Берәү дә юк.
Урам уртасында
Басып тора ялгыз кыз гына.
Ап-ак карлар аның
Ай-урактай
Кыйгач кашларына сылана,
Яңа чыккан канатлары белән
Кай якларга,
Кая очар шушы кыз бала?
Буран,
Хәбәр биргән кебек:
«Килегез сез, тиздән туй була».
Буран,
Нечкә генә билләреннән кочып,
Алып китәр кебек тоела.
Ә әнисе
Тиздән тәрәзәгә
Ят кулларның тоя чиртәсен.
Күзен мөлдерәтеп тәрәзәдән
Карап тора...
Унсигез ел сөеп баккан кызын
Буран-фәлән «урлап» китмәсен...

*1958*

## Авылым легендасы

Яз җитте исә,
Мин шунда барам,
Исәнме, болын,
Исәнме, Кәрам?
Бу — истәлекле
Мәйдан урыны.
Исем бирелгән:
Кәрам болыны.
Язылмаганнар
Рәсми карарлар,
Халык күңлендә
Яши Кәрамнар...
«Ничәнче елны
Үлде ул?» — дисәм,
Китәләр кызып:
«Исән ул, исән...
Күңелләр — сабыр,
Күңелләр — түзем.
Кайтыр ул, кайтыр,
Язын, йә көзен...
Үз сүзен жилгә
Очыра торган
Егет түгел ул,
Белдеңме, туган?»
Кайсы юллардан
Барыйм Кәрамга?
Мин булдым аны
Эзләп табарга.
Кәрам болынын
Күпме буйладым.
Күрмәдем күпме
Сабан туйларын,—
Көрәшкән чакта
Булса бер хәрам,
Әйтәләр картлар:
«Их, кайтса Кәрам...
Аның яшьлеге
Узмады әрәм...»
Эзлимен аны.
Кайда син, Кәрам?

Күзләр, күңелләр
Юлларга карый,
Еракта калган
Елларга карый.
«Сугыш!» хәбәрен
Ишеткән таңда,
Кәрам иң башлап
Ыргылды яуга.
«Көтегез безне,
Тиз кайтырбыз,— дип,—
Язын кайтмасак,
Көз кайтырбыз»,— дип.
Әйләнә турат,
Урамнар урап,
Китте юл буйлап,
Без калдык уйлап:
«Юк, дошман мондый
Ирне җиңәлмәс,
Кәрамнар булган
Илне җиңәлмәс».
Хатлар көткәндә,
Беркөнне почта
Хәбәр китерде,
Сүзләр бик кыска:
«Сугыш кырында
Сыналды Кәрам.
Ләкин... хәбәрсез
Югалды Кәрам.»
Утларга керер,
Суларга керер,
Югалмас Кәрам,
Бер кайтып килер.
Хат килә кинәт
Кәрамнан! Исән!
«Камаудан чыктык.
Дошманны кисәм».
Тагын күп айлар
Хәбәр килмәде,
Язып җибәрде
Командирлары:
«Сугышты Кәрам
Арыслан сыман,

Һәм һәлак булды
Дус, иптәш, туган...»
Өмет өзелгәч,
Шулчак үзеннән
Хат килеп төшә
Кайгы эзеннән:
«Үлгәч терелдем,
Бу точно! — дигән.—
Кайтып житәрмен
Бу кышны,— дигән.—
Туры килмәде
Хатлар язарга,—
Югалып тордым
Партизаннарда».
Ничә яз үтте,
Ничә көз үтте,
Ничә кыз көтте,
Ничә күз көтте...
Кайтмады Кәрам.
Көткән күңелләр
Сүрелми икән...
Нигә соң Кәрам
Күренми икән?
Кайтып сөйләде
Фронтташ дусты:
— Соңгы сәламен
Әйтергә кушты.
— Юкны сөйләмә,—
Аны бүләләр,—
Кәрамдай ирләр
Разве үләләр...
— Үлде кулымда
Берлин юлында.
Әмма сөйлиләр
Кәрам турында.
Сөйлиләр һаман,
Аптырап калам,
Шәһәрләр төзеп
Йөри ди Кәрам.
Ничә яз үтте,
Ничә көз үтте,—
Сугышлар бетте,—

Кайтмады Кәрам.
Әйтәләр бар да:
— Үлмәс ул батыр,
Киләсе елга,
Йә быел кайтыр.
«Ничәнче елны
Үлде ул?» — дисәм,
Китәләр кызып:
— Исән ул, исән!
Ерак йөри ул
Үлемнән, диләр.
Сабан туенда
Күренгән, диләр.
Берсе шахтада
Очраткан аны,
Кайтам, дигән, ди,
Урап дөньяны.
Берәү, бер частьта
Хезмәт иткән, ди,
Кәрам генерал
Булып киткән, ди.
...Кәрам болыны
Шау килә һаман:
— Их, Кәрам кайтса,
Кәраммы, Кәрам...
Сабантуйлардан
Эзләп карадым,
Әлегә аны
Таба алмадым.
Халык күңленнән
Эзләдем аны
Һәм шунда таптым
Эзләрен аның.
Язылмаганнар
Рәсми карарлар,
Халык күңлендә
Яши Кәрамнар.
Сезнең тарафка
Килеп кагылса,
Хәбәр итегез,
Кәрам табылса.

Ул кайта-кайта
Илендә йөри,
Илендә йөри:
Кәрам турында
Легенда йөри...
Легенда йөри...

*1963*

## Тып-тын иртә

Тып-тын иртә.
Кеше бара атлап протез аяк белән,
Гәүдәсен ул тота бары таяк белән.
Тып-тын иртә.
Йөрәкләргә төшә протез шыгырдавы,
Бу кадәре булмый хәтта теш сызлавы.
Тып-тын иртә.
Һәр шыгырдау искә төшерә таза чагын,
Шыгырдый ул, шыгырдый ул адым саен.
Тып-тын иртә.
Таяк гүя Морзе кебек хәбәр йөртә,
«Сак булыгыз дошманнардан!» — диеп үтә.

*1959*

## Васыятен эзлим Кәримнең

Васыяте, әйтер сүзе була
Сугышларда үлгән һәр ирнең.
Күңел теле шуны: иң ахыргы
Сүзен эзлим Фатих Кәримнең.
Музейларга кердем. Шунда күрдем
Пуля тишкән соры шинелен.
Шунда таптым аның безгә кайткан
Соңгы сүзен, соңгы шигырен.
Мин тапмадым анда ыңгырашу.
Васыятен инде эзләмәм:
Соңгы сүзе аның сүзсез иде,
Әмма көчле иде сүзләрдән.

*1960*

* * *

«Ялтага бар, тынычлан»,— дип әйтмә, доктор,
Авылымнан әйбәт курорт юктыр, юктыр.
Тынычлыгым — җил улаган тауларында,
Урманының, кырларының шауларында.
Бөрлегәне йөзләремә алсу бирә,
Кымызлары йөрәгемә ярсу бирә.
Хуш исләрен бөркеп тора гөлләр миңа,
Түмгәкләре кислородлы мендәр миңа.
Әче нарзан суларыннан һич ким түгел,
Чишмәләрен эчми тору мөмкин түгел.
Гөлҗимешләр һәрчак укол кадап тора,
Күкеләре пульсларны санап тора.
«Ялтага бар, дәвалан»,— дип әйтмә, доктор,
Авылымнан әйбәт курорт юктыр, юктыр...

*1961*

* * *

*Заһидулла Яруллин һәм*
*Фәрит Яруллинга*

Җитмеш яшьлек Заһидулла абзый
Тукай маршын безгә уйнады.
Рояль өстендәге рәсеменнән
Улы Фәрит аны тыңлады.
Ап-ак чәчле Заһидулла абзый
Улы рәсеменә баш иде.
Ә Фәритнең чәче кара иде,
Ул яшь иде, шундый яшь иде.
Җитмеш яшьлек абзый йөзләрендә
Әллә кайгы, әллә шатлыкмы?
Тормыш кануннары кырыс шулай,
Ни яшьлекне белми, картлыкны.
Ул баш иде улы рәсеменә,
Улы Фәрит шундый яшь иде,
Ни өчендер,
Белмим,
Ап-ак чәчле
Ата күзләрендә яшь иде.
Рәсеменнән Фәрит гел елмаеп карый.
«Кайда соң син, улым, син кайда?»
«Тирән моңнар, әткәй, шулай була:
Кайчак елый, кайчак елмая...»

*1962*

## Ертылган рәсем

Җил очыртып алып килде миңа
Бер рәсемне...
Ертып ташланган.
Сагыну, яратулар ташып тора
Уйчан күзләр, куе кашлардан.
Мин очратмам сине, гүзәл кызый,
Моңсу егет, сине күрәлмам,
Сезне мәңге аермаслык итеп,
Сөю җыры язып бирәлмам.
Бик еш шулай тормыш иртәсендә
Яшьлек белән яшьлек хушлаша.
Мәхәббәтнең кадерен белмисең шул,
Үз сөюең җилдәй очмаса.
Рәсемнәрне тагын табып була,
Рәсемнәргә еллар кагылмый,
Кире килеп кабат эзләсәң дә,
Иң беренче сөю табылмый...

*1960*

# Светлана

Озак еллардан соң, тынып калган
Иске тегермәнгә туктадым,
Тик, көтсәм дә, гүзәл Светлана,
Син атылып килеп чыкмадың.
Бар җир йоклый. Таулар, елгаларга
Синең көлүең җитмидер кебек,
Бездән соңгы килгән бала чаклар
Алай шаулап үтмидер кебек.
...Яңа калкып чыккан чәчәкләрдән
Башлап такыялар үрә идең,
Яз җиткәнен хәбәр иткән кебек,
Яланаяк йөгереп килә идең.
Тегермәнче кызы Светлана
Атылып киткән җитез ук иде,
Ул йөрмәгән урман, ул менмәгән агач,
Ул шумаган таулар юк иде.
Малайларны алып китәр иде
Серле урманнардан юл ярып,
Поезд юлларына җитәр иде,
Калмас иде юлда ул арып.
Поездларны озатып калыр иде
Борылмалы юллар чатыннан...
...Күп тормады, аннан үзе китте
Ерак хыяллары артыннан.
Җитен чәчләреңнең җилфердәвен
Күрә алмам инде кайда да,
Тегермәнче кызы Светлана
Тимер юллар сала тайгада.
...Бер тавыш юк.
Оеп, йокымсырап,
Нидер көтә иске тегермән.
Тик ул килми,
Яз киләсен хәбәр иткән кебек,
Еракларга чыгып йөгергән...

*1963*

* * *

Сандугачлар сайраталар иде
Гармун каешларында,
Икесе дә яуда ятып калды,
Берсе — кояш чыгышында,
Берсе — баешларында.
Ана
        поездларны озатып кала
        талга сөялеп.
Яшь солдатлар китә төялеп,
Берсе — кояш чыгышына,
Берсе — баешларына.
Кошлар куна гармун каешларына.
Эшелоннар уза,
Сыгылып-сыгылып кала карт таллар,
Гармун күрүкләре кебек
Сузылып-сызылып кала шпаллар.
...Ананың ике улы
Җирнең ике ягында ята,
Кояш берсеннән чыга,
Икенчесендә — бата...

*1964*

* * *

Күңелем минем — чиксез кара урман:
шаулый, тына,
үрли, сына,
сайрый, көлә,
туа, үлә.
Күңелем минем — чиксез кара урман:
эзли, таба,
күккә аша,
сөя, шаша,
ыңгыраша.
Күңелем минем — чиксез кара урман:
өмет өзәр,
түзәр, чыдар.
Тик кояшлы
юлга чыгар.

*1966*

## Илһам килгәндә һәм киткәндә

Үтенәм, китегез ялгызым калдырып,
Кулларым каләмгә үрелә.
Алдымда беркем дә белмәгән,
Тоймаган Матурлык күренә.
Үтенәм, китегез ялгызым калдырып,
Нур тама каләмем очыннан.
Күңелемнән аккошлар очырам,
Шашынам, тилерәм, очынам.
Үтенәм, китегез ялгызым калдырып,
Мин — күкнең җиденче катында,
Бу мәлдә кирәкми берсе дә:
Сөйгән яр, дусларым, алтын да.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күңел буш. Эч поша. Мин йөрим
Үләрдәй моңаеп, каңгырып.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үтенәм, китмәгез ялгызым калдырып...

*1966*

# Мин сине нигә яратам?

*Кызга егет җавабы*

Мин сине яратам,
Үзем дә белмим ни өчен.
Әллә борын очындагы
Бәләкәй генә миң өчен?
Мин сине яратам:
Үзәккә үтүләрең өчен,
«Кит аннан, мәхәббәтсез»,— дип
Ташлап китүләрең өчен.
Мин сине яратам:
Кабат кайтуларың өчен,
«Мәңге, мәңге үптермим»,— дип
Саргайтуларың өчен.
Мин сине яратам:
Кулга иялəшмәүләрең өчен,
Ялгыш бер кызга карасам,
Сөйләшмәүләрең өчен.
Мин сине яратам:
Шулай ялындыруларың өчен,
Бер кыз миңа караса,
Борын салындыруларың өчен.
Кагылыйм дисәң, «каравыл!»
Кычкыруларың өчен,
Тоттым дигәндә кулымнан
Ычкынуларың өчен,
Мин сине яратам:
Усал, үтереп карауларың өчен,
Бездән үткен керфегеңне
Йөрәккә кадауларың өчен,
Мине өзелеп яратып та,
Шуны сиздермәвең өчен,
Әнә шул сиздермәвең белән
Мине биздермәвең өчен.
Күпме мине газапладың —
Ни ачуым, ни үчем...
Мин сине яратам. Ни өчен?
Үзем дә белмим ни өчен!

*1967*

* * *

Һәрнәрсәгә карыйм исем китеп:
Алтын көзгә,
Ачык йөзгә,
Бөдрә тупылга,
Көләч Айга,
Шаян тайга,
Йөгерек дулкын,
    Һәрнәрсәгә карыйм исем китеп,
    Тәүге тапкыр күргәндәй итеп.
Һәрнәрсәгә карыйм исем китеп:
Сулган гөлгә,
Сүнгән көлгә,
Моңсу таңнарга,
Үкси-үкси,
Яулык селкеп
Калган ярларга,—
    Һәрнәрсәгә карыйм исем китеп,
    Соңгы тапкыр күргәндәй итеп.

Җиргә яңа туган сабый мин
Һәм сугышта үлгән абый мин.

*1967*

* * *

Әйтегез:
җан нидән яралган?
Давылдан?
Болыттан?
Яшеннән?
Ләйсәннән?
Ташкыннан?
Дулкыннан?
Әйтегез:
җан нидән яралган?
Уттанмы?
Бozданмы?
Таштанмы?
Кылданмы?
Алмаздан?
Бәллүрдән?
Әйтегез:
җан нидән яралган?
Мәхәббәт?
Нәфрәттән?
Шатлыктан?
Хәсрәттән?
Ачыдан?
Татлыдан?
Әйтегез:
җан нидән яралган?
Сагыштан?
Тавыштан?
Аһәңнән?
Нәкыштән?
Хистәнме?
Төстәнме?
Әйтегез, җан нидән яралган?
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Яфрактай кечкенә бер йөрәк
Җирнең мең сыйфатын алалган.

*1964*

# Табыну

Ерак бабаларым — мәҗүсиләр.
Табынганнар:
атка,
сыерга,
утка,
Кояшка,
Айга,
йолдызларга...
Тарих җиле искән, суы аккан...
Ат — буйсынган кешегә,
Сыер — буйсынган кешегә,
Ут — буйсынган кешегә,
Су — буйсынган кешегә...
Мин ышанам заман тизлегенә,
Буйсынучы тагын табылыр.
Тик барыбер кеше бала чагын —
Атка табынуын сагыныр.

*1965*

## Юк, мин яши алмыйм алай...

Юк, мин яши алмыйм алай:
Әзер утлар табып,
Җил кай якка иссә,
Шунда таба авып.
Юк, мин яши алмыйм алай:
Мичкә арка терәп,
Кеше яккан утта
Кызынырга теләп.
    Үзем утлар ягам,
    Үзем дөрлим, янам...
    Үзем булып яшим,
    Үзем булып калам.
Юк, мин яши алмыйм алай:
Хәрәкәтсез ятып,
Ялган Алла ясап,
Сүзгә үрә катып.
Юк, мин яши алмыйм алай:
Көчлегә баш орып,
Язмыш колы булып,
Җирнең үксез улы булып.
    Яши алмыйм — Күксез,
    Яши алмыйм — Җирсез.
    Юк, мин китмәм Җирдән,—
    Дөнья нишләр минсез?!

*1970*

# Борчыну

Әрсез дигән атым таралмаган,
Тик аласын алдым.
Ни алдым:
    Күктән — нурлар,
    Җирдән — тәмнәр,
    Табигатьтән моң алдым,
    Каеннан — су,
    Таңнардан — чык,
    Кыңгыраудан чың алдым,
    Әнкәемнән — якты дөнья,
    Еллардан — көз, яз алдым,
    Көздән — байлык,
    Яздан — чәчәк,
    Сөйгәнемнән наз алдым...
Туктаусыз алдым-алдым да
Мин кинәт уйга калдым,—
Борчу сискәндерде күңелне:
    Җир — картайган,
    Су — азайган,
Әнкәм — хәлсезләнгән түгелме?
Әрсез дигән атым чыкмаса да,
Әрсезләнгән ул мин түгелме?

*1972*

## Уфтану

Язлар килә, язлар китә,—
мин калам,
Җәйләр килә, җәйләр китә,—
мин калам,
Көзләр килә, көзләр китә,—
мин калам,
Кышлар килә, кышлар китә,—
мин калам...
Мин калам.
Мәңгелеккә карыйм да мин тын калам.
Аһ, табигать, мин бит синең бер балаң...
Тын калам да авыр сулап уфтанам:
Язлар килер, язлар китәр,—
мин булмам,
Җәйләр килер, җәйләр китәр,—
мин булмам,
Көзләр килер, көзләр китәр,—
мин булмам,
Кышлар килер, кышлар китәр,—
мин булмам...

Аһ, табигать, мин бит синең бер балаң,
Шулай укмы эзсез китеп югалам?..

*1972*

# Шом

Нишләр идем, әгәр:
Халкым бәла-каза кичергәндә,
Үз рәхәтем белән чикләнсәм,
Илем йөзен бәйрәм бизәгәндә,
Үз кайгыма кереп бикләнсәм...
Нишләр идем, әгәр:
Эшем өчен түгел, дәрәҗәле
Постым өчен генә макталсам,
Авыр чакта дусларымны сатып,
«Чоры шулай» диеп аклансам...
Нишләр идем, әгәр:
Толлар-ятимнәргә күзне йомып,
Үзем өчен сарай салдырсам,
Үземнән соң якты рух калдырмый,
Җир йөзендә тик мал калдырсам...
Нишләр идем, әгәр:
Үзем кичермәслек гөнаһ кылып,
Гомерем буе яшереп сакласам,
Мине өнәмәгән вак җаннарның
Яшерен өметләрен акласам...
Нишләр идем...

Ә кемнәрдер шулай тын яши,—
Күңелемдә минем шом яши.

*1971*

* * *

Мәхәббәт, нишләттең син мине?..
Хисләрне яңарттың,
Йолдызга караттың,
Күңелне — бай иттең,
Телемне — бал иттең,
Зиһенне чуалттың,
Биеттең, елаттың,
Өемне — гөл иттең,
Кем идем, кем иттең,
Төнемне — көн иттең,
Көнемне — төн иттең,
Яндырдың — көл иттең...
Нишләттең син мине, мәхәббәт?
Тилерттең, шаштырдың,
Күкләргә аштырдың,
Сагышлар уяттың,
Наз гына оялттың,
Кабыздың, сүндердең,
Тыңлаттың, күндердең.
Чәчәкләр өздердең,
Сагынгач түздердең,
Ялгызым калдырдың,
Татлы яшь тамдырдың,
Күңелне нечкәрттең...
Мәхәббәт, син мине нишләттең?..

*1971*

## Ни ясар тимерче?

Кайгыдан, шатлыктан,
Арудан бушанып,
Изрәгән бар тараф,
Ал таңга ышанып.
Йокламый тимерче,
Ут-күмер дөрләтә,
Гүя ул сабыйның
Бишеген тирбәтә:
Куллары — күрүктә,
Учакта — тимере,
Янамы күмере,
Янамы гомере?..
Ал да сал сандалга,—
Ут шары өлгергән,
Тик менә тимерче...
Ни ясар тимердән:
Куянга — читлекме?
Балыкка — кармакмы?
Табутка — кадакмы?
Бүрегә — тозакмы?
Зинданга — йозакмы?
Ни ясар тимерче:
Атларга тышаумы,
Азатлык сөюче
Муенына кыршаумы?
Нәниләр сөенеп
Атыныр таганмы?
Сабаннан кылычмы?
Кылычтан сабанмы?
Шатлыкмы, хәсрәтме?..
Ут шары өлгергән...
Көтә Җир-алачык:
Ни ясар тимерче,
Ни ясар тимердән?

*1971*

## Бер сүз

Уйламыйча дустым бер сүз әйтте:
Ул сүз йөрәгемә кадалды.
Үзе берни белми китеп барды.
Ә сүз калды.
Ул сүз тора минем йөрәгемдә
(Аннан авыр яра юк сыман).
Җәясеннән ялгыш атылып киткән
Һәм дустына тигән ук сыман.

*1972*

* * *

Шушы урамнардан атлап киттем,
Шушы урманнарда атлар көттем,—
Юк, онытмадым.
Сине ташламаска антлар иттем,
Ә беркөнне ерак чыгып киттем,—
Юк, онытмадым.
Хәзер җырчы булып кайтып киләм,
Танымас дип, уйга батып киләм,—
Юк, онытмаган.
Җырым миннән алда кайтып кергән,
Авылдашка сердәш булып йөргән,—
Юк, онытмаган.

*1972*

## *Бәрәңге чәчәге**

Исми җил, үсми гөл,
Кая ул яшеллек...
Көтмә дә яңгырны,
Күкрәүне, яшенне.
Күзгә дә күренмәс
Иң тыйнак бер чәчәк
Беренче көнне үк
Төшеңә керәчәк.
Бәрәңге чәчәге —
Хыялда тирбәлә.
Күз яше аркылы
Әйталмый ир бала...
Сызыла күңелең,
Тойгыңны тый, яшер.
Бәрәңге чәчәге,
Туган җир, өй, нәсел...
Бәрәңге чәчәге
Сарылы, ак, көрән,
Далада юксынып,
Багларга мин керәм...
...Янында чагында
Без сине күрмибез,
Тантана-бәйрәмгә
Күтәреп йөрмибез.
Мактану, шау-шудан
Ераксың, димәк, син,
Тормышта бик кирәк,
Бик кирәк бизәк син.
Туган өй нигезен
Балкытып ул чәчәк
Еракка киткәч үк
Төшеңә керәчәк.

*1970*

* Фирзәр Мортазин көе

* * *

Аннан бирле күпме печән үсте,
Яшел җәйләр узды, ак кышлар.
Нигә, нигә хәтеремнән китми
Җыелмыйча калган покослар?
Яшь ирләрнең чалгы янаулары
Йөрәгемә уелып калдылар.
Киленнәрнең яшьлек чәчәкләре
Атар-атмас коелып калдылар.
Чалгы тоткан куллар мылтык алды,
Печән чапты япь-яшь киленнәр.
Ир бәхетен күрә алмадым дип,
Пышылдады кайнар иреннәр.
...Картаела, ахры, туган якка
Кайтып килүләрне ешайттым,
Печән чапкан ыспай егетләрне
Мәрхүм этиләренә охшаттым.
Яшь ирләрнең чалгы янаулары
Йөрәкләрдә уелып калмасмы?
Киленнәрнең яшьлек чәчәкләре
Атар-атмас коелып калмасмы?..

*1971*

* * *

— Хушыгыз! Мин китәм еракка!
Хушыгыз!
Ишетелде бер аваз колакка:
— Хушыгыз!
— Мин китәм кайтмаска, озакка.
Хушыгыз!
Яфраклар пышылдый колакка:
— Хушыгыз!
Анда да мондагы шикелле
Каеннар, чишмәләр табылыр...
Хушыгыз!
— Картайгач, күңелең сагыныр,
Хушыгыз!
— Мин китәм бөтенләй кайтмаска!
Хушыгыз!
Тау-ташлар, диварлар әйттеләр:
— Кайтырсың...
— Юк, кайтмам!
— Сугышта үлгәннәр кайттылар,
Йә туфрак, йә ядкәр-таш булып.
— Юк, кайтмам!
— Галәмдә үлгәннәр кайттылар
Көл булып,
метеор шикелле ашкынып.
— Мин кайтмам, түзәрмен!
Бар тарту көчләрен өзәрмен.
Туган як җилләре тәкрарлый колакка:
— Аңларсың киткәчтен еракка...
Бабайлар туфрагы тартыр ул,
тартыр ул,
Ни белсен яшь бала... Рәнҗемик.
Барыбер кайтыр ул,
кайтыр ул...

*1972*

* * *

Балалыкка кире кайтыйм әле,
Кире кайтыйм әле тагын бер.
Туфлиләрне салып, тыкрыклардан
Яланаяк чабып карыйм бер...
Эшләпәмне җилгә очырыйм да,
Костюмымны элеп куйыйм да,
Яшел түмгәкләргә башны салып
Ятыйм әле Гәрә буенда.
Шагыйрь халкы шулай була инде,
Хыялланган икән, дисеннәр,
Теләсә нәрсә, әйдә, сөйләсеннәр,
Тик, картайган икән, димәсеннәр...
Шикләнмәгез миннән, авылдашлар,
Зыян итәр өчен кайтмадым,
Кызык өчен, сорамыйча гына
Чәлдеримче колхоз шалканын.
Кич клубта кино була икән,
Билет алмый гына карыйм бер,
Тик, кызганыч, гәүдәм калынайган,
Тәрәзәдән сыймам барыбер.
Түбән очтан кайтып керимче бер
Урам тутырып елап, кыйналып,
Кайгыларга батып йөримче бер,
Кызлар сөйгән булып кыланып...

*1971*

* * *

Иптәшләре шелтә бирделәр дә
Оныттылар.
Ә ул...
Түзсәң түз.
Эштә,
Өндә,
Төштә
Вөҗдан белән калды күзгә-күз.
Дус-ишләр дә аны аңладылар,
Кызгандылар,
Ә ул...
Әллә ни
Булды йөрәгенә.
Үз хуҗасын үзе җәлләми.
Акылы да шелтәләүдән тынды.
Бәхилләде, искә төшерми.
Тиле яшьлек кылган бер хатаны
Тик йөрәге,
Тик йөрәге мәңге кичерми.
Төзәтер өчен кире китәр иде...
Яшьлегенә кем соң кайтала?!
...Ул бары тик улына васыять итеп:
«Кабатлама!» — диеп әйтала.

*1972*

* * *

Үз-үзеңне эзләп табыйм диеп,
Айлар-еллар үтә.
Үз-үзеңне югалтырга
Бер минут та җитә.
Ычкындырсаң шул мизгелне —
Бар гомерең газап.
Үз-үзенә турылыклы шәхес —
Мәгърур, көчле, азат.

*1973*

# Канкай углы Бәхтияр*

*Легенда*

Исте җилләр, сулар актылар,
Кама буйларында якты яр.
Оныкларның нурлы йөзләрендә
Бәхтиярдан төшкән якты бар.

Тып-тып тояк тавышын
Тыңлап үскән баладыр,
Урал-тауның сагышын
Җырлап үскән баладыр,
Акбүз атта барадыр
Канкай углы Бәхтияр.

Каракошны атарга
Җәя белән ук алган,
Пайтәхетне ватарга
Ядрә белән туп алган,
Яу ияртеп кузгалган
Канкай углы Бәхтияр.

Юллар бергә килгәнгә,
Ике батыр дус булган,
«Уң кулым син» дигәнгә,
Күңелләре хуш булган,
Пугачауга кушылган
Канкай углы Бәхтияр.

Утлы кылыч уйнатып,
Ярсу акбүз атында,
Килә Кама буйлатып,—
Мең гаскәре артында,
Бәхет инде якында,
Канкай углы Бәхтияр.

* Бәхтияр Канкаев — 1773 — 1775 еллардагы крестьян сугышында күренекле полководец, Пугачев полковнигы.
М.Яруллин музыкасы.

Патша тәмам шүрләгән,
Ике йөз дә кырык көн,
Ике йөз дә кырык төн
Йокы заты күрмәгән, —
Тәхетенә үрләгән
    Канкай углы Бәхтияр.

Иксез-чиксез каракош
Ябырыла Камага,
Ава агач, ава таш,
Елга булып кан ага,
Гаскәрләрең камала,
    Канкай углы Бәхтияр.

Патшаның эше ходта:
Тәхеткә юллары юк,
Пугачау — эшафотта —
Сулышы, тыннары юк,—
Башы һәм куллары юк,
    Канкай углы Бәхтияр.

Төшкәндә эшафоттан
Җәллад нигә борчулы?
Сөенергә ашыккан...
Пугачауның ун кулы —
Исән кала уң кулы —
    Канкай углы Бәхтияр.

Тып-тып тояк тавышы
Тынгы бирми бер көн дә,
Чыгарылган хөкем дә,
Тотып бирми беркем дә,
Йөри халкы иркендә
    Канкай углы Бәхтияр.

Үзен һәм акбүз атын
Мең шымчы да тапмаган.
Тотучыга — мең алтын,
Әмма һичкем сатмаган,
Бәхет булып сау калган
    Канкай углы Бәхтияр.

Үчлеләр — Идел кичәр —
Сулышы, тыннары бар.
Йоклый алмый башкисәр:
Бәхеткә юллары бар,
Пугачау кууллары бар —
    Канкай углы Бәхтияр.

Тып-тып тояк тавышын
Челдерәтеп барадыр,
Морадына җитмичә
Тынмый торган баладыр,
Сынмый торган баһадир
    Канкай углы Бәхтияр.

Сүндерелгән ут-ялкын
Төтенсез көйрәр әле.
Сарайга борып атын,
Йодрыгын төйнәр әле,
Бәхет башкисәрләрен
Тәхеттән сөйрәр әле
Пугачауның уң кулы —
    Канкай углы Бәхтияр.

*1971*

* * *

Үз дәрәҗәсен
Белгән җаныма
Нигә дәрәҗә, нигә соң даннар?
Аңламасалар
Аңламасыннар
Аңламас җаннар.
    Үз намусына
    Тугры җаныма
    Нигә килешү, алдау-ялганнар?
    Аңламасалар
    Аңламасыннар
    Аңламас җаннар.
Үз иманына
Тугры җаныма
Тик дуслар керер, белсен дошманнар.
Аңламасалар
Аңламасыннар
Аңламас җаннар.
    Үз максатына
    Тугры җаннарга,
    Юк, җиңел түгел төннәр һәм таңнар...
    Аңламасалар
    Аңламасыннар
    Аңламас җаннар.

*1974*

## Калдыр, аккош, каурыеңны...

Калдыр, аккош, каурыеңны,
Кояш нурына маныйм,
Күңел җылысын салыйм да
Хисләрдән утлар ягыйм.

Калдыр, аккош, каурыеңны,
Мин аны изге саныйм,
Аккоштай саф ак кәгазьгә
Җылы хис булып тамыйм.

Ак кышларны яндырырлык
Учаклар булып яныйм,
Аккошларны калдырырлык
Утлы җыр булып тамыйм,—
Калдыр, аккош, каурыеңны...

*1973*

## Шагыйрь Мөхәммәдьяр

XVI гасыр шагыйре Мөхәммәдьяр — хан каберендә мөҗавир (кабер сакчысы) булып хезмәт иткән.

Чәчәннәрнең хәлен сора чәчәннән,
Хак сүз әйтеп күпме гомер яшәлгән...
Язмышымны бер чәчән дә күрмәсен,
Каберлектә саклыйм ханның төрбәсен.
Яшәештә кадерләр юк хак сүзгә,
Күпме чәчән җиһан кичте хаксызга,
Күпмеләре эзсез гаип булдылар,
Сүзкәйләрен әйтә алмый тындылар.
Күпләренең ядлар өчен кабере юк,
Күпләренең саклар өчен кабере юк.
Падишаһның кабере зират үрендә,
Чәчәннәрнең сүзе йөрәк түрендә.
Мөхәммәдьяр мин, мөҗавир кабердә,
Чәчәннәрнең рухын саклыйм бәгырьдә.

*1973*

# Шагыйрьләр нигә картаймый?

Шагыйрьләр нигә картаймый?
Дөнья уе — башында.
Асыл кошлар затыннан ул,
Сандугачлар яшендә.

Болай да кыска гомерне
Мәгънәле итәсе бар.
Юлчы булып, дөнья буйлап,
Сәфәрләр китәсе бар.

Тормыш дигән әкиятнең
Йомгагын сүтәсе бар.
Фатир сорап күңелләргә
Тәрәзә чиртәсе бар.

Картаеп сүнгән йөрәкнең
Бозларын эртәсе бар.
Үксезләрнең күзләреннән
Яшьләрен сөртәсе бар.

Гашыйкларны кавыштырып,
Туенда биисе бар.
Сабыйларның бишекләрен
Тирбәтеп йөрисе бар.

Сандугач киткән күңелгә
Оялап сайрыйсы бар.
Дошман йөрәген тишәрлек
Хәнҗәр-сүз сайлыйсы бар.

Юлда адашып калганга
Маяклар тезәсе бар.
Үзеңне адаштырсалар,
Бирешми түзәсе бар.

Халык кайгырганда — елый,
Көлгәндә — көләсе бар.
Ил булып утка керәсе,
Ир булып үләсе бар.

Оясы юк, мөлкәте юк,
Каләме, биштәре бар.
Куңелләрне тетрәтерлек
Җырлары-хисләре бар.

*1973*

* * *

Атлап киләм
йомшак кына басып
яфрак-келәмгә.
«Алтын көз»...
Ә ник алтын?
Мин чагыштырмыйм
берни белән дә.
«Яфрак-тәңкә»...
Ә ник тәңкә?
Мин чагыштырмыйм
берни белән дә.
Атлап киләм,
йомшак кына басып,
яфрак-келәмгә...
Ник алтын?
Ник тәңкә?
Юк!
Мин чагыштырмыйм
　　　берни белән дә,—
Дөнья базарында
мин бу көзне
алыштырмыйм
　　　берни белән дә!
　　　Берни белән дә!
Атлап киләм,
йомшак кына басып,
яфрак-келәмгә.

*1974*

## Гармунсыз авыл

Авылларда йөрим. Кем генә юк...
Бар моңлысы шунда... бар моңсыз.
Моңсыз авыл җирдә булмаса да,
Мин бер авыл күрдем гармунсыз.
Бар тирә — тын... Яшьлек — чәчәкләрен
Вакыты җитми йомган шикелле.
Нидер җитми җанга... Авыл йоклый...
Сандугачсыз урман шикелле.

*1977*

* * *

Акчарлакның туган җире — диңгез...
Яши шунда, авыр булса да,
Оча торгач куна дулкыннарга,
Күз ачкысыз давыл булса да.
Өзелеп-өзелеп нигә кычкырасыз,
Җирсез яшәү авыр — шуңамы?
Соңгы тапкыр кайда төшәсез сез,
Әллә җиргә, әллә сугамы?
Акчарлакның туган җире — диңгез...

*1977*

* * *

Күнеккәнбез:
һәр иртәне
Кояш калка да бата,
калка да бата,
китә дә кайта,
китә дә кайта...

Әйтик:
бердәнбер көнне
Кояш кире кайтмаса?
Чулпан калкып, таң атмаса?
Кошлар сайрап уятмаса?
Шәфәкъ нурында җемелдәп,
агымсулар акмаса?
Җир йөзен,
бар Галәмне
караңгылык капласа?
Җан иясе бу дәһшәттән
чыгу юлын тапмаса?..
Бердәнбер көнне
Кояш кайтмаса?
Кеше нишләр иде?
Ул,
күкрәгеннән изге нурлар алып,
күккә ашар иде,
Кояш ясар иде.
Караңгылык мәңгегә
кайтмаска качар иде.
Бердәнбер көнне
Кояш кайтмаса?
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бу бары тик куркыныч бер уй гына.

Кояш калкыр да батар,
батар да калкыр,
мәңге нур чәчәр!
Ә менә Кеше күңелендә Кояш батса —
Җир ничек яшәр?!

*1975*

* * *

Икеләнми киттек сезнең арттан,
Басып әзер эзгә.
Фатихагыз һаман күңелебездә,
Аксакаллар,
Рәхмәт инде сезгә!
Ә без хәзер мөстәкыйльләр инде,
Сездән бераз үзгә,
Сез дигәнчә уйламасак әгәр,
Аксакаллар,
Рәнҗемәгез безгә,
Хакыйкатьне ярып салсак әгәр
Туры карап күзгә.
Сез үзегез безне өйрәттегез,
Аксакаллар,
Гадел, тугры сүзгә,
Рәхмәт сезгә!

*1976*

# Унөченче

*Баллада*

Егетләр унике булганнар,
Аяусыз үлемгә барганда.
«Юк, унөч, унөч!» дип кабатлый
Күңелем һаман да.

Унөченче...
Ул булган егетләр янында
Иң соңгы йөзенче адымда,
Башларын югары күтәрткән
Һәлакәт алдында.

Дөньяның килерен хәл итеп
Булмыйдыр тәвәккәл ир-атсыз,
Һәрберсе белән дә үлемгә
Кергән ул чиратсыз.
Бер булып киткәннәр егетләр,
Сайларга бер генә юл калган.
Унөченче...
Ул калган
Һәм китеп... хәбәрсез югалган.

Унөченче...
Ничә ай, ничә ел эзлим мин,
Табалмыйм, җанда — бер үкенеч,
Әйтәләр: «Алар бит унике!»
«Юк, унөч!»
«Юк, унөч!»

Унөченче...
Җәлладның балтасы астыннан
Бердәнбер сау калган каһарман...
Мин беләм, ул — исән, табармын,
Ә, бәлки, табалмам...

Унөченче...
Иң көчле дошманны җиңдем дип,
Җай саен кычкырмый торгандыр,

Ул тыйнак, дуслары сымандыр,—
Табалмый шуңадыр.
Баһадир икәнен белмичә,
Тын гына, шау-шулар эчендә
Янадыр, көядер, сөядер
Дуслары өчен дә.

Унөченче...
Ул калган
Һәм китеп... хәбәрсез югалган.

Иң соңгы йөзенче адымда
Мусалар җырлаган моңлы җыр...
Моңлы җыр — билгесез каһарман.
Мин беләм: син исән, табармын.
Ә, бәлки, табалмам...

*1978*

# Бакчачы турында баллада

Кайчандыр бу урын
Каргалган җир булган,
Таш атып, ут чәчеп
Тетрәгән, убылган.
Язгы кар сулары
Челтерәп акмаган,
Узучы кошлар да
Кунар җир тапмаган.
Көннәрдән бер көнне
Бакчачы карт килде,
Иелде, көрәге
Ташларга төртелде.
Ул — җиргә беректе,—
Имәндәй — тамыр нык...
Ташларны йомшартты
Чыдамлык, сабырлык.
Күрделәр: бакчачы
Куллары килеште —
Җил исте, тир тамган
Ташларда гөл үсте.
Челтери-челтери,
Вак ташлар аркылы,
Гөлләрне иркәләп,
Акты су салкыны.
Канатлы җырчылар
Төшәр җир сайлады,
Тирәктә, сөенеп,
Былбыллар сайрады.
Матурлык тудырган
Бакчачы хакында
Сөйләде барчасы
Еракта, якында.
...Чү, ни бу? Әллә соң
Күзенә күренә?
Гөлләргә, тирәккә
Еланнар үрелә.
Шаштыра аларны
Өстәге былбыллар,
Богаулый тирәкне
Еланнар-чылбырлар.

Хак сүзме? Ишетә
Ул күрше картыннан:
«Еланнар киләләр
Былбыллар артыннан.
Тынычлап калырсың
Агулы дошманнан,
Бары тик котылсаң
Әнә шул кошлардан».
...Читлекләр куеп, ул
Кошларны аулады,
Бер генә былбыл да
Бакчада калмады.
Тындылар былбыллар,
Киттеләр еланнар,
Тынычлап яшәгез
Инде сез, оланнар!
...Акылы: «Дөрес!» — ди,
Ә йөрәк ник боек?
Ник сулган кош кунып
Тибрәнгән төнбоек?
Шауламый тал-тирәк,
Исми җил, тын — гөлләр,
Назламый сөмбелләр,
Сайрамый былбыллар.
Төзәлмәс бер яра
Ник әрни йөрәктә?
Җырламас шул инде
Ул кошлар тирәктә...
Килсә дә бакчага
Яңа яшь былбыллар,
Юк булган былбыллар
Шикелле кем җырлар?
Тигезсез көрәштә
Ул һәлак булсачы...
Кабере өстенә
Шул кошлар кунсачы...
Тирәндә-тирәндә
Хәсрәте, сагышы,
Арттыра газабын
Былбыллар тавышы.
Төзәтер иде ул
Шул еллар ялгышын,

Үзгәртер иде ул
Былбыллар язмышын...
Сүреләдан жыры
Алсу таң нурында
Таштагөл үстергән
Бакчачы турында.
Сүреләдан жыры,
Еракта, якында
Тирбәлә җан жыры
Былбыллар хакында...

*1978*

## Моң турында баллада

Ник йөрергә табигатьтә —
Урманда,
Базарыңда бар да әзер
Булганда?
Утыр да оч: үз кулыңда
Машинаң,
Бар табигать — алларыңда
Баш игән.
Ал, рәхим ит, җиләкләре
Эреләр,
Җимешләре — иренеңдә
Эрерләр.
Бик теләсәң — утыр каен
Төбендә,
Балык дисәң — аквариум
Түреңдә
Авыз ит син, йөрмә карап,
Узгалап:
Балтырганмы? Каз тәпие?
Кузгалак?
Төп теләге булмаса да
Баюда,
Кызык өчен бии монда
Аю да...
«Алыгыз!» дип әйтмәсә дә,
Бер читтә,
Сап-сары бер кошчык сайрый
Читлектә.
Өзелергә үсмәсә дә
Болында,
Ак ландышлар — чибәр кызның
Кулында.
Кыш кирәкме? Җәен — боз да,
Кар да бар,
Ни теләсәң, ни сорасаң —
Бар да бар.
Кайный базар — машиналар
Тезелгән,
Бар да әзер — табигатьтән
Өзелгән.

Сайлый базар, күңелле дә,
Түгел дә,
Базар халкы бары тик бер
Шөгыльдә:
Сата-ала, башкасында
Гаме юк,
Ә дөньяның — гамьнән башка
Яме юк.
Табигать бит теләмичә
Күченгән...
...Шулчак базар шау-шулары
Эченнән
Ишетелде серле бер көй
Колакка,
Әллә якын, әллә инде
Еракта.
Базар күптән күрмәгәндер
Тынлыкны,
Барча халык төп шөгылен
Онытты.
Сатучының-алучының
Күзләре
Билгесез бер курайчыны
Эзләде.
Тиздән моңның иясен дә
Күрделәр:
— И... и... дивана икән ич,— дип
Көлделәр.
— Әй, дивана, килдең монда
Кай яктан?
— Каян булсын... урманнардан,
Тау яктан...
— Шул кураен кулларыннан
Куймый ул.
— Бераз гына ялындыра,
Уйный ул.

Хәйран калып карап торам
Мин аңа,
Сатмый, алмый, уйный бирә
Дивана.

Уйный бирә, исәпләми,
Санамый,
Ризыкларга-нигъмәтләргә
Карамый.
Үзләре дә белми, яше,
Карты да
Ни өчендер диванага
Тартыла.
— Әй, дивана, кураеңны
Тарт әле!
— Әй, дивана, курай ни хак? —
Сат әле!
Җавап бирә тәкәллефсез,
Тартынмый:
— Бәясез ул: курай моңы
Сатылмый!
— Әй, дивана, юлың бара
Кай якка?
— Кая булсын... урманнарга,
Тау якка.
Гадәттәге көнкүрештән
Уятып,
Китеп барды уе барны
Уйлатып.
Китеп барды, базар бераз
Тын калды,
Моңы барның йөрәгендә
Моң калды.
Уйный-уйный югалды ул
Күзләрдән.
Мин дә киттем ул калдырган
Эзләрдән.
Кулым — рульдә, барам аның
Эзеннән,
Карыйм артка: машиналар
Тезелгән.
Кайберәүләр кызык итеп
Баралар...
Ерагайган табигатьтән
Аралар.
Моң артыннан машиналар
Тезелгән...

Без түгелме табигатьтән
Өзелгән?
Диванабыз урманнарга
Юл алды,
Уйный-уйный табигатьтә
Югалды.
Югалттым мин дивананың
Эзләрен.
Ник югалттым? Гомерем буе
Эзләрмен.
Бәлки, әле бер төшәрмен
Эзгә дә...
Диваналык кирәк бераз
Безгә дә...

*1978*

# Ай сонатасы*

Төн.
Тын.
Тиздән — таң атасы.
Урамнарда
Илаһи моң:
«Ай сонатасы».
Җир тирбәлә
Галәм бишегендә.
Ә Ай-әни
Көйли бишек җырын:
«Балам, уян,
Ишет әнкәң моңын».
Җир уянды
Һәм ишетте көйне...
Тик Ай соңгы нурын сипкән иде,
Бөтен моңын, нурын Җиргә биреп,
Ул таң белән сүнеп киткән иде...

*1971*

* Р.Яхин музыкасы.

* * *

Мәхәббәтнең
Кире кайтмас
Газаплы саф ядкаре,
Яшьлегеңнең
Шаян җилдә
Дулкынланган чаклары...

Язмыш миңа
Бүләк иткән
Иң якын кеше итеп.
Саклыйм синең
Толымыңны
Сафлыгың төсе итеп.

Бик бәхетсез
Булмасам да
Мин бүгенге көннәрдә,
Күрә алмам
Чәчләреңнең
Җилфердәвен җилләрдә...

*1971*

* * *

— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?..
— Чүлләрдә сусаган кешегә
Чишмәдән су илтеп барышым.
— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Ачлыктан тилмергән, йөдәгән
Балага нан илтеп барышым.
— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Диңгездә бәлагә очраган
Корабка ярдәмгә барышым.
— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Йорт-җирен су баскан кешегә
Диварлар төзәргә барышым.
— Әй, Кеше, кайларга юл тоттың,
Юк анда туганың-танышың?
— Барасы юлыма корылган
Диварны сүтәргә барышым.

*1972*

## Өзелмә...

Мин — бер яфрак, яралганмын
Әнкәй дигән каеннан,
Язмышым тик изгелектән,
Ал нурлардан каелган.
Хәзер үзем — каен. Әнкәй,
Яфрагым бул, өзелмә,
Саклармын зәһәр җилләрдән
Кышларын да, көзен дә...

*1975*

## *Хуш, бәхил бул...*

Яшьлегебез шәүләләре уйный
Чыгып килгән кояш нурында.
Хуш, бәхил бул, аерыла юллар,—
Күрешүләр — язмыш кулында.
Сөю яна — кояш нурында.
Бәлки...
Очрашырбыз гомер баешында,
Син — үз юлың, мин — үз юлымда...
Яшьлегебез шәүләләре уйнар
Синең кызың, минем улымда,—
    Баеп барган кояш нурында...

*1974*

# Нишләдем?..

Нишләдем?
Күкрәк читлегеннән сыеша алмый
Ташып чыга иде хисләрем.
Нишләдем?
Мин йөгәнсез чапкан бер тай идем,
Белми идем хыял чикләрен.
Нишләдем?
Тупасланганмы әллә хисләрем?
Йөрәгемне салып күрегенә,
Гармун уйный идем кичләрен.
Нишләдем?
Яшьлегемнең шашкын дулкыннарын
Күкрәк читлегенә бикләдем.
Нишләдем?
Юрга тайдай түгел, йөк атыдай
Тартып барам заман йөкләрен.
Нишләдем?
Давыллламый, эчтә ташый хәзер
Сабырланган яшьлек хисләрем.
Нишләрем —
Күкрәгемне ватып чыкса әгәр
Сыешалмый яткан көчләрем?
Яшьлегемнең шаян дулкыннары
Шашып әйтсә миңа:
«Нишләдең?!»

*1976*

* * *

Гаиләдә төпчек бала идем мин,
Абыйлардан калган кием кидем мин,
Абыйлардан калган укны аттым мин,
Абыйлардан калган төпчек тарттым мин.
Абыйларым китте сугыш кырына,
Абыйлардан калды бары җыр гына:
«Китәм инде, китәм инде,
Китсәм кала күлмәгем,
Күлмәгемне энем кияр,
Ярымны кемнәр сөяр?»
Абыйлардан калган юлда — тузаннар,
Яу кырында ятып калды туганнар.
Абыйларның төсен җирдә сакладым,
Абыйларсыз калган юлдан атладым.
Гаиләдә төпчек бала идем мин,
Абыйларның йөген тартам инде мин.
Абыйлардан калган каеш — билемдә,
Абыйларсыз заман йөге — иңемдә.
Абыйларның җыры чыңлый йөрәктә,
Парсыз калган ярга авыр бигрәк тә...
«Абыйларны онытыгыз!» — диялмим,
Абыйлардан калган ярны сөялмим...

*1976*

## Суга баткан бала

Кызык итеп,
Гүя юри
Тик уйнап качкан бала,
Көн-төн көтеп,
Ярда йөри
Күп уйлап шашкан ана,
Комдагы
Аяк эзенә
Тын гына баккан килеш,
Тирән кайгы
Диңгезенә
Мәңгегә баткан килеш...

## Әнисез нигез

Тик ул бәйләп
Торган икән
Күңел җепләрен,
Уллар-кызлар
Таралышты,
Нигездә — әрем.
Гомер буе
Ул бәйләгән
Йомгак сүтелде.
Сагына барысы
Ул морҗадан
Чыккан төтенне.
Суынды көл,
Сүнде учак,
Эзләр күмелде...
Кире чорнап
Кара хәзер
Йомгак-гомерне...

*1975*

* * *

Кара диңгез суларының ярлардан ашкан чагы,
Бер сәбәпсез котырынган, дулаган, шашкан чагы...
Аһ, кайда син, яшьлегемнең тезгенсез чапкан чагы,
Чиксез дәрья төпләреннән бәллүрләр тапкан чагы?!
Аккоштай ак муеннарга энҗеләр таккан чагы,
Диңгездәй тирән күзләргә сокланып баккан чагы,
Мәхәббәтен эзләп, табып, кабат югалткан чагы,
Татлы хәсрәт суларына чыкмаска баткан чагы...
Яшьлекнең шашкан чагыннан ярларга кайткан чагы,
Гомеремнең яшьлек белән ярсып хушлашкан чагы?!
Аһ, ул булган яшьлегемнең диңгезгә аккан чагы.

Кара диңгез суларының ярлардан ашкан чагы,
Бер сәбәпсез котырынган, дулаган, шашкан чагы...

*1976*

# *И туган як...*

Тоела хәзер, тоела
Төннәрең көннәр булып,
Чәнечкеле билчәннәрең
Иң гүзәл гөлләр булып,
Бик кечкенә тауларың да
Иң биек үрләр булып,
Йолдызга карап баш куйган
Ташларың мендәр булып...
Китмәстер һаман йөрәктән
Чыңнарың һәм шауларың...
Төшемдә эчкән суларың
Басмыйдыр сусауларым,
Мәңгелек сусауларым...

*1976*

## Калмадыммы?..

Кайчандыр ул салкын чишмә булган,—
Тамчылардан күлләр җыелган,
Челтерәп агышлары онытылган,—
Агып киткән үзән буеннан.
Карамыйча артка каерылып,
Диңгезләргә таба юл алган,
Чыккан чишмәсеннән аерылып,
Үзәннәрдә кибеп югалган.
Килә минем гомерем агышында
Ярларымнан ташып агасым,
Юк, юк, килми еллар барышында
Корган елга булып каласым.
Суым тулып ашыгып аксам да мин,
Ник узганга карыйм каерылып,
Мине елга иткән чишмәләрдән
Калмадыммы икән аерылып?..

*1976*

# *Тамсын ул...*

Күңелемдә ялтырап
Кояш чыкты
Һәм күземнән мөлдерәп
Бер яшь чыкты.
Кояш нурын күпме генә
Сипмәсен,
Кипмәсен ул сөенеч яше,
Кипмәсен.
Оялмамын кешеләрдән,
Сөртмәмен,
Үз шатлыгым итеп кенә
Йөртмәмен.
Ак кәгазьнең битләренә
Тамсын ул,
Кешеләргә шатлык алып
Барсын ул!..

*1976*

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

## Тоям...

Тоям: бу моң килә борынгыдан,
Шаулап-күкрәп миндә тынгандыр...
Кайсыдыр бер ерак бабам минем
Билгесез зур шагыйрь булгандыр...

*1975*

## Тыңламадым...

Тыңламадым ул чак бер карт сүзен...
Шул ялгышым чәчне агартты.
Гомер буе акыл җыйгач белдем
Акыл иясе дип ул картны...

*1975*

## Шат иде...

Һәрвакыт шат иде... хәсрәтле
Чакларын күргәнең бармы соң?
Ул китте... соңыннан белделәр
Таулар да күтәрмәс кайгысын.

*1975*

## Бәхет килгәч...

Кайгы килгәч, бар да уртаклаштылар,
Бәхет килгәч, әллә инде качтылар...
Мин бәхетле,— тик дуслар юк, берүзем,
Бәхетем белән ялгыз калдым,— бир түзем!..

*1975*

## Юк шул...

Гармония юк шул бу Җирдә.
Мин тәртипкә салам дөньяны
Тик, кызганыч, бары шигырьдә...

*1975*

## Посып тора...

Йөрәкнең нәкъ бер читендә көнчелек посып тора,
Күңелләрне тарайтып шул кимчелек кысып тора.

*1975*

## Бер чыгарсың...

Син — бер кояш, нурларың да,
Тапларың да бар,
Нәкъ кояш кебек тотылган
Чакларың да бар.
Тотылганда да карамам
Кара күзлек киеп...
Син барыбер бер чыгарсың,
Нурың белән сөеп...

*1976*

## Ни җитми?

Ни җитми? Ник карыйм каерылып,
Һич кире кайтмаслык чакларга?
Нәрсәдер калган күк, калган күк
Бишегем тирбәлгән якларда...

## Явызлык

Яман адәмгә тормышта
Явызлык кирәк була,
Явызлыкны йөгәнләргә
Авызлык кирәк була.
Явызлык булмый кечкенә,
Явызлык олы була,
Көрәшкә сәләтсез кеше
Явызлык колы була.

*1976*

## Еллар узгач...

Әйләндермә шатлыкны син хәсрәткә,
Әйләндермә мәхәббәтне нәфрәткә,
Еллар узгач, гомер кичкәч, син аңларсың:
Хәсрәтеңнең ул чак шатлык булганын,
Нәфрәтеңнең сөю-сафлык булганын
син аңларсың...

## Бер генә сүз...

Бир мөмкинлек, язмыш, бер минутка
Узганыма кире кайтырга.
Бир мөмкинлек бары бер генә сүз:
«Кичер!»— диеп кенә әйтергә.

## Моңсу ядкәр

Килеп чыкты чиккән кулъяулыгы
Авылдагы иске сандыктан...
Моңсу ядкәр тәүге мәхәббәттән,
Күз яшьләре сыман сафлыктан...

*1976*

## Чыгалмасаң...

Чыгалмасаң әгәр ваклыктан,
Тайпылырсың олы Хаклыктан.

## Уйлама...

Уйлама үзеңне халык дип,
Шул халык эчендә Алып дип,
«Ул — халык эчендә Алып» дип,
Әйтергә хаклыдыр халык тик...

## Дусны югалттым...

Бер җан дустым минем бар иде,—
Бер-беребезгә күңел табынды...
Кем гаепле, белмим, югалттым,
Югалттым мин ярты җанымны...

## Мәшәкать

Дөнья мәшәкатьтән корылган,
Дөнья мәшәкатьтән кырылган.
Мәшәкатьне хуплыйм мин аны, —
Кырмасын тик, корсын дөньяны.

*1976*

## Бер хакыйкать

Син этиме, йә әниме...
Тик бер хакыйкать кала:
Хет даһи бул, хет хаким бул, —
Табигатьтә син — бала!

## Нигә?

Нигә рәнҗетәбез табигатьне?!
Тилмереп һәм әрнеп ул калыр,
Явызлыклар өчен кайчан да бер
Безнең оныклардан үч алыр.

## *Ир булгач...*

Дөнья гаме килә — ир булгач,
Дөнья яме килә — ир булгач,
Дөнья тәме килә — ир булгач...
    Ах!
Дөнья кала —
Ирләр китә бара —
                    ир булгач...
Гамь дә,
        ямь дә,
                тәм дә җирдә кала.
Дөнья бәяләре — ир булгач...

## *Аңладым...*

Әтиләрнең яшьли картаюын
Бала чакта чынга алмадым,
Мин моны тик, үзем әти булгач,
Балаларга карап аңладым.

*1976*

## Бул!

Гөл булмаган җирдә — былбыл бул,
Җир булмаган җирдә — сөмбел бул.
Боз булмаган җирдә — салкын бул,
Ут булмаган җирдә — ялкын бул.
Чүлләр булган җирдә — күлләр бул,
Төннәр булган җирдә — көннәр бул.
Давыл булган җирдә — тамыр бул,
Авыр булган җирдә — сабыр бул.
Шаян булган җирдә — наян бул,
Усал булган җирдә — чаян бул.
Хәсрәт булган җирдә — шатлык бул,
Ялган булган җирдә — сафлык бул.
Дошман булган җирдә — кылыч бул,
Дуслар булган җирдә — тыныч бул.
Чит җирләргә барсаң — илче бул,
Дус табасың килсә — юлчы бул,
Халыкларны якынайтыйм дисәң,
Тукай, Бердах[1] кебек җырчы бул!

*Каракалпакстан*
*Август, 1969*

*Бердах* — каракалпак халкының бөек шагыйре.

## Шигъриятнең хәле

Шигъриятнең хәле җиңел түгел,
Шигъриятнең җаны яралы:
Дошманнары салкын акыл белән
Чыгармакчы хөкем карары.
Моңнан, җырдан бары табыш кына
Көтүчеләр күчте һөҗүмгә.
Тукай исеме белән дәшәм сиңа:
Шигырь җаным, чигенмә!
Шигъриятнең хәле беркайчан да
Булмаган шул рәхәт, җиңел дә...
Ул һәрвакыт Җәлил җыры сыман,
Яшәү белән үлем чигендә.
Туфан сыман сабыр-түзем дә ул,
Такташ җыры кебек тынгысыз...
Дошманнары һәрчак шагыйрьләрне
Хөкем итеп, көткән соңгы сүз.
Сигез гасыр узган юлың бар шул —
Ахыр сүзне әйтер идең дә...
Дусың, дошманың да сиңа карый
Менә бүген авыр мәлеңдә.
Шигъриятнең хәле шундый әле:
Кул күтәрсәң,— үлем чигендә...
Башлар, җаннар биреп алган үрдән,
Шигырь бәгърем, чигенмә!
Кәрим кебек, авып, биектә кал,
Әмма җиңелмә!
Җыр югалткан гавәм баш калкыта.
Дөнья, хәвефләнеп, Чын сүз көтә,
Шигырь, чигенмә!
Иңсен өчен аңга рухи Ирек,
Килсен өчен җанга Җыр заманы,
Алга, һөҗүмгә!
Шигырь бәгърем, чигенмә!

*1979*

# Такташым

*Сынчы Фәһим Фәсхетдиновка*

Сагынганда күкрәгемә кысам
Туган җирнең салкын ак ташын,
Шул килеш тә мине җылытасың,
Моңга әверелгән Такташым.
Озак әле, озак юксындырыр
Күзең зәңгәрлеге, яшь башың...
Безнең дөньяларны зәңгәрләтеп,
Бигрәк иртә киттең, Такташым.
Егерме ел синнән артык яшим,
Картаямын, ахры, ак башым...
Заман агышында янам, туңам
Синең өчен дә мин, Такташым.
Йөрәгеңнең шашкын кайнарлыгын
Бирә алмаса да сынчылар,
Исемеңне әйтеп кагылганда,
Салкын ташлардан да моң чыгар.
Җирдә синнән озак яшәвемне
Шигъриятле гомерем акласын.
Ташны җырга әйләндерә Кеше...
Син яшисең, димәк, Такташым!
Күкрәгемә кысып синең сынга
Әверелгән туган як ташын,
Мин ант бирәм: моңнар, изге моңнар
Ташка әверелмәс, Такташым!

*1979*

## Хәсән Туфан фатихасы

Бигрәк тә бәхетле идек без
Ул исән, янәшә булганда.
Бер кичне чакырды өенә,
Үзенә сиксән яшь тулганда.
Әйтмәде: «Картайдым... Китәм»,— дип,
Зарлану, сыкрану — аңа ят.
«Егетләр, мин сездән разыймын...»
Бер җөмлә. Шул булган васыять.
...Разыйлык алганнар шагыйрьнең
Җәсәден күтәреп баралар.
Шулкадәр җиңел лә гәүдәсе...
«Мин сездән разыймын, балалар».
Һай, авыр, һай, авыр, бик авыр
Дөньяда Туфансыз калулар.
Юк, җиңел түгел ул изге зат —
Шагыйрьдән фатиха алулар.
Тагын да авыррак Туфанның
Өметен акларга калулар...

*1981*

* * *

Сине эзлим һаман, Хәсән абый...
Аккош күле. Кыш.
Урманнардан, сукмаклардан эзлим.
Син — юк. Бүлмәң — буш.

Синнән башка үтмәсә дә шигъри
Бәйрәмнәребез,
Үзең җитми җанга. Кайда соң син,
Пәйгамбәребез?

Ерак сәяхәткә киттең мәллә,
Әйтче, син кайда?
Көтмәгәндә пәйда бул, әйдә,
«Ба!» дип елмай да.

Акыл әйтә: «Нәкъ кешечә яшәп,
Ул туктап калды:
Чиксез мәңгелекнең бер җирендә
Йокыга талды».

Юк, эзләмим сине җир астыннан,
Кабердән, таштан;
Рухың мәңгелеккә тоташкан да
Күкләргә ашкан!

Күрмәсәм дә, шигъри пәйгамбәрем,
Һич өмет өзмим:
Сине Тукай, Такташ киткән яктан —
Күкләрдән эзлим!

*1982*

# Киттек, Сибгат абый!

*Сибгат Хәкимгә*

Кайчан гына әле башкалада,
Лужникида, меңнәр алдында
Шигырь сөйләдек без...
Хәзер
башым иеп
Мин утырам койкаң янында.
Беләм, аңлыйм: хәлең авыр бик.
Әйдә киттек шигырь кичәсенә,—
авырмыйк!
Без дә мәңге түгел, бердәнбер көн
Егылырбыз, бәлки, көч бетеп...
Шигырь белән әле көчлеләр без,
Яшик әҗәлләргә үч итеп!
Күкрәкләрең — ялкын, тәнең — кайнар,
Димәк, шигырь яна җаныңда.
Авыргач та сафтан китмибез без:
Без һаман да меңнәр алдында!
Менә бүген күп шагыйрьләр белән
Шигырь кичәсенә җыйналдык...
Сибгат абый, синсез — кыен икән:
Җитми синең олуг тыйнаклык!
Беләм, аңлыйм: хәлең авыр бик,
Әйдә, киттек шигырь кичәсенә,—
Сөенмәсен әле шигърияткә
Дан таларга,
Мал таларга килгән бәндәләр.
Тор, күтәрел, әйдә, Сибгат абый,
Юл күрсәтеп, гел-гел алдан бар!
Һөҗүм итә-итә, шигъриятнең
Үрен яулап алган шикелле,
Курск дугасында яраланган
Хәлдә алдан барган шикелле,
Киттек, Сибгат абый, тор, күтәрел,
Таян ышанычлы иңнәргә...
Хәсән абый да юк...
Сездән башка
Без таяныйк тагын кемнәргә?

Сугышта да, тынычта да алган
Яраларың сызлыйлар, беләм,
Телгәләнеп беткән йөрәкләрне
Яшерик тә шигырьләр белән,
Киттек, Сибгат абый,
Безгә рәхәт
Синең кебек чын ирләр белән,
Үргә күтәрелү җиңелрәк
Синең кебек шагыйрьләр белән.
Киттек, Сибгат абый,
Син — командир,
Мин дә бүген синең взводта;
Юк, куркыныч түгел сезнең белән
Өермәләр, дәһшәт, боз, ут та...
Киттек, Сибгат абый!

*1986*

# Югалмаган дуска

*М.Я.*

Яши-яши без ниләрне югалттык?
Үзебез туган өйләрне дә югалттык.
Бара-бара илле юлны югалттык,
Кырык елны, илле елны югалттык.
Сөенечле яшьләрне дә югалттык,
Куе кара чәчләрне дә югалттык.
Әтиләрне-әниләрне югалттык,
Сугышларда абыйларны югалттык.
Гашыйк булып, һушларны да югалттык,
Шаулы мәҗлес, тостларны да югалттык.
Үзе килгән постларны да югалттык,
Илле юлда илле дусны югалттык.
Тиләләнеп, без аңнарны югалттык,
Әллә күпме гармуннарны югалттык.
Бишкә бүлгән алмаларны югалттык,
Ялган даһи-Аллаларны югалттык.
Бу дөньяда гел-гел-гел югалттык без,
Күп югалтып, үзебезне таптык без.
Югалтулар эзен салды... ни калды?
Йөрәкләрнең үзәгендә көй калды.
Гамьсезлекне югалтып, без моң таптык,
Авыр тапкан бу көйне без югалтмыйк!
Моңсызларны, көйсезләрне моңайтыйк,
Һәммәсен дә югалтканны юатыйк.
Югалтуга киткәч, барсын югалтыйк,
Иң кадерле гомерне дә югалтыйк,
Шуннан соң да үзебезне югалтмыйк,
Авыр тапкан бу көйне без югалтмыйк!

*1988*

## Юлдашым, тукта...

«Башка вакытта керермен...— дисең,—
Гомерләр озын, күрермен»,— дисең.
Юк, юк, юлдашым, әнкәң тоядыр,
«Якында гына...» — диеп куядыр.
Әнә үзе дә... капка төбендә,
Көткән кичә дә, көткән бүген дә.
«Ашыгам, әнкәй, тамак тук! — дидең,—
Чәй эчәргә дә вакыт юк»,— дидең.
Күзләре белән озата бара бит:
Кара борылып, әнкәң кала бит...—
Болай да кердең бик азга инде,
Кире кил, бала, бер назла инде.
«Рәхмәт, әнкәй!» — дип, ике сүз генә
Әйтче, әйт, бала, бик тиз, тиз генә.

Борылмадың, юк, кире бармадың...
Һәм үзем дә мин бик соң аңладым:
Узып барышлый, соң кайткач кына,
Әнкәмне мәңге югалткач кына...

*1988*

## *Асфальт юлдан ат бара*

Асфальт юлдан юртып ат бара,
Арбасында уйчан карт бара.
Алларында кызыл ут яна:
Башын иеп, малкай туктала.
    Юллар ачык, яшел ут яна,
    Киттек, малкай, әйдә, әйдә, на!
    Их, китәсе иде хыялга:
    Киң болынлы яшел дөньяга!
Йөрәгендә тизлек артадыр,
Яшел печән исе тартадыр,
Алларында кызыл ут яна:
Чаба-чаба да ул туктала.
    Юллар ачык, яшел ут яна,
    Киттек, малкай, әйдә, әйдә, на!
    Их, китәсе иде хыялга:
    Киң болынлы яшел дөньяга!
Асфальт юлдан ярсып ат бара,
Арбасында уйчан карт бара.
Юк болыннар монда, юк — дала,
Тимер ташкынында туктала.
    Юллар ачык, яшел ут яна,
    Киттек, малкай, әйдә, әйдә, на!
    Их, китәсе иде хыялга:
    Киң болынлы яшел дөньяга!

*1988*

# Нихәл, күрше?

*(Телетамашачы белән сөйләшү)*

Мин дустың да, танышың да түгел,
Аргансыңдыр инде, кич җиткән.
Зәңгәр экранында күренермен,
Кермәсәм дә бикле ишектән.
Килдем сиңа бары ике сүзне:
«Нихәл, күрше?» — диеп әйтергә,
Шигъриятнең бер илчесе булып,
Сөенеп һәм көеп әйтергә.
Тынгысыз һәм көйсез Җир йөзендә
Бергә яши торган кешеләр —
Телибезме, теләмибезме,—
Без һәммәбез якын күршеләр.
Хәлең ничек?
Сөенеч-шатлыкларың
Котлы булсын! Әйдә, күрешик!
Хәсрәт-бәлаләрең газапласа,
Уртаклашыйк, бергә бүлешик!
Ачыйк әле җанны бары икәү
Хәл белешкән чакта, бу мәлдә:
Әти-әниләрең, туганнарың,
Күрше-күләннәрең ни хәлдә?
Берәр күршең тормышыннан бизгән,
Өметен өзгән, бәлки, кем белгән...
Иң-иң якындагы кешең синнән
Таш диварлар белән бүленгән.
Әллә инде күптән онытылганга,
Ишетелмәгәнгә күрше ягыннан,
Авылдагы «Нихәл, күрше?» дигән
Җанга якын сүзне сагынам.
Бер үк планетада диеп әйтмим,
Бер подъездда күпме яшибез,—
Күңел өчен генә булса да бер:
«Нихәл, күрше?»— диеп дәшмибез.
Нигә тансык хәзер күркәм гадәт:
Хәлгә керү, олы-кечелек?
Күрше белән күрше аңлашмагач,
Ничек аңлашсын, ди, Кешелек?

Дуслардан да бигрәк, дошманнар күп,
Аерым-аерым яшәр чак түгел...
Һәр адәмнең кайгы-хәсрәте бар:
Берәүнең дә хәле шәп түгел.
«Күрше хакы — Алла хакы!» дигән
Изге мәкаль бара искереп.
Һәлакәткә таба илтәр үзен,
Күршелектән язса Кешелек,—
Кешелектән язса Күршелек!
...Сау бул, күрше...
Борчып китте, диеп,
Гаеп итмә...
Яшә сәламәт!
«Нихәл, күрше?» диеп дәшкәннәргә
Миннән сагынып-сөеп сәлам әйт!
Бәла-кайгы җир астына китсен,
Сөенечләр күккә ашсыннар,
Илләр, планеталар бер-берсенә
«Нихәл, күрше?» диеп дәшсеннәр!
Тыныч йокы, матур төшләр теләп,
Зәңгәр экраныңнан югалам...
Шигърияттнең бер илчесе булып,
Ят илләргә карап юл алам...

*1989*

## Аксакаллар мәҗлесендә булдым

Әлегә кадәр юкка мин үземне
Акыллы дип фараз иткәнмен,
Аксакаллар мәҗлесендә булдым:
Мин шактый ук надан икәнмен.
Әлегә кадәр юкка мин үземне
Хисле адәм диеп йөрткәнмен,
Аксакаллар мәҗлесендә булдым:
Мин хискә дә ярлы икәнмен.
Көчсезлегем калкып чыгар диеп,
Әйтә алмый калдым сүземне,
Әмма шуны аңлый алуым белән
Көчле итеп тойдым үземне.
Тарих бабай үзе карап тора
Зирәк аксакаллар аркылы,
Мөлдерәмә яшьләр булып тула
Халык хисе, халык акылы.
Бөек аксакаллар мәҗлесендә
Боек күңелем калды хуш булып.
«Без китәбез...» — диеп җырладылар...
«Без калабыз!» — дидем, кушылып.

*1985*

## Үзгәрүчеләргә

Юк, ышанмыйм сезгә, нык ышанмыйм,
Җыелыш саен сүз алучылар,
Өстән «Үзгәрергә!» дию белән,
Минутында «үзгәрүчеләр»...
Мин ышанам сезгә, нык ышанам,
Ялгыш өчен сызланучылар,
Йөрәкләрен янар эшкә биреп,
Беләкләрен сызганучылар,
Сызыла-сызыла, кайчак өзелә-өзелә,
Авыр-авыр үзгәрүчеләр!

*1987*

## Төннәр кебек зәңгәр сагышларым

Ярда таллар йоклый арып-талып,
Җил дә тынып калган. Сулар тын.
Сай күлләрне тирән уйга салып,
Гармун уйный берәү югартын.

Көй тирбәтә күлнең камышларын,
Моңга күмә елга буйларын.
Төннәр кебек зәңгәр сагышларым,
Күлләр кебек тирән уйларым.

Яшьлек моңын әллә Айдан алган
Төннәр сандугачы шул гармун...
Түзә алмам: зәңгәр төндә калган
Сөйгәнемне эзләп чыгармын.

*1976*

# Табыйк шундый бер җыр

*Р.С.*

Бәхәсләшеп, дуслык дигән изге
Чиктән узып китеп,
Кул күтәрде икәү бер-берсенә,
Кинәт кызып китеп.
Көчле иде болар әзмәвердәй
Арысланнар кебек,
Бер-берләрен өзгәләрләр хәзер
Гел дошманнар кебек.
Син җырладың шулчак шундый бер җыр —
Икәү — тынып калды,
Көчле йодрыклары күтәрелгән
Килеш торып калды.
Кирәк түгел хәзер бу икәүгә
Сүзләр, үгет, вәгазь...
Иң ахырдан куллар кысыштылар:
Хәл ителде бәхәс.
Мин дә, дустым, әнә шуннан бирле
Бер җыр көйләп йөрим.
Бу дөньяны көйләп булмас, беләм,
Әмма уйлап йөрим:
Бер-берсенә ташланырга тора
Милләт, гаскәр, яулар...
Бу көчләргә киртә була алмас
Елга, дивар, таулар...
Табыйк, әйдә, шундый тылсымлы җыр:
Дөнья уйга талсын,
Илләр бер-берсенә гел салават
Күперләре салсын.
Кулларына кылыч күтәргәннәр
Кинәт туктап калсын,
Моңнан сихерләнеп, кылычларын
Кыннарына салсын!
...Беләм, бу уйларым әлегә тик
Дәртле хыял гына.
Тик ышанам Җырның явызлыкка
Бер чик куярына!
Табыйк шундый бер җыр!

*1982*

## *Бер җырладым...*

Биек тауга менеп бер кычкырдым, —
Ишетмәделәр,
Узучылар, тургай, сандугачлар
Иш итмәделәр.
Үзәннәргә төшеп бер еладым, —
Аңламадылар,
Кызгандылар гына, ә үземне
Санламадылар.
Читәннәргә менеп шашып көлдем,—
Карамадылар,
Мөлдерәмә тулы күңелемне
Яраладылар...

Урманнарга кереп бер җырладым, —
Тукталды бар да,
Узучылар, тургай, сандугачлар
Тын калды бар да...

*1982*

## Табигать туе

Җәйге иртә. Кояш чыга. Тау буйлатып,
Көмеш-талир тәңкәләрен ялтыратып,
Каен-кызлар су алырга аска төшә,
Бии-бии, йөгерешә-йөгерешә.
Таң җилендә бию көен уйный курай,
Аңа кушылып җырлый чишмә, тыңлый тугай.
Яшь имәннәр көрәшергә алга чыккан,
Таң аларга ак томаннан сөлге чиккән.
Монда — узыш, монда — чабыш, монда — ярыш,
Сүз дә юктыр, сандугачка — моңда ярыш.
Нәфислектә, инсафлыкта каен — өлге,
Имән-егет иңнәрендә — ап-ак сөлге!
Каен кызын яшь имәнгә димли кошлар,
Кошлар сүзен тыңламыйча булмас, дуслар!
Каен моны күптән көткән икән ләсә,—
Имән барсын, аермыйча, туйга дәшә.
Монда — шатлык, монда — бәйрәм, монда — уен,
Алкышлый җан табигатьнең сабан туен!
Онытыла бу дөньяның хәсрәт-уе,
Җанның бүген табигать белән кавышу туе!

*1982*

## *Тау ягы гүзәле Әлфинур*

Китмә син яшьлектән, Әлфинур,
Унҗиде яшеңдә торып кал,
Мәңгегә картая белмәүче
Тау ягы гүзәле булып кал.

Китмә син яшьлектән, Әлфинур,
Үзәнгә сибелсен нурларың,
Әйтсеннәр уфтанып: «Нигә мин
Тау ягы егете булмадым?»

Китмә син яшьлектән, китмә син,
Эзеңдә, йөзеңдә балкый нур,
Унҗиде яшеңдә торып кал,
Җырымда булса да, Әлфинур...

*1982*

## Бер кочак җылы

Бер кочак чыбык-чабыктан
Кабынды учак,
Көтеп торган юлда мине
Җылы — бер кочак!
Ул җылыны алып китәм,
Күңелем тулы
Юлда калып туңганнарга —
Бер кочак җылы!
Җитә адәм баласына
Бер учак нуры,
Күп тә түгел, аз да түгел:
Бер кочак җылы!

*1982*

## Тормыш ул — серле бер могҗиза

Кайчакта үзеңне
Бәхетсез тоясың:
Өметең гөлләрен җил өзә...
Нигә соң, нигә соң
Күренми Кояшым?
Тормыш ул — серле бер могҗиза.
Кайчакта үзеңне
Бәхетле тоясың:
Күңелне иркәләп нур йөзә.
Бер җанга, Кояшым,
Ничекләр сыясың?
Тормыш ул — серле бер могҗиза.
Бәхетле минутлар,
Бәхетсез сәгатьләр
Барсы да мизгелдәй бер уза...
Нурыңны коеп кал,
Гомереңне тоеп кал:
Тормыш ул — серле бер могҗиза...

*1987*

## Су астында калган гүзәллек

Сылу кызлар көнләшәләр иде
Каеннарның буй-сыннарыннан.
Гашыйкларны аерып булмый иде
Мәхәббәтле су буйларыннан.
Каеннарның яшел толымнарын
Таңда җилләр тарый иделәр,
Нечкәбилләр тып-тын су өстенә
Көзге итеп карый иделәр.
Оялышып, шәрә тезләренә
Толымнарын яба иделәр,
Яфракларын суга мана-мана,
Ак тәннәрен чаба иделәр.
...Өмет белән карыйм дулкыннарга:
Тирәнлектән кемдер дәшәр кук,
Су кызлары килеп чыгар сыман,
Уйный-уйный сулар чәчрәтеп...

*1989*

# *Челтери дә чыга...*

Борынгы Биләргә якын гына, Хуҗалар тавы астыннан, чишмә агып чыга. Халыкта изге саналган бу чишмәне җирле түрәләр техника ярдәмендә ташлар белән томаламакчы булганнар. Әмма гаҗәп хәл: чишмә яңадан-яңа көчтавыш белән челтерәп агуында дәвам иткән...

Кол Галиләр, Утыз Имәниләр...
Юлда туктап, кемнәр эчмәгән,
Юлын бүлим, башка акмасын, дип,
Кемнәр ниләр генә ишмәгән,—
Челтери дә чыга чишмәләр.

Халык йөрәгенең тибешләре
Кемнән кемгә генә күчмәгән,
Тукай булып, Җәлил булып тибә
Өстен булып барлык көчләрдән,—
Челтери дә чыга чишмәләр.

Инде агышыннан туктады дип,
Хәсрәтләргә кемнәр төшмәгән,
Һич тә көтелмәгән урыннардан,
Һич тә көтелмәгән төшләрдән,—
Челтери дә чыга чишмәләр,
Челтери дә чыга чишмәләр!

*1984*

## Сезгә мин ни әйтим?

Сезгә мин ни әйтим...
Ничекләр юатыйм,
Бары тик ядкәрләр кайталар...
Ирләрен югалткан,
Улларын югалткан,
Елларын югалткан апалар?
Сезгә мин ни әйтим...
Ничекләр юатыйм,
Җаннарда яңара яралар,
Әнкәсен югалткан,
Әткәсен югалткан,
Һәммәсен югалткан балалар?
Бар изге ниятем,
Ничекләр мин әйтим,
Түзәлми бер кайтыр кебекләр:
Нахакка сатылган,
Хөкемгә тартылган,
Гаепсез атылган егетләр...
Бар изге ниятем,
Ничекләр мин әйтим.
Әйтсәм бер ишетер кебекләр:
Хәбәрсез югалган,
Кадерсез югалган,
Каберсез югалган егетләр...

*1989*

* * *

Көтмәдем, кайчан килер дип,
Өлешкә тигән көмеш,
Сорамадым беркайчан да:
«Кайда,— дип,— минем өлеш?»
Бәлки, бардыр ул минем дә
Өлешкә тигән алтын...
Атылмадым, сатылмадым,
Алтынга караш салкын.
Кызыкмадым кемнәрнеңдер
Алтыны, көмешенә,
Болай да күп керүчеләр
Башкалар өлешенә.
Милләтнең рухи байлыгы —
Алтыны-көмешендә,
Бер генә тамчы булса да,
Бар минем өлешем дә.

*1990*

## Килеп сөялдең каенга

Якты уйларга зарыгып,
Урманга барасың да,
Ап-ак тоясың үзеңне
Каеннар арасында.
Өлкән яшьтәге каенга
Сөйлисең серләреңне,
Каен җилендә юасың
Җандагы керләреңне.
Тормышның авыр юлында
Йөрәгең тузды сыман,
Дөрләп янарга әзер ул
Каенның тузы сыман.
Килеп сөялдең каенга
Юлыңның яртысында,
Китсен күңелең хәл алып,
Каеннар яктысында.
Узмады газиз башыңнан
Ни генә, ниләр генә...
Иркәли хәзер чәчеңнән
Ягымлы җилләр генә...

*1991*

## Әнкәйгә бишек җыры

Син мине бишектә тирбәттең,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
«Өметем, күз нурым» дип әйттең,
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Көйләрең бәгъремә уелды,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Балачак җыр булып тоелды,
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Дәү үстем, яшәдем еракта,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Берәү дә көйләми ул якта:
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Әкренләп онытмым өйне дә,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Әнкәем тирбәткән көйне дә,
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Мин инде көйләргә ят бала,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
«Хәбәр бар: «Әнкәң — юк... Кайт, бала...»
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Әнкәем туфрагы җылы ич,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Мин аның өмете, нуры ич,
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Сау чакта белмәдем кадереңне,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Ал, әнкәй, ал минем бәгъремне,
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Әйтерсең Җир — бишек, Җир — матәм,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Әнкәмнең бишеген тирбәтәм,
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Гамьсез бер йокыдан уяттың,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Ник, нигә бик соңлап мин кайттым,
бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Син инде мәңгелек йокыда,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Тынычлык бир аңа, йа Хода,

бәлли-бәү, бәлли-бәү.
Тирбәтсен үз көең, үз җырың,
бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Әнкәем, өметем, күз нурым,
бәлли-бәү, бәлли-бәү...

*1990*

* * *

Юк инде гамьсез шаяру
Һәм көлеш.
Бөкерәйдем... картайганчы...
Яшь килеш.
Ерак-ерак дәверләрдән
Килгәндер.
Җиде бабамның рәвеше
Сеңгәндер.
Ничә гасыр бөгелгән дә
Сыгылган.
Күпмеләре авырлыктан
Егылган.
Бу сыйфатлар улдан — улга
Күчкәннәр...
Турайганның горур башын
Кискәннәр.
Бу гәүдәмне, бәлки, кабер
Турайтыр,
Токымымда «Турайдым!» дип,
Кем әйтер?
Үлеп кенә качып булмас
Хурлыктан.
Җирдә кайчан котылырбыз
Коллыктан?
Гомеремне нәселдә кем
Озайтыр,
Гаделсезлек, ялганны кем
Турайтыр?
Дөрес, анысы, әлегәчә
Баш исән.
Җәлладларым җиң сызганган —
Баш исәң...
Гәүдәм — бөкере, тик шулай да
Баш туры!
Күзләремдә — өмет белән
Яшь тулы...

*1991*

# Болытлар артында Кояш бар!

Усаллар, әрсезләр заманы...
Нәселдә һәммәбез юашлар.
Бабабыз әйтергә яраткан:
«Болытлар артында Кояш бар!»
Өметне югалту бик ансат,
Ни генә күрмәде бу башлар...
Башларны калкытты тик бер нур:
Болытлар артында Кояш бар!
Караңгы, болытлы күзләрдән
Сибелер шатлыклы күз яшьләр...
Көн килер, дөньялар яктырыр:
Болытлар артында Кояш бар!

*1991*

# *Ян, күңел!*

Беренче дә булмый, бишенче дә...
Мәхәббәт ул салкын сан түгел,
Кайнар яшьлектә дә, картлыкта да
Сүнмә, дөрлә, мәңге ян, күңел!
Ваклап сатылмый да, алынмый да,
Мәхәббәт ул товар, мал түгел.
Дөнья малларыннан өстен калып,
Сүнмә, дөрлә, мәңге ян, күңел!
Җан серләрен илгә кычкырмыйлар,
Мәхәббәт ул оран, дан түгел,
Бик тирәндә, эчтән генә сызылып,
Сүнмә, дөрлә, мәңге ян, күңел...

*1991*

# Уйныйк әле быргыларны...

*Рифкать Исрафилга*

Йоклый вөҗдан, йоклый әхлак,
Йоклый акыл, саф мәхәббәт.
Ил йөзеннән сөрелгәннәр
Хозыр Ильяс һәм Мөхәммәт.
Табигатькә хыянәтме?
Сулар качты, оят качты.
Ахырзаман — кыямәтме?
Күңелләрне шайтан басты.
Йөрәкләрдә — боз катламы,
Кан аңкытып исә җилләр,
Кем коткарыр бу афәттән?
Илгә кирәк исрафиллар*!
Бер гөнаһсыз булмасак та
Һәр гамәлдә, һәрбер эштә,
Булыйк сәнгать дөньясында
Исрафилдай бер фәрештә!
Уятыйк без туң мохитне!
Җаны барның — моңы чыгар.
Булыйк сәнгать дөньясында
Исрафилдай быргычылар!
Уйныйк әле быргыларны,
Шайтан китсен башын иеп...
«Без барында күңелләргә
Кыямәт көн килмәс!» — диеп,
Уйныйк әле быргыларны!

*1991*

* *Исрафил* — мөселман ышануынча, кыямәт көнендә быргы өрү өчен билгеләнгән фәрештә.

# Кәҗә белән Сарык елында әйтелгән тост

*Нил Юзиевка*

Ямады дигән авылда
Карт, карчык гомер иткән.
Кәҗә вә сарыктан гайре
Берниләре юк икән.
Адәм булып, байлык төяп
Кайтсыннар, дип, салага,
Озатканнар бу икәүне
Казан дигән калага.
Китмәгән болар капчыкка
Кишер һәм кыяр төяп,
Киткәннәр болар туп-тулы
Омтылыш, хыял төяп.
Ике фәкыйрь Казанда да
Бик тату яшәгәннәр,
Бүреләрдән артып калган
Боткалар ашаганнар.
Болар икәү, иренмичә,
Гыйлемгә тотынганнар,
Карт белән карчык әйткәнчә,
Капчыкны тутырганнар.
Бер-бер артлы, җәлләмичә,
Капчык бавын чиш кенә...
Кәҗә бай икән акылга,
Ә сарыкта — хис кенә.
Ә бүреләр бу икәүне
Куып җитәргә теләп,
Көн-төн чапканнар капчыкны
Кабып йотарга теләп.
Кәҗә дә, сарык та исән,
Капчыклары да тулы...
Шөкер, бүре елы түгел,
Кәҗә һәм сарык елы.
Әкияттә сөйләнгән чор
Бик авыр еллар иде.

Кәҗә һәм сарык дигәнем
Нил белән Илдар инде...
Еллар һаман арык, әмма
Без, шөкер, исән менә...
Күтәрик бер кәҗә белән
Сарык исәнлегенә!

*1991*

* * *

Астрономнар ничә еллар инде
Җан иясен эзли Марстан[1].
Анда Рәдиф Гаташ туганлыгын
Күрми яшәп алар ялгышкан.
Синдәй Мәҗнүн җанлы хыялыйга
Ходай үзе бирсен сабырлык.
Хыялыннан киткән Җир йөзендә,
Тоеп торам, энем, авыр бик.
Туганчы ук тәкъдир язып куйган:
Шагыйрьләргә Җирдә гел кысан.
Хыял саклап яши алулары
Җиңел түгел, энем марсиан!
Без алдандык кайбер хыялларда:
Киләчәккә, алга барышта.
Китәбезме әллә, чигенү ясап.
Мин — Ямады,
Ә син — Марска?
Туган җирдә — хыял — баш очында,
Аяк аста — аңлаешлырак.
Анда — әнкәй кабере.
Туфрак — җылырак.
Кызыктырмый инде безне мираж —
Киләчәкнең балкышлары да,
Җаныбызда әрнеп яна әле
Остазларның ялгышлары да.
Гомумән дә, бүген бигерәк тә
Җырчы булып калу — читен ул...
Җир хыялын югалтмыйча гына
Ясыйк мәллә лирик чигенү?
Әмма шушы Җирдә туган өчен
Сөенеп кенә яшик, үкенмик,
Хыялларны тыеп, шунда калыйк,
Башка планетага сикермик!
Кайбер хыялларда чигенсәк тә,
Шигърияттә — тик бер карыш та!
Ялгышмаска, ялгышмаска иде
Киләчәккә, алга барышта...

*1991*

* *Марс* — Рәдиф Гаташ туган авыл.

* * *

Әллә нигә йөрәк яна бу айда...
Гармуннарым, уйныйм әле, сез кайда?
Күңел тоя гомеремнең баешын,
Өзим әле гармуннарның каешын!
Уйныйм яшьлек, уйныйм картлык көен дә...
Гармуннарның берсе дә юк өемдә.
Искә төште: дус-ишләрдә калдырдым,
Гармун уйнап күпме йөрәк яндырдым.
Дусларымны юатырга теләдем.
Инде тәмам янып бетте йөрәгем.
Бер гомергә җитәр, әйдә, калганы,
Кирәк түгел миңа дусның ялганы!
Ялгыз башың — калган җаның сүрелер,
Дуслар белән бер утыру — бер гомер!
Мин бәхетле: дуслар белән күрештем,
Үз моңымны кызганмыйча бүлештем.
Әллә нигә йөрәк яна бу айда,
Гармуннарым, киттем эзләп, сез кайда?
Өзим әле гармунымның каешын,
Онытырмын, бәлки, гомерем баешын...

*1991*

## Хәтерләү

Әллә инде сине өндә күрдем,
Әллә инде татлы төшемдәме?
Көнем дә син, төнем дә син, диден...
Исеңдәме, синең исендәме?
Әллә язның аяз иртәсендә,
Әллә язның тыныч кичендәме...
Бик кадерле бер сүз әйткән идең...
Исеңдәме, синең исеңдәме?
Саргаюлар нинди була икән,
Сары ромашкалар түсендәме...
Син дә, мин дә аерым саргаябыз...
Исеңдәме; синең исеңдәме?

*1991*

* * *

Тауның ташын алып китим мәллә?
Туган якны сагынып, кошлар сыман
Басып сайрармын,
Илгә илбасарлар явы килсә,
Кылыч кайрармын.
Тауның ташын алып китим мәллә?
Шул тарафтан искән җилләр аша
Хәбәр көтәрмен,
Бәла килеп, берчак утсыз калсак,
Чакма итәрмен.
Тауның ташын алып китим мәллә?
Үлем килгәч, туфрагыма шушы
Ташны куярлар:
«Җирнең моңлы бер баласы»,— дигән
Җөмлә уярлар.
Тауның ташын алып китмим инде...
Күтәрәлмәс авыр хәсрәт төште
Газиз башыма.
Таш куйдым да, әнкәй, баш куйдым мин
Каберең ташына.
Тауның ташын алып китмим инде...
Туган туфрагыңнан көчләр алып,
Сау булып калдың.
Гомерең буе таулар күтәрдең дә...
Тау булып калдың.
Тауның ташын алып китмим инде.

*1991*

# Шигырь кое

Әйт әле, ничек табасың
Шигырьнең ритмын-көен?

Уйга баттым авылымның
Саеккан инешендә.
Көй булып калган һәммәсе
Йөрәгем тибешендә.
Югалтмадым, сакладым мин
Инешем агышларын,
Шул сагышлардан башланды
Минем бар табышларым.
Сүзләремә көй биргәндер
Заманның уй-борчуы,
Зырлагандыр, җырлагандыр
Дәү әнинең орчыгы.
Дөньяга күзне ачкач та,
Әнкәм тирбәткән мине,
«Бәү-бәү» дигән иң беренче
Көйгә өйрәткән мине.
Адәм күргәннәрне күрде
Без — бала башлары да,
Мине көйләргә өйрәтте
Тегермән ташлары да.
Әле һаман күз алдымда
Сиртмәле кое тора,
Чыгырларның шыгыр-шыгыр
Шигырьдәй көе тора.
Тынды тегермән ташлары,
Сиртмәле кое да юк,
Әллә шуңа бу тормышның
Аһәңе, көе дә юк.
Тормыш чыгырдан ычкынды...
Кем уйлый — шул сызлана,
Тигез ритмнан ычкынды,
Йөрәгем көйсезләнә.
Ишетсәгез йөрәгемнең
Соң мәртәбә кагышын,
Шушы булыр төзәлмәслек
Иң зур ритмик ялгышым.

*1991*

* * *

Татарча туабыз.
Урысча «юабыз».
Урысча беләбез,
Урысча көләбез.
Урысча уйныйбыз,
Урысча уйлыйбыз.
Урысча кочабыз,
Урысча эчәбез.
Урысча үбәбез,
Урысча сүгәбез.
Урысча ашыйбыз —
Урысча яшибез.
Урысча җырлыйбыз,

Татарча елыйбыз,
Татарча үләбез.
Татарча күмәбез...

*1991*

# Йөрәге сызлаган дустыма

*В.Юныска*

Һәр хаксызлык өчен яндык-көйдек
Берәве дә бушка узмыйдыр,
Бу дөньяда йөрәксезләр бик күп,
Йөрәгебез шуңа сызлыйдыр.
Без сүнәрбез, янган йөрәкләрне
Аңлаучылар табылыр әле,
«Йөрәклеләр Җирдә бар иде!» — дип,
Тормыш безне сагыныр әле...
Сагыныр әле...

*1991*

## Аккан сулар, искән җилләр...

Туган җирләр,
Үскән җирләр,
Аккан сулар,
Искән җилләр.
Бәгыремә
Күчкән җирләр,
Аккан сулар,
Искән җилләр...
        Гомер моңын
        Сезгә көйләр
        Аккан сулар,
        Искән җилләр.
Узган юллар,
Тузган еллар,
Аккан сулар,
Искән җилләр.
Үткән таңнар,
Үпкән төннәр,
Аккан сулар,
Искән җилләр...
        Минем хәлне
        Сезгә сөйләр
        Аккан сулар,
        Искән җилләр.
Көткән ярлар,
Киткән көннәр,
Аккан сулар,
Искән җилләр.
Узган гомер,
Сүнгән көлләр,
Аккан сулар,
Искән җилләр.
        Гомер юлын
        Сезгә сөйләр
        Аккан сулар,
        Искән җилләр...

*1991*

# Аксакал нәсыйхәте

*Йөз чишмәле Кече Кирмән балаларына*

Көлгәндә дә чишмә кебек челтерәп,
Нәкъ татарча тыйнак көлегез,
Тәнгә-җанга сихәт-дәрман биргән
Чишмәләрнең кадерен белегез!
Дулкынланып, йөрәкләргә агып,
Үтсен сезнең һәрбер көнегез,
Күпме сәхра сусыз кибә, сула,—
Чишмәләрнең кадерен белегез!
Сусыз калсак әгәр, корыячак
Табигатьнең иркә гөле без,
Җилләр иссен, назлы гөлләр үссен,—
Чишмәләрнең кадерен белегез!
Их, яшисе иде озак, мәңге...
Табигатьтән башка үле без,
Кемдер, зарыгып, бер йотым су сорый,—
Табигатьнең кадерен белегез!
Изге чишмәләргә төкерсәк без,
Саегыр җан, корыр телебез,
Бездән соң да челтерәп-челтерәп калсын,—
Чишмәләрнең кадерен белегез!

*1991*

* * *

Ап-ак карга ятып бер елыйсы килә:
Күз яшьләрем туңып бозга әйләнсен лә...
Җылы өмет итеп бер сорыйсы килә:
«Минем хәлдә инде, дөнья, әллә син дә?»

Һаваларга менеп бер җырлыйсы килә:
Җанымдагы бозлар эреп түгелсен лә...
Шыксыз бу җиһанны матурлыйсы килә:
«Бөтен дөнья назга-язга күмелсен лә...»

Хыялымнан әкрен... әкрен генә сүнәм...
Җиргә төшәм горур башны түбән иеп.
Дөнья карый миңа үзе өмет белән:
«Суыттыгыз мине, кем җылытыр?..» — диеп.

*1991*

* * *

Тормышыңны матурлаган
Аккошың булалмадым,
Күңелеңне гел нурлаган
Балкышың булалмадым,
Хыялларыңда зурлаган
Саф кешең булалмадым.
Тел яшергән килен сыман,
Сак кеше булып калдым,
Хаким фикергә буйсынган
Вак кеше булып калдым,
Кара чәчләр арасында
Ак кеше булып калдым,
Шәфкатьсезләр дөньясында
Чак... Кеше булып калдым.

*1991*

# *Без*

Без ничек шәфкатьле булыйк,
Хөр җанлы, изге булыйк,
Без ничек көзге булыйк та,
Тәвәккәл сүзле булыйк?
Шунысы гаҗәп: бу дәһшәттән
Без ничек калдык әле...
Без бары тик изгеләрнең
Сау-исән калдыклары.
Бабайларны аттылар ич,
Әтиләрне яптылар,
Себерләргә озаттылар,
Нәселне тараттылар.
Без яшеннең үзе түгел,
Елдырымнары гына.
Без давылның үзе түгел,
Ком бураннары гына.
Болай читтән караганда
Сүнгәндәй күренәбез,
Нәсел яраларын бәйләп,
Бик әкрен терелобез.
Бик тирәнгә яшеренгән
Нәфрәт тулы сагышлар...
Кагылмагыз... Безме? Без ул —
Яралы юлбарыслар...

*1991*

## Өлкәнәйгән бер хис

*Р.М.*

Шулай, дустым, әле кичә генә
Бәләкәйләр идек, нәниләр.
Олыгаеп, бөкерәеп калдык
Ташлап киткәч безне әниләр.
Аңласа да безнең хәлне аңлар
Күз алдына китерүчеләр:
Тудыручы китте. Калды безне...
Әкрен-әкрен үтерүчеләр.
Шулай, дустым, без дә әкрен генә
Бу дөньядан китә барабыз.
Әллә шуңа, әллә шуңа инде
Хәзер, бигрәк моңлы бала без.
Өлкәнәйгән бер хис телә җанны:
Юкка гына тумадым микән,
Мин үзем дә әнкәемнең гомерен
Кыскартучы булмадым микән?..

*1991*

* * *

Аңа хәзер берни кирәк түгел,
«Саумы?»— диеп, бер сүз дәш аңа...
Синең күзләреңнән яшьлек ага,
Аның күзләреннән яшь ага.
Өмет өзәргә дә күптән вакыт,
Ярың — янда, үзең — яшь ана.
Синең күзләреңнән яшьлек тама,
Аның күзләреннән яшь тама.
Соңгы тапкыр өзелеп карый сиңа,
«Бәхил бул...»— дип, бер сүз дәш аңа...
Синең күзләреңнән яшьлек ага,
Аның күзләреннән яшь ага.

*1992*

## *Уйлыйсыздыр*

Уйлыйсыздыр: адәмнәргә шагыйрьнең үзе кирәк?
Юк! Шагыйрьнең, үзе үлгәч, даны һәм сүзе кирәк...

*1991*

* * *

Ычкынырмын, ахры, беркөнне мин
Җирнең серле тарту көченнән:
    йомшак җилдән,
    нечкә билдән,
    чәчәк исеннән...
Китәрмендер, ахры, беркөнне мин,
Ташлап китәрмендер барын да:
    якты кичләр,
    татлы хисләр,
    сөйгән ярым да...
Китәрмендер, ахры, беркөнне мин,
Онытырлар йөз яшь тулганда:
    газиз дуслар,
    явыз дошман,
    якын туган да...
Китүләргә кадәр бу дөньядан,
Җан шатлыгы белән тартылыйм:
    йомшак җилгә,
    нечкә билгә,
    искә-төскә,
    дуска-ишкә,
    тәмгә-ямьгә,
    тәнгә-шәмгә —
Ярсу дәртем белән атылыйм!

*1991*

## Кошлар юлы

Былбыл булалмадым дип тормадым,
Кошлар юлын сайладым,—
Таң алдыннан өзелеп бер җырладым —
Күңелем тулып сайрадым.
Мин дә сезнең кебек газапланам,
Кошлар, гаеп итмәссез,
Яз таңында мин дә канатланам,
Бәлки, ташлап китмәссез?..
Күрешербезме, юкмы бу дөньяда?
Анысы — язмыш кулында...
Очрашасы иде Мәңгелектә —
Ерак кошлар юлында...

*1991*

## Хәсрәтле җыр

Минутлап, сәгатьләп
җыелган гомеремнең
белмәдем кадерен,—
син хаклы, бәгырем...
Минутлап, сәгатьләп
сүтелгән гомеремнең
йомгагы шул булды:
йөрәгем — көрәшче,
кул-аяк — кол булды...
Минутлап, сәгатьләп
таралган гомеремнең
хәсрәтле азагын
коллыктан ычкынган
кул белән язамын...

*1991*

## Кайчагында

Суыткыч та булмас инде шулкадәре:
Боз шикелле салкынсың син кайчагында,
Эретәсем килә кайнар кочагымда...
Бик сөйкемсез күренәсең боз чагында,
Кил, җаныем, яндырыйм бер кочагымда,
Синнән гүзәл кызлар булмас шул чагында...

*1991*

* * *

Тормыш бит ул: барысы да булгандыр...
Гөнаһлармы? Анысы да булгандыр.
Мәхәббәттә бераз гына наян мин:
Алдадым һәм... үзем күбрәк алдандым.
Мин алдаган кызлар, бәлки, кичерер,
Татлы Айлы төнне искә төшерер.
Бераз гына алдасам да азмадым,
Мәхәббәттән алдым язмыш язганын.
Хәзер, тәүбә, алданмыйм һәм алдамыйм,
Гөнаһлардан инде тыныч ялда мин.
Сагындыра тәмле төннәр, «аһ-вах!»лар...
Сөйгән ярлар кичерерлек гөнаһлар...

*1991*

# *Акланма, шагыйрь...*

«Аның рәсемен хәзер, үкси-үкси,
Кара тасма белән үрәмен».

*«Яшь сталинчы», 1953*

Башкалардан аерылмадым,
Башкалардан калмадым,
Коточкыч тиран икәнен
Соң булса да аңладым...
. . . . . . . . . . . . . . . . .
Акланма, шагыйрь, патшага
Баш ию — оят, гарьлек.
Шигырь язу гына җитми,—
Шагыйрьлек — пәйгамбәрлек.

*1992*

# Мин нигә гафил булдым?

Комда — ишәк,
Чүлдә — дөя,
Эш аты йә фил булдым,
Адәм булып тусам да мин,
Илемнән гафил* булдым.
Илдә — урыс,
Чүлдә — үзбәк,
Йаурупада — фин булдым,
Татар булып тусам да мин,
Телемнән гафил булдым.
Болгарда — гөл,
Рәсәйдә — кол,
Казанда мин көл булдым,
Җиде бабамнар төзегән
Дәүләттән гафил булдым.
Җырда — бөек,
Моңда — боек,
Дастаннарга тиң булдым,
Алыплардан тусам да мин,
Тарихтан гафил булдым.
. . . . . . . . . . . . . . . . .
Әйтерме бер күреп, җиһан:
«Бабаңнарга тиң булдың!»

*1992*

* *Гафил булу* — мәхрүм булу, сизми калу, абайламый калу.

# Ул үткән юллар

Киләчәк өчен
Булсын дип көчем,
Сахралар кичтем, далалар үттем.
Маңгайда сырлар...
Мин үткән юллар:
    Кылдан нечкә, кылычтан үткен.
Тузды чәчләрем,
Кипте яшьләрем,
Зәһәр җилләрдә какланып беттем.
Дәһшәтле еллар...
Алдымда — юллар:
    Кылдан нечкә, кылычтан үткен.
Арды атларым,
Җәяү атладым,
Күкрәгем белән шуышып киттем,
Яшьләр, түзегез,
Булса сүзебез
    Кылдан нечкә, кылычтан үткен.
Картлык көнемдә,
Туган илемдә
Көрәштән арып, тыныч ял көттем.
Болганчык чорлар...
Томанлы юллар
    Кылдан нечкә, кылычтан үткен.
Дөнья, куркытма,
Читлектә тотма,
Сират күперен мин инде үттем.
Күңелем, өзелмә,
Инде үзең дә
    Кылдан нечкә, кылычтан үткен...

*1992*

* * *

Безме? Без — ул яшь чакларда
Җирне туп итеп ордык,
Айга да шлем кидердек,
Кояшны буйсындырдык,
Барабан һәм күкрәк кактык:
«Килсә дошман теш кайрап,
Бездә, бездә — бүрек белән
Бәреп егарлык гайрәт!»

...Хәзер: «Ярый, Кояш бар!..» — дип,
Сөенеп уянабыз,
Шлемсыз гына йөрүче
Айдан да оялабыз.
Дошманнарым, кызганасыз
Безнең хәлне күреп сез.
Өлкәнәйдек, калдык хәзер
Ыштансыз һәм бүрексез.
Бу тормышны, табигатьне
Хәзер ничек көйләргә?
Калсын безнең җүләр яшьлек
Гыйбрәт итеп сөйләргә...

*1992*

* * *

Ник тыйнаклык? Яшермим дә мин аны:
Миндә Такташ, миндә Туфаннар җаны.
Мин дә бит хаксызлыкны яратмадым,
Мин дә... алар ялгышын кабатладым.
Кабатлый алмадым тик талантларын.
Китәр идем изгеләр дөньясына,
Җигалсам Тукайның «Пар ат»ларын...

*1992*

## Кайда минем утлы төннәрем?

Үрләрем...
Бала чакта сезгә үрләдем.
Үзләренә мине тарта иде
Күзге кебек көмеш күлләрең.
Үрләрем...
Иркәләде җылы җилләрең.
Учак ягып без яктырта идек
Туган якның зәңгәр төннәрен.
Үрләрем...
Ачтың биеклекнең серләрен.
Авыр мәлләрдә дә сүнми яндым,
Төнге учак кебек дөрләдем.
Үрләрем...
Кайттым, ләкин сезне күрмәдем.
Күрдем бары актарылган җирләр,
Хыялымның янган көлләрен.
Үрләрем...
Нигә хәлләреңне белмәдем?
Кинәт үзем түбәнәеп калдым.
Кайда минем утлы төннәрем?..

*2002*

* * *

Шатлыкларым чиксез: йөрим очып,
Бәхетемнән шашкан төслерәк...
Олы бәйрәм ясыйм микән әллә?
Әйтте акыл: «Тукта, сөенечең
Халкың шатлыгыннан кечерәк...»

Кайгым тирән минем, ай-һай, тирән —
Тып-тын төпсез дәрья төслерәк...
Шул дәрьяга батыйм микән әллә?
Әйтте йөрәк: «Тукта, хәсрәтләрең
Халкың кайгысыннан кечерәк...»

*1992*

# Сораулар

Мин туганда гел-гел өндәү иде:
«Алга! Алга! Юллар салынган!»
Әйтерсең лә барлык сорауларның
Җаваплары бездә табылган.
Шул хыялга наив ышандым да
Якты киләчәккә өндәдем,
Өндәүләрнең сорау билгесенә
Әйләнәсен ул чак белмәдем.
Эчтән янып, тыштан сиздермичә,
Шул сораулар эчтән кимерде.
Өндәүләрнең ялганлыгын тоеп,
Мин ябыктым, алар симерде.
Күзләремдә минем — халык гаме,
Йөзләремдә минем — ил төсе,
Кайчан гына төп-төз өндәү идем,
Хәзер гәүдәм — сорау билгесе.
Бернәрсә дә миннән сорамагыз,
Үземдә дә бик күп сораулар...
Шул сораулар тузган йөрәгемне
Гомерем буйларына бораулар.
Беләм, берчак китеп югалырмын,
Сорауларга җавап табалмам.
Мин китәрмен, ә сораулар калыр...
Дөнья сораулардан яралган.

*1992*

## Яңавыл әтәче

Әтәчләрең иртә таңда уята,
Ике сәгать мине алда уята.
Әткәм-әнкәм төшкә кереп уята,
Авыр чакта киңәш биреп уята.
Дәү әнкәем дога укып уята,
Ата казың талап-чукып уята.
Назлы җилең чәчтән сөеп уята,
Поездларың: «Кайт! Кайт!» — диеп уята.
Сандугачың таңны сайрап уята,
Егетләрең чалгы кайрап уята.
Гүзәлләрең суга китеп уята,
Шоферларың «сулга» китеп уята.
Жуликларың төнлә талап уята,
Акбайларың кулны ялап уята.
Бураннарың адаштырып уята,
Хаталарым саташтырып уята.
Әтәчләрең иртә таңда уята,
Ике сәгать мине алда уята.
Рәхмәт уяу әтәчеңә, уята,
Алып кайта, елата да... юата...

*1992*

* * *

Куларбамны тартып узган чакта,
Бөкерәеп, алга сузылып,
Икешәр дә өчәр машиналы
Күршеләрем кала кызыгып.
Берни дә юк, дисәм, ышанмаслар:
Нәрсәдер бар минем арбамда.
Бизнесменнар кызыгып карап кала,
Мин урамнан үтеп барганда.
Ике-өчәр дачалары булган
Танышларым туктап юл бирә,
Халык арасында очрашканда,
Ил башлары хәтта кул бирә.
Эшкуар да, җилкуар да түгел,
Хәерче дә түгел, мескен дә...
Миллиардерлар, минем хәлдә булса,
Яши алмас иде өч көн дә.
«Мерседес»та йөргән танышларга
Хәерле юл теләп каламын,
Урам чатындагы ятимнәргә
Хәл кадәри хәер саламын.
«Арган, ахры»,— диеп уйлыйлардыр,
Адым саен туктап калганда,
Бик авыр да, бик җиңел дә түгел,—
Нәрсәдер бар минем арбамда.
Өметләнеп карап кала миңа
Ачлар, ялангачлар салкында:
«Нәрсә икән серле ул арбада?»
Юк, көмеш тә түгел, алтын да...
Урам ташларыннан әкрен атлап,
Тоеп барам заман агышын,
Сыгылам да кайчак, бөгеләм дә,—
Төяп барам заман сагышын.
Куларбамны тартып узган чакта,
Ник калалар, дисәм, кызыгып.
Күкрәгемнән тулып, ташып чыккан
Җырым кала икән сызылып...
Үз юлымнан читкә каерылмам! —
Кая юнәлсәм дә — юл ачык.
Җырым минем һич бетәрлек түгел,
Куларбамда гына — бер капчык!

*1993*

## Янган чәчәк

Кара җаннар
Үч йөрттеләр,
Төнләй өйгә
Ут төрттеләр.
Кайда минем
Янар чәчәк,
Күзләремә
Карар чәчәк?
Исә зәһәр
Җилләр генә,
Нигеземдә —
Көлләр генә...
Янган бакча,
Янган чәчәк,
Ут эчендә
Калган чәчәк.
Хәлсез башны
Ташка салдым,
Үзем әле
Исән калдым.
Янган чәчәк,
Көйгән чәчәк,
Мин өзелеп
Сөйгән чәчәк.
Йөзләремдә —
Көл төсеме,
Янган чәчәк
Шәүләсеме?
Янган еллар —
Янган чәчәк,
Ут эчендә
Калган чәчәк.
Ут — тышымда,
Ут — эчемдә,
Янам-яшим
Ут эчендә.
Янган гомерем —
Янган чәчәк,
Ут эчендә
Калган чәчәк.

Юк, барыбер
Калкырмын мин,
Көл эченнән
Балкырмын мин.
    Булсам да мин
    Янган чәчәк,
    Ут эчендә
    Калган чәчәк!
Юк, сулмамын,
Балкырмын мин,
Таш астыннан
Калкырмын мин!

*1993*

* * *

Җир йөзендә тәүге тапкыр
Шигырь туганнан бирле,
Шагыйрьләрне юк итүнең
Ысулы төрле-төрле.
Мәкер-яла беләп урау,
Кисү, асу, яндыру;
Йөрәгенә төбәп ату,
Йортсыз-җирсез калдыру.
Гөлдәй сулганнар азмыни
Зиндан эчендә ятып,
Бу дөньядан киткәннәр бар
Үз-үзен асып, атып...
Пулясыз-нисез яралап,
Газапка дучар итеп,
Түшәгендә сүнгәннәр бар
Туксан — йөз яшькә җитеп.
Үкенечкә җыры кала...
Якты, моңлы, борчулы.
Җан авазын юк итүнең
Юк бернинди ысулы!

*1993*

* * *

Кагылма, зинһар, ярама,
Ул хакта сүз кузгатма,
Төзәлмәслек җәрәхәткә
тоз атма...
Сулкылдар инде йөрәгем
Азга түгел, озакка,
Әрнесен, янсын, дөрләсен,—
боз атма...
Үз хәлемне үзем беләм,
Сабырлыгым — йозакта.
Җаным — яшьлек ялгышында —
тозакта.
Әрнүләрем — гомерлеккә,
Бер генә дә сүз әйтмә.
Сорыйм: калдыр ялгызымны,—
озатма...

*1993*

* * *

Мин фәрештә түгел, бераз
Шәрабын да каптым,
Яшьлегемдә адашып та йөрдем,
Гөнаһка да баттым.
Юк, шайтан да түгелмен мин,—
Әйттем исә кайттым,
Аның коткысыннан китеп,
Үз юлымны таптым.
Язмыш мине авыр юлда йөртте,
Уттан суга салып,
Үрнәк түгел, миннән була —
Бары гыйбрәт алып...

*1993*

## Җан юлдашым

Ягып яшьлек учакларын,
Башладык бит без юл башын,
Гомерлеккә кочакладым,
Җан юлдашым, җан юлдашым.
Син кабызган ут булмаса,
Нишләр идем ялгыз башым,
Юллар бергә узылмаса,
Җан юлдашым, җан юлдашым.
Ни күрсәк тә бергә күрик,
Кайнар яшьлек озата барсын,
Сүнгәндә дә бергә сүник,
Җан юлдашым, җан юлдашым...

*1993*

# Читләрнең үз бәясе

> «Татарлар елмаеп үлделәр...»
>
> *Р.Ланфридини*

> «Иң башта Корьәнне Алишка суздым... Ул, акрын гына торып, кулын Корьәнгә салды һәм елап җибәрде...»
>
> *Госман мулла истәлегеннән*

«Татарлар үлде елмаеп...»
Читләрнең үз бәясе.
Биш минуттан — гильотина,—
Килерме елмаясы?
Таш бәгырь булу мөмкинме
Әҗәл янда дәшкәндә,
Милләтнең изге китабы —
Корьән бәхилләшкәндә?
Киткән алар — бу дәһшәткә
Түзәргә кирәк ничек? —
Читләр алдында — елмаеп,
Корьән алдында үксеп...

*1993*

* * *

Мин гашыйкмын, юллардагы
Карларга гашыйк,
Язлар килсә, елгадагы
Ярларга гашыйк,
Яр буенда дулкынланган
Талларга гашыйк,
Салмак агып, уйга салган
Салларга гашыйк,
Салларга карап калучы
Ярларга гашыйк,
Шушында бәхет табучы
Парларга гашыйк,
Сүнгән дәртне уятучы
Таңнарга гашыйк,
Табигатьне яратучы
Җаннарга гашыйк...
...Күзәт мәңгелек агышын,
Ярларга басып,
Гүзәл мизгелләр сагышын
Карарга ашык...

*1993*

* * *

Минем юаш табигатем
Сезгә бик ошый кебек...
Сез — бүреләр арасында
Мин яшим поши кебек.
Тик белегез: мин бик сизгер,
Тиз генә тоталмассыз,
Тешегезгә эләксәм дә,
Кабарсыз, йоталмассыз!
Сез йөрисез өер белән.
Мин бит үзем... берүзем...
Йоталмассыз, җирдә калыр
Сөзә торган мөгезем!

*1993*

## Оялдым

Үзем өчен генә түгел,
Читләр өчен оялдым,
Кеше өчен генә түгел,
Этләр өчен оялдым.
Үзем оятка калдырган
Нәсел өчен оялдым,
Тукай, Такташлардан узган
Яшем өчен оялдым.
Мине оятка калдырган
Әрсезләрдән оялдым,
Оят тойгысын белмәгән
Мәнсезләрдән оялдым.
Әрсез, мәнсез таптап китте...
Оялудан уяндым.
Оятсызга калкан итеп
Күкрәгемне куярмын!
. . . . . . . . . . . . . . .
Хәзер инде элеккечә
Яшәвемнән оялдым.

*1993*

* * *

Бәла-каза арттан ияреп йөри,
Кайчак көтеп тора алда ук...
Гомер буе мин яшәгән булдым
Бәхет килер, диеп алданып...
Гел ышанып, гел алданып яшәү
Газапларны бераз киметкән.
Шул чорымны кайчак сагынып куям...
Тик үзем дә белмим... нилектән?
Хәсрәтләрем бераз кимер иде
Үзем генә булсам бәхетсез,
Ничә гасыр буе көрәшеп тә,
Милләттәшләр һаман тәхетсез.
Ышанмыйм да инде, алданмыйм да...
Газапларым шуңа артадыр,
Бабамнарның ватык тәхетләре
Аның саен ныграк тартадыр...

*1994*

* * *

Нишлисең бит, күз өстендә
Каш булалмадым инде,
Кемнәргәдер ату өчен
Таш булалмадым инде,
Гөнаһларымны яшердем,
Фаш булалмадым инде,
Каруннарның карынына
Аш булалмадым инде,
Рухи яктан бай яшәдем,
Ач булалмадым инде,
Хисләр җиңде, акылыма
Баш булалмадым инде...

*1994*

* * *

*Ф.Г.*

Мәҗлестән соң бераз гына кыздык...
Кочакларда — гармун.
Төнге шәһәр буйлап җырлап уздык:
Актарылды — бар моң.
Исерекләр, зурлап, кул бирәләр,
Айнып, туктап калып,
Хулиганнар, җырлап, юл бирәләр:
«Тимә, безнең халык!»
Бу урамнан төнлә беркем йөрми,—
Хуҗа монда — хәмер.
Без узганда усал этләр өрми...
Ачыл, басыл, бәгырь!
Изү чишеп, мин дә җырлап киләм.
Йөрәкләрдә — давыл.
«Баламишкин» булып, ярсу белән
Тибә җанда — авыл.
Мин дә сездән аерылып тормыйм,
Сукбай, сәрхуш җаннар...
Кочаклашып, үксеп-үкереп җырлыйм:
Безне кемнәр аңлар?!

*1994*

* * *

Хакыйкатьне тулы ачалмыйча,
Шигъriяттә гомер уздырдык.
Канга гына түгел, җанга сеңгән
Курку, үз-үзеңә цензорлык.
Бик күп серләр яшеренеп кала,
Хаталарым, ялгышларым да...
Нидер кала барыбер ачылмыйча
Җанның тирән агышларында.
Шигыремне укып баручылар,
Сизәм, миннән күбрәк көткәндер.
Ябылуын, анысы, ябылмамын,
Тик бөтенләй ачылып бетмәмдер...

*1994*

* * *

Беркатлы дип уйламагыз,
Мин бәйле күпләр белән,
Чүпләр белән генә түгел,—
Җиде кат Күкләр белән.
Җиде төн урталарында
Уяткан көчләр белән,
Салават күперендәге
Җидегән төсләр белән.
Илаһым, и коткар мине:
Көннәр һәм төннәр белән
Сугышам Күктән сөрелгән
Иблисләр-җеннәр белән.
Бер тамчы шатлык китерсәң,
Бүлештем күпләр белән.
Ник төядең йөрәгемә
Газабын йөкләр белән?
Чикләнсә дә бу яшәвем
Бикләр вә чикләр белән,
Кыска гомремне бәйләдем
Илаһи Күкләр белән.
Китәрмендер Мәңгелеккә
Үпкәләр-шикләр белән,
Җирдә аңлаша алмыйча,
Беркатлы күпләр белән...

*1994*

* * *

Хәерче, гарип-гораба...
Кем генә юк урамда...
Хәер бирергә омтылып,
Кесәмә тыгылам да...
Кулны кире тартып алам.
Сез өмет иткән кеше —
Ул да Казанның билгеле
Рухи бай хәерчесе.
Кесәләр буш... Күңелем хуш...
Акчасыз-нисез җырлыйм.
Гармун уйнап, бүрек тотып,
Урамда гына тормыйм.
Юбилейга бүләк булган
Тунымны киеп йөрим.
Салкында туңып утырган
Баланы сөеп йөрим.
Мин дә заман байларына
Кызыгып карап калам.
Кил әле, кер тун эченә,
Кил, жылын, таҗик балам...
Бу бабагыз — пенсиядә.
Йөрергә вакыты бар.
Илдән, Җирдән куылмаган,—
Бер генә бәхете бар...

*1994*

* * *

Бала чагымда очындым
Бөркет кыяларында,
Күкнең җиденче катына
Очтым хыялларымда.
...Күтәреләм баскычлардан...
Авыр... кысыла сулыш...
Өйнең җиденче катына
Күтәрде мине тормыш.
Чыгам да карыйм балконнан:
Бер аска, бер Күкләргә...
Карыйм, кызганып, оялып,—
Оясыз «бөркет»ләргә...

*1994*

* * *

Таныш, үземнең җырымны
Ишеттем әллә каян...
Ватан сугышы гарибе...
Кулына тоткан баян.
Күкрәгендә — медальләре,
Алдында — кәләпүше.
Синме соң бу иң-иң явыз
Дошманны җиңгән кеше?!
«Без көчле!» дип язган шагыйрь —
Ярдәм итәлмим мин дә.
Җырым да мохтаҗ ярдәмгә
Шушы хәерче илдә.
Берни юк... Заман җилендә
Чалланган ак башым бар.
Шушы хәлләрдә калуда
Минем дә катнашым бар...

*1994*

# Китү

Кирәк сүзебезне,
Йөрәк сүзебезне
Әйтеп китик, аннан соң була...
Кояш нурын сибәр,
Күздән яшьләр кибәр,
Без китәрбез әкрен, тын гына...
Күзгә карап куллар кысышканда
Әйтелгән сүз ихлас, чын була.
Таңнар сызылып калыр,
Җаннар өзелеп калыр,
Без китәрбез әкрен, тын гына.
Юксынсагыз безне,
Суытмагыз эзне,
Йөрәк сүзе бары шул гына.
Кырлар, җир-су калыр,
Җырлар моңсу калыр,
Без китәрбез әкрен, тын гына...

*1994*

* * *

Мине дошман күргән кешеләргә
Озын гомер телим, тыныч төн.
Мин үзем дә сезнең белән бергә
Озак яшәргә дип тырыштым.
Мине дошман күргән кешеләргә
Яхшы күрше телим, якты йөз...
Башкаларны нурландырып торсын
Үзегездән төшкән яктыгыз.
Мине дошман күргән кешеләргә
Әйбәт кәеф телим, көләч көн...
Һәм ышанам яфрак яруына
Җаныгызда шушы теләкнең...

*1994*

* * *

Такташ җене, Такташ рухы синдә,
Ашкынулы, тиле романтик...

*Сибгат Хәким*

Кайтып килә Кояш баешыннан,
Тиле романтикасын озаткан.
Ачу-нәфрәт белән чынбарлыкка
Каршы барып, туры сүз әйткән.
Кырыс йөзләрендә матәм эзе,
Хыялларын күмеп ул кайткан.
Романтикасы. Күктән егылып төшкән,
Рухи юлдашларын югалткан.
Кояш чыгышыннан берәү килә,
Оныткан ул Күккә ашуны,
Ул каһкаһә белән усал көлә,
Кемнәргәдер бик тә ачулы.
Сез көтмәгез инде, йомшак җилләр,
Кабат кайтмас хыял иленә.
Атлап бара янган битен куеп,
Замананың каршы җиленә.
Йөзләрендә — хыял күләгәсе.
Ул үзгәргән, әмма таныплык.
Күпләр, бәлки, аны ят итәрләр,
Күкләр бирсен аңа сабырлык!
Кайчан гына, кайчан гына әле
Юлы янар чәчәк иде бит...
Хәтерләгез аны «яшь җаннарның
Шашкын романтигы иде» дип.
Югалтмагыз, Кояш белән батып,
Кояш белән бергә кайтыр ул.
Такташларның әйтми калган сүзен
Әйтми калмас, барыбер әйтер ул!

*1994*

* * *

Чыгармыйм күз яшьләрен мин,
Чыгармыйм,
Еламыйча яшәрмен мин,
Чыдармын.
Елар идем, күз яшьләрен
Кем сөртер?
Әнкәем юк, бәлки, искән
Җил сөртер...
Сабый чакта татлы яшьләр
Коелган,
Мин — нарасый — әнкәемә
Сыенган.
Шәфкать сорап булмый хәзер
Яшь белән,
Яшьләремне хәтта җилдән
Яшерәм.
Яшь коюдан күңел барыбер
Бушанмый,
Әнкәйләрдән башка беркем
Ышанмый.
Кызганычлар болай да күп —
Ил белән.
Яшем чыкса, очсын кырыс
Җил белән.

*1994*

* * *

Авырлыклар тулы бу тормышта
Бер җиңеллек булсын, дисеңме...
Бик иркәләп, бик кадерләп әйттең
Назга тансык минем исемне.
Шул сүзеңнән канатландым әле,
Җанда тоям рәхәт җиңеллек,
Бу дөньяда яшәү бик-бик авыр,—
Синең белән яшәү — җиңел бик.
Әйдә әле, үпкә, ачуларны,
Хәтер калуларны онытып,
Салкын мәңгелектә югалганчы,
Яшик бер-беребезне җылытып...

*1995*

## Кешене иярткән этләр

Кая таба бара дөнья,
Их, егетләр, егетләр?
Шәһәр тулы, урам тулы
Кеше иярткән этләр...
Этләр, бәйдә булсагыз да,
Шомга салып барасыз.
Миңгерәгән адәмнәрне
Кая алып барасыз?

*1995*

# Бурлаклар

Идел буендагы бурлаклардай,
Тормыш йөген тартып барасың.
Хәлдән таеп арып каласың да
Сүгенәсең туктап: «Анасын!..»
Бар да, бар да халык җилкәсендә:
Кемнәр генә анда менмәгән...
Миллион — өзелә-сузыла аркан тарта,
Кәеф-сафа кора — мең адәм.
Мин дә тарттым алар пароходын,
Мин дә бераз гына бурлакмын.
Гамьсезлегем шулай арта-арта,
Яшьлегемне иртә югалттым.
Бар да, бар да халык җилкәсендә,
Бик соңарып шуны аңладым.
Мин акчарлак булып күтәрелдем,
Бурлаклардан һаман калмадым.
Акчарлакның ачы авазларын
Тыңлый-тыңлый, халкым, уйлап бар:
Өзелерме аркан йә түземлек, —
Булырбызмы мәңге бурлаклар?..

*1995*

* * *

Олы җанлы шагыйрь-әдипләргә
Үз илендә яшәү читен лә.
Тукай кебек яшьли гүргә китә
Йә Исхакый кебек чит илгә!
Хакыйкатьне төшендерә алмый,
Кадер-хөрмәт күрми китәләр.
Исән чакта үзен аңламаган
Халыкны да бөек итәләр.

*1995*

* * *

Әзерлиләр заман давылының
Җимергеч зур хәрабәләрен...
Бик сагындым инде авылымның
Сандугачлы әрәмәләрен.

Әллә җаным тарткан туган якның
Кошы булып кына сайрыйсы?
Әллә инде Ирек дошманына
Калкан булып, кылыч сайлыйсы?

Ишетерсезме соңгы җан авазын
Әрәмә йә мәйдан ягыннан:
Шатлыктанмы әллә ярааданмы
Сандугачның җаны ярылган?..

*1995*

* * *

Ул даһины исән вакытында
Нигә, нигә сакламадык соң,
Җаны рәнҗетелгән, туңган чакта,
Нигә, нигә якламадык соң?
Читкә сөрелгәнгә, кагылганга
Ярдәм кулы сузу — бик кирәк...
Хәзер — һәйкәл... чәчәк, алкыш, хөрмәт...
Җылы караш ташка ник кирәк?

*1995*

# Үзгәрәм

Мин элекке түгел инде,
Үзгәрдем.
Бик әз күрәм, нуры сүрән
Күзләрнең.
Мин элекке түгел инде,
Үзгәрдем,
Дуслар сизә йомшаклыгын
Сүзләрнең.
Дошманнарга карата да
Үзгәрәм:
Таш урнына шигырь белән
Сүз бәрәм!

*1995*

## Сагышлы мирас

Булганбыз без эре халык, тере халык.
Гасырларны кичә-кичә вакланганбыз.
Ваклансак та, без һаман да рухи Алып:
Тукай булып, Сәйдәш булып сакланганбыз.
Ни әйтсәң дә, Алыплардан яралганбыз.
Шул нигездә торасыбыз, корасыбыз.
Чәчелгәнбез, сибелгәнбез, таралганбыз.
Бабайларның бик сагышлы мирасы без.
Алып бабай тубалыннан чәчелгәнбез.
Үсмәсен дип, чирү булып килгән ятлар.
Өзелмәслек тамырдан без, нәселдән без,
Җанга сеңгән моңсу җырлар, риваятьләр.
Ак син, җырым, Әтил сыман дулкынланып,
Тыңла, бала, шул дулкынны уйга талып.
Бабаң менгән рухи үрдән төшә күрмә.
Төшә күрмә, Алыплардан калган халык!

*1995*

* * *

Указлы шагыйрь булганчы,
Указлы мулла булсам,
Бәлки, деннән язмас идем,
Гел изге юлда булсам.
Соң аңладым илһамымның
Күкләргә бәйләнгәнен,
Илаһи шагыйрь икәнен
Мөхәммәт пәйгамбәрнең.
Шик ярала иң-иң тирән
Җирендә күңелемнең:
Табигатьнең бик үк камил
Баласы түгелмендер...
Рәхмәт, Тәңрем, әле дә мине
Бу җирдә Адәм иттең.
Тик кызганыч, гомеремне
Заяга әрәм иттем.
Үкенсәм дә артта калган
Имансыз елларыма,
Сыялмыйм шул Мөхәммәтнең
Катгый кануннарына.
Указлы шагыйрь булганчы,
Указлы мулла булсам,
Бәлки, деннән язмас идем,
Гел изге юлда булсам...

*1995*

* * *

Үз теләгем белән бу дөньяга
Килмәгәнмен,
Табигатькә кирәк булганмын,
Якты җиргә сөенеп бага-бага,
Көлмәгәнмен,
Сөрән салып елап туганмын.

Үз теләгем белән бу дөньядан
Китмәмендер,
Олуг көчне зурлап китәрмен.
Чиксез яшәтүне Җир-Анадан
Көтмәмендер —
Илаһи моң тыңлап китәрмен.
...«Юктан бар иттең,— дип,—
Бардан юк иттең...»,— дип,
Тып-тын гына җырлап китәрмен...

*1995*

* * *

Әллә инде Күктән иңгәнгәме:
жырда — илһам,
тылсымлы көч,
ашкын хыял,
серле хис...
Күкне Җиргә тоташтырган
моң күпере — җиде төс...

Әллә Җир туфрагын сизгәнгәме:
жырда — шатлык,
кайгы-хәсрәт,
омтылыш,
яшәү көче...
Күктән куылган Адәмнең
мәңгелек үкенече...

*1995*

* * *

Искитәрлек булмаса да,
Башымда акылларым,
Чит итмәде, якын күрде
Дусларым, якыннарым.
Йолдыз алып кайтам, диеп,
Күкләргә атылмадым,
Йөрәк кушканча яшәдем:
Сатмадым, сатылмадым.
Белсәм дә рәхәт яшәргә
Өлешем-хакым барын,
Читләтеп үттем дөньяның
Көмешен-алтыннарын.
Башкортларның сәсәннәрен,
Казакъның акыннарын
Юлдаш иттем. Юлбаш иттем
Йөрәгем ялкыннарын.
Әкрен генә сөйләдем мин,
«Тыңла!» — дип акырмадым.
Ишетте ерак тарафлар,
Үз итте якыннарым.
Искитәрлек түгел дә соң
Башымда акылларым...
Әүлия үк булмасам да,
Дәрвишләр затыннанмын...

*1995*

# *Иярләштек...*

Иярләштек илне-җирне
Талауга,
Үзебезне кол түгел дип
Санауга.
Иярләштек налогка йә
Ясакка,
Туган җирен ташлап киткән
Качакка.
Иярләштек җимерүче
Хакимгә,
Урамдагы кулын сузган
Ятимгә.
Иярләштек туп атуга,
Кан, утка,
Әнкәсенә кайткан кургаш
Табутка.
Иярләштек, тешне кысып,
Дәшмәүгә...
Иярләштек әнә шулай
Яшәүгә.
«Йом күзеңне, күрмә күпне,
Бул тыныч...»
Менә шулай яшәү — үзе
Куркыныч...

*1995*

* * *

Озын төннәр йокламадың,
Күзләреңне йоммадың.
И эрләдең, и эрләдең
Гомереңнең йомгагын.
Бәйләп бардың ялганганын,
Читкә аттың ялганын.
Өзеп ташлый алмаганын —
Нишләтерсең калганын?
Җиңел генә чиштең кебек
Катмарлы төеннәрен,
Юкка гына түгел микән
Чиштем дип сөенгәнең?
И бәйләдең, и бәйләдең
Утырып, боек кына.
Әллә инде бәйләгәнең
Бияләй, оек кына...
Көндезен дә, төннәрен дә
Тырышып, онытылып,
Ни эрләдең, ни бәйләдең
Җаннарны җылытырлык?

*1995*

## Илһамга ничә яшь?

Илһам Шакировка ничә яшь соң?
Нинди уйлар аның башында?
Халык яшәгәндә яшәр моңы,
Илһамыбыз — халык яшендә.
Борынгы да үзе... Киләчәк тә...
Тоям шул чишмәнең кипмәсен.
Һәр кешенең йөрәгенә һәр көн
Илһам килсен,
Илһам китмәсен!..

*1985*

# *Без*

«Без һәммәбез Гогольнең
«Шинель»еннән чыктык...»

*Дәресләрдә еш кабатланган тәгъбир*

Сез шулайдыр, ә без — башкачарак,
Ертык ыштаннардан атлап киттек.
«Туган тел»ле Казаннарга карап,
Такташ «Мокамаен» ятлап киттек.
Без Гогольнең «Шинель»еннән түгел,
Әтиләрнең шинеленнән чыктык.
Корчагиннар сезгә яттыр бүген,
Ә без «корыч булып чыныктык».
Павел Морозов та үрнәк иде...
Шәп анадан, шәп атадан чыктык.
Без тормышка (кырыс сабак бирде),
Үзебез үргән чабатадан чыктык.
Заман безнең үзәкләрдән үтте,
Назламады рәхәт тынычлыкта.
Корал биреп, походларда йөртте.
Ярап куйды кайчак корычлык та.
Тимер иләк аша чор үткәрде.
Бик аз калган буын — нәселле без.
Яшерсәк тә яра авыртканны,
Күңел йомшаклыгын яшермибез.
Гел-гел хәсрәт диңгезендә йөзеп,
Әллә бабайларның каны күчкән:
Күнеккәнбез кайгыларга түзеп,
Елыйбыз тик шатлык-сөенечтән...

*1995*

## Сөембикә манарасы янында

Тарих серенә төшәргә
Омтылган борау кебек,
Хәлсезләнеп башын игән
Авыр бер сорау кебек.
Кем гаепле? Кайчан? Нигә
Манарабыз авышкан?
Урын сайлаганда әллә
Коручысы ялгышкан?
Узганнарга тарта уйны
Тансык азан тавышы.
Тынгылык бирми күңелгә
Манараның авышы.
Янтайганмы күпме еллар
Иманы-нуры юкка?
Барсына да шаһит бит ул:
Хыянәт, тугрылыкка...
Бердәмлектә, татулыкта
Башкадан калыштыкмы?
Манара белән бергәләп
Үзебез авыштыкмы?
Иелдекме, бөгелдекме
Миһербансыз алыштан?
Омтылабыз төзәтергә —
Тарихыбыз авышкан.
Шәһитләрнең кан-яшьләре
Өстебезгә яумасмы?
Манарабыз турыланыр,
Милләт үзе аумасмы?..

*1995*

* * *

Барабыз вагон эчендә
Тел яшереп һәм тынып.
Үзебезчә сөйләшергә
Тарсынып, кыенсынып.
Килеп керделәр чегәннәр:
Ана һәм дүрт-биш бала.
Беркемнән дә оялмыйлар,
Аларга — вагон — дала.
Үз телендә ду китереп
Кычкырып уза болар.
Башлары горур, югары:
Әйтерсең — хуҗа болар!
Үзе бер дәүләт — тотышы
Дүрт-биш бөртек чегәннең.
Татарстан урамында
Тукталышта чыгам мин.
Басып торам башны иеп
Әрнүле бер сагышта.
Горурлыкны югалттык без
Кайчан, кай тукталышта?..

*1996*

## Соңгы гармун

(Баллада)

«Казан гармун фабрикасы,
хәле мөшкелләнеп, табут
ясауга күчте...»

*Соңгы хәбәрләрдән*

Борын заманнарда түгел,
Нәкъ хәзерге чорларда
Тынып калган йөз ел, мең ел
Күкрәп торган җырлар да.
Гармун фабригының хәле
Мөшкел, бик начар икән.
Дус-ишләрнең күңелләрен
Инде кем ачар икән?
Фабрикасы белән бергә
Үләргә ята гармун.
Бер дә ышанмас идем дә...
Матәмгә үзем бардым.
Соңгы гармунны салырга
Табут ясап куелган.
Башлар түбән иелгән лә,
Йөзләр кара коелган.
Күз яшьләрен эчкә йотып,
Күңелемнән елап тордым.
Башым иеп, осталарның
Сүзләрен тыңлап тордым.
«Моңлы-зарлы арасында
Акчалы-бай кеше юк.
Гармун үтми, адәмнәрдә
Хәзер җыр кайгысы юк!»
«Магнитофон, синтезатор,
Телевизор, плейер...
Яшьләргә гармун кирәкми,
Яңа ритм тели ул!»
«Үз бурычын үтәп, гармун
Фани дөньяны кичте.
Гармун фабрикасы хәзер
Табут ясауга күчте».
«Матәм көен уйнады да
Өзелде, тынды гармун.

Хөрмәтләп күмәрбез инде,
Табутта — соңгы гармун...»
...Шулчак бик ямансу уйлар
Чорнап алды күңелне.
Туктагыз әле, егетләр,
Ашыгабыз түгелме?
Үлмәгәндер, ул бары тик
Хәлсезләнеп ятадыр,
Безнең сүнгәнлекне күреп,
Җан сызланып ятадыр.
Сезне белмим, гармун — минем
Юанычым бердәнбер.
Гармунсыз калу — ул миңа
Үзем үлү белән бер.
Якты дөньяга килгәч тә,
Мин көй белән таныштым,
Дус-ишләрем арасында
Гармун — минем җан дустым.
Ничә гасыр исән калган,
Кичеп суны һәм утны...
Сорыйм сездән, сабыр итик,
Бикләмәгез табутны!
Гармунсыз гамьле яшьлек тә,
Һәм картлык та булалмый,
Гармунсыз хәсрәт тә җиңел,
Шатлык та мул булалмый.
Һич арттырмыйм, гармун бит ул —
Җаныбызның яртысы.
Анда — яшьлегем хисләре,
Анда — сөйгән яр төсе.
Туктагыз әле, телләргә
Бик сак кына кагылыйк,
Моңнарга төренеп калган
Яшьлек чорын сагыныйк.
Кызлар бигрәк ялындыра,
Әйдә, бәйләник әле,
Гармун телләре аңлатыр,
Урам әйләник әле!
«Гармуныңны уйныйсың,
Үзеңниләр уйлыйсың,
Яшь чагында шуны уйлыйсың,
Яр сөюдән туймыйсың».

Сугышларда дүрт ел йөргән
Гармунчы кайта, дисәм...
Үзе яуда ятып калган,
Гармуны гына исән.
Ятып елардай чакларда
Яшьне чыгармый калам,
Уйнаучысын сагынам да
Гармунын кулга алам.
«Сандугачлар басып сайрый
Гармун каешларында,
Кайталмады, ятып калды
Кояш баешларында».
Узган сират күперләрен,
Кичкән сугыш-тәмугны.
Сорыйм сездән, ашыкмагыз,
Бикләмәгез табутны!
Әйтмәгез: «Еллар бик ябык,
Тагын, диеп, түзегез...»
Илне бу авыр хәлләрдән
Чыгарыйк без үзебез!
Замананың авырлыгы
Безнең җилкәгә төште.
Һич күтәрә алмас идек,—
Гармун да күтәреште.
Ул булды гел-гел кулымда,
Кулымда, куенда да,
Кичке елга буенда да,
Яшьлегем туенда да.
Син ул — балачак хыялым,
Син ул — сайраулы таңым.
Юк, бирмим сине үлемгә,
Күтәр башыңны, җаным!
Өзелдем дигән телләргә
Кулларым тиеп китә...
Бармакларым сөенечтән
Тирбәлеп биеп китә!
Уйный ич гармун, уйный ич!
Кем әйтә: «Үлеп ята...»
Бу гармунның телләрендә
Мең яшәр өмет ята!
Әй уйный гармун, әй уйный...
Кем әйтә: «Өнсез ята...»

Туң җаннарны эретерлек
«Моң» дигән бер сүз ята!
Осталарның әкрен генә
Күтәрелә башлары,
Әнә, гармунга кушылып,
Алар җырлый башлады:
«Уйна, дустым, гармуныңны,
Үзең яраткан көйгә,
Кайгы-хәсрәтне җиңмәсәң,
Дөньяда яшәү нигә?»
Кемнәр әйтә: «Гармун мәрхүм
Кабергә таба бара...»
Кабергә таба бармый ул,
Бәгырьгә таба бара.
Гармун ясаучы осталар
Шатлана-канатлана,
Табут артыннан түгел лә,
Гармун артыннан бара.
«Тормыш бит ул, тормыш бит ул,
Тормыш бит ул үзгәрә,
Тормышның рәхәт көннәре
Килер әле безгә дә».
Исән ул, исән, терелеп,
Кочакка килеп куна,
Кочакта гармун барында —
Өметтә яшәп була!
Кабына көйләр йөрәктә,
Ялкын теле шикелле,
Ягымлы ул әткәм-әнкәм,
Халкым теле шикелле.
«Тормышны көйләрбез!» — диеп
Кем әйтә? Күңел әйтә.
Заман йөген күтәрүне
Гармун да җиңеләйтә.
Кечкенә нәни гармунга
Бар шатлык, хәсрәт сыя,
Гармун белән бергә барыйк
Гүзәллек дөньясына!
Уйныйк әле гармуннарны,
Иш янына куш булсын,
Сандугач телле гармунга
Оркестрлар кушылсын!

Кулларда гармун барында —
Җаннарда тынгы булмас,
Мең яшә, татар гармуны,
Бу гармун — соңгы булмас!

*1996*

## Татар шагыйрьләренә

«Яшәгез озак!» дип исә кебек
Җирне жылыткан апрель җиле дә...
Китмәскә иде, китмәскә иде
Тукай шикелле егерме жиделе.

Яшәргә иде гомер озайтып,
Ут-ялкын биреп җаны утсызга...
Китмәскә иде, китмәскә иде
Такташ шикелле, бары утызда.

Җыр — каләм белән җиңеп дошманны,
Башны имичә коллыктан соң да...
Китмәскә иде Җәлилләр сыман,
Утыздан соң да, кырыктан соң да.

Атарга алып чыкканнан соң да,
Түзәлмәс газап чиккәннән соң да,
Китмәскә иде, китмәскә иде
Туфан шикелле, сиксәннән соң да.

Һич тә тукталмый барасы иде
Туган тел белән Җыр дәшкән чорга...
Яшисе иде, яшисе иде
Колгали сыман, мең елдан соң да!

*1997*

# Абыйларсыз калган юлларда

*Лэис Зөлкарнэйгэ*

Фэиз үткэн юллар, нигэ миңа
Үпкэлэгэн кебек карыйсыз?
Лэис энем, сиңа килдем эле,
Син дэ, мин дэ калдык абыйсыз.
Без дэ юлда, без элегэ исэн,
Гомер уртасында калабыз.
Фэиз кебек, без дэ экрен генэ
Туган җирдэн китеп барабыз.
Юл буеның зэңгэр чэчэклэре,
Нигэ шулай боек карыйсыз?
Лэис энем, без энелэр идек,
Син дэ, мин дэ хэзер — абыйсыз.
Фэиз үткэн юлдан үзэк өзеп,
Тимер ташкын уза тезелеп,
Авыл белэн кала арасында
Без абыйсыз калдык өзелеп.
Үзебез дэ сизми калдык, энем,
Тормыш руле безнең кулларда.
Барулары бик үк җиңел булмас
Абыйларсыз калган юлларда.
Көтэ булыр, бэлки, һэлакэт тэ.
Кайберэүлэр кайтмый бер киткэч...
Йөрэк барыбер хэтэр юлга тарта!
Киттек, эйдэ, Лэис энекэш!

*1997*

* * *

Хәтеремдә:
бала чагымда,
авыл урамында
Абый чыкты мине кулдан тотып.
Сизми калдык:
Ике нәни җанны куркытып,
Тыкырыкта бер ат күренде.
Кулдан ычкындырган Нил абый.
Ат астында калдым мин — сабый.
«Беттем...» дисәм,
Мин — исән...
Атның дүрт тоягы тими үткән икән.
Кара дуга
ал офыкка китеп күмелде...
Сикереп тордым.
Җанда курку хисе сүрелде.
Куллар Нил абыйга үрелде.
...Тимер ташкын килә
урамнарны йотып:
китәр сытып,
аждаһадай килә куркытып.
Чыктым юлга оныгымны тотып.
Тимер ташкын килә каршыга.
Сак булыгыз, шәһәр оныклары!
Онытмагыз, шәһәр картлары:
Ал офыкка китеп күмелделәр
Авыл атлары...
...Ат та, машина да читләп үтте.
Нил курыкмый иде алардан.
Аның нечкә җанын таптап үтте
кайбер адәмнәр.
Сак булыгыз, шәһәр оныклары...

*1998—2001*

## Таулар күкрәгеннән чыккан җыр

Гомерем буе тауга-күккә ашып,
Түбән төшә-төшә ялыктым.
Тукталдым да Урал итәгенә,
Йөрәгемә ятып ял иттем.
Ишетелде шулчак серле бер җыр,
Ардым инде, талдым дигәндә:
«Төшсәң дә син Җиргә — бик түбәнгә,
Төшә күрмә Җырда түбәнгә...»
Табигатьне,йөрәгемне айкап,
Яшәртте җыр Җирне-Күкләрне.
Таулар күкрәгеннән чыккангадыр,
Ул мине дә биек күтәрде.

*1997*

## *Гомерләрең уза, былбылкаем...*

Ерак чит җирләрдә йөргән чакта,
Тәрәзәдән бер җыр ишеттем.
Тирбәлүен тойдым балачакта
Туган тел көйләгән бишекнең.
Өзелеп-өзелеп кош сайраган кебек...
Каян килгән тансык бу җырым?
Нинди салкын җилләр чит илләргә
Какты сине, сеңелем-былбылым?
Аңладым мин: очып киткәнсеңдер
Чит җирдәге кошка пар булып.
Гомерләрең уза, былбылкаем,
Әнкәң моңнарына зар булып...

*1998*

* * *

Өй алдында үскән карт аккаен
Гарасаттан мине яшергән.
Утны үзенә алып, әнкәм белән
Саклап калган мине яшеннән.
«Саклан, балам, яшен утларыннан»...
Хәтерлим мин әнкәм әйткәнне.
Тик мин генә каен булалмадым,
Саклап калалмадым әнкәмне.
Каен гомерләре бирәлмәдем,
Шул үкенеч кала гомеремдә.
Әнкәемнең тынычлыгын саклап,
Карт аккаен үсә каберендә.

*1999*

## Гасыр кичкән чакта...

Гасыр кичкән чакта уйга калдым,
Күңелемне бер җыр тартты да...
Көем минем «Кара урман» сыман,
Кайгы-хәсрәтле дә, дәртле дә.
Бабамнардан калган мең батырлык,
Бабамнардан калган мең хата
Бер җырлата мине, бер елата,
Алда — мең бормалы юл ята.
Балачакта, үсмер яшьлегемдә
Ялган аллаларга табынып,
Мин үзем дә юлдан чыккаладым...
Буш хыялдан киләм арынып.
Күңелләрдә янган мең еллык Моң
Җиңеләйтә атлап барышны.
Килер елларым да булыр димен
«Туган тел»ле, «Сәйдәш марш»лы.
Егерменче гасыр күкрәгендә
Хәсрәт көен күбрәк җырладым,
«Тиран, җәлладларны Җир йөзенә
Ник тудырдың?» диеп сорадым.
Сугыш утларында янган-көйгән,
Туфрак булган ирләр, балалар:
«Тыныч яшәр көннәр туармы?»— дип,
Көйләремә ияреп бабалар.
Чәчләремне сыйпап юат әле,
Дәвер җиле, гасыр кояшы.
Кырыслана, усаллана барам,
Булсам да бер Җирнең юашы.
«Син каян?»— дип сорый Киләчәгем.
«Татар яши!»— дигән өйдән мин.
Ниләр күреп, ниләр кичерсәм дә,
Аерылмам шушы көйдән мин!
Гасыр кичкән чакта уйга калдым,
Күңелемне бер җыр тартты да...
Көем минем Сәйдәш җыры сыман,
Кайгы-сагышлы да, дәртле дә...

*1999—2000*

## Кайраучы

Пычак кайрыйм!
Яшь егетләр
Чәчәк кисеп алсыннар,
Саф хисләрен аңлатырга
Сөйгәненә барсыннар!
Чалгы кайрыйм!
Болыннарда
Җырлап печән чапсыннар!
Чалгы кайравын ишетеп,
Кызлар шунда чапсыннар!
Кайчы кайрыйм!
Сеңел-кызлар
Туй күлмәге киссеннәр,
Бу күлмәкне иң бәхетле
Ярлар-парлар киссеннәр!
Балта кайрыйм!
Өйләнешеп,
Өй нигезе корсыннар,
Бу йортларда сөеп-сөелеп,
Гел сөенеп торсыннар!
Көрәк кайрыйм!
Хыялларым
Шат йөзләрдә күренсен,
Мәкерле явыз ниятләр
Яшәмәсен, күмелсен!
Аһ, нигә аз бу базарда
Уемны аңлаучылар?!
Теш кайрыйлар — ниятемә
Хәнҗәр-ук кайраучылар...

*2000*

* * *

Әллә безнең өчен оялудан
Шәфәкъ — алсуланып дымлана.
Без кунакка гына килгән идек,
Тыйнак булалмадык, Җир-Ана.
Бирмәгәнне талап-йолкып алдык,
Әллә шуңа яндың-көйдеңме?
Чакырылган кебек әрсезләндек,
Әллә чакырмаган идеңме?
Җир йөзенә нигә килгәнлекне
Аңлаучылар әллә тумаган...
Юкка гына Адәм-Һауабызны
Аллаһ Күктән Җиргә кумаган.
Кичерүне, ярлыкауны сорап,
Күккә ялварсак та — чара юк.
Күкләр тынган, очар канат сынган...
Ычкындырмый Адәм-Һаualык...

*1997*

* * *

Берүзем җиде төн уртасында:
Ай да мин.
Мәңгелекнең кайсы ноктасында,
Кайда мин?
Нигә шулай төнлә күк күкрәтеп
Яшьнисең?
Яшим Күктән серле аваз көтеп, —
Дәшмисең.
Сорау белән карыйм Күккә — салкын
Тынлыкка.
Гаҗиз булып калам Мәңгелеккә
Юл юкка.
Яшәгәндә Җирдә җылы нокта —
Аң булып,
Аңлашасы килә синең белән,
Мәңгелек...

*1997*

# Китәм, диден...

*Фасил Әхмәткә*

Хәсрәт-сагыш тулы тавыш белән
Чылтыраттың миңа бүген дә:
«Фатир алу өчен китәм,— диден,—
Яшим ич мин ишек төбендә».
Күңел тартты гел-гел югарыга —
Хыял җитмәс Илаһ күгенә.
Фатир сораганда төштек инде
Түрәләрнең ишек төбенә.
Ничә гасыр газап чигәбез без,
Һич күнегеп булмый бүген дә...
Туган телебез дә, үзебез дә
Түрә телнең ишек төбендә.
Ераккарак, йөрәккәрәк китик
Түрәләрнең ишек төбеннән,
Күпме генә аска тартсалар да,
Төшмәдек без иҗат күгеннән.
Аңлыйм, дускай, авыр — бу тормышның
Кырыс җилләр искән үрендә.
Юк, китмәбез, без яшәрбез әле
Үзебезнең өйнең түрендә!

*1997*

...Китеп бардың кайтмас Мәңгелеккә,
Симфония булып күкрәргә.
Син яшисе фатир көткән икән
Таң йолдызың янган Күкләрдә...

*1998*

## Август чәчәкләре

Август чәчәкләре, кайчан гына
Балкып-көлеп яна идегез.
Көз салкынын сизеп боектыгыз,
Башыгызны түбән идегез.
«Вакытында су да сипмәде» дип,
Рәнҗемичә генә корыгыз.
Мин беразга гына калам әле,
Мәңгелеккә бара торыгыз.
Якын дус-ишләрем арасында
Яшәсәм дә уйнап-көлеп мин,
Ялгыз калган чакта бик тә уйчан,
Август чәчәкләре кебек мин.
Дусларыма кереп барам әле
Яшьләремне тыеп көләргә.
Кышларыма кереп барам әле
Яшьлегемне коеп җилләрдә.

*1998*

## Язлар килә монда иртәрәк...

Салкын карлар-бозлар эреп бетә,
Язлар килә монда иртәрәк,
«Җаным» дип әйтүгә эреп китә,
Тау ягында кызлар иркәрәк.
Тау ягының уңган егетләре,
Салкын күлгә кармак салмагыз,
«Җаным» сүзен әйтеп өлгермичә,
Салкын күздә торып калмагыз.
Казларыгыз җылы күлләр эзләп,
Көньякларга күчеп китмәсен,
Казларыгыз очып китсә китсен,
Кызларыгыз очып китмәсен!

*Кайбыч, 1998*

* * *

Рәсемеңне ясыйм хыялымда:
Күзләрең — диңгез,
чәчләрең — дулкын,
хисләрең — ташкын,
карашың — упкын.

Ни булса да түзәм юлларымда:
күзләрем — маяк,
чәчләрем — җилкән,
тынычлан, диңгез,
мин киләм, иркәм...

*1998*

## Урта Кирмән

Кемнәр киткән,
Кемнәр килгән?
Әйтче миңа,
Урта Кирмән?
Тауда—Кирмән,
Тауда—кала.
Кала тавы
Яуда кала.
Урта Кирмән,
Урта Кирмән,
Ирек өчен
Утка кергән.
Урта Кирмән
Башын игән:
Боз да күргән,
Ут та күргән.
Болгар бабам,
Болгар бабам,
Калатауда
Янган бабам,
Көл булса да
Югарыда,
Биек тауда
Калган бабам.
Алар өстә,
Һаман тауда,
Ә без шулай
Ник түбәндә?
Ни әйтергә
Тели икән:
Козгын оча
Баш түбәмдә?
Түгел микән
Омтылышлар
Бик түбәндә,
Бик түбәндә?

*Урта Кирмән,1998*

## Тагын бер дәрәҗә тактылар...

Мулла нәселе дә җиткән иде,
Тагын бер дәрәҗә тактылар:
Шәҗәрәмдә бик эзләнә торгач,
Морза икәнемне таптылар.
Иске-москы Ямадыда туып,
Шул тормышка риза булганмын,
Черек кәлҗәмәләр капканда ук,
«Чабаталы морза» булганмын.
Ничә еллар кагылып та сугылып,
Морзалыктан китә барганмын,
Авызымны ачсам, бер чакырымнан
Күренеп тора һаман бәрәңгем.
КГБга рәхмәт, ул елларда
Табалмаган кат-кат тикшереп.
«Сыйнфый дошман» диеп, Себерләргә
Озатырлар иде «өшкереп».
Халык малын талап баеганнар,
Кайсы булсагыз да берегез
Үзегездән арткан коттеджны
Юзи хәзрәтләргә бирегез!
Кайтарыгыз мине морза бабам
Гомер сөргән сарай, утарга.
«Тот капчыгың!» диеп әйтсәгез дә,
Капчыгым да юк шул тотарга.
Еллар мине юлга чыгардылар,
Чабатадан күчтем итеккә.
Әмма ямаулардан котылмадым,
Ямадыдан ерак китеп тә.
«Саумы, Юзи морза? Хәлең ничек?»
Язмыш минем белән шаяра.
Ачы яшькә, канга яшеренеп
Дәшә миңа бөек шәҗәрә.
Мөлкәт-байлык миңа кирәк түгел,
Сарайларда рәхәт күрегез.
Сабыйларча бер мактану өчен,
Титулымны гына бирегез!
Әтрәк-әләм, ялкау теш кайрарлар,
Морзадашлар, бәлки, үз күрер.
Әмма теге заман кире кайтса,
Җиде әбиемне өшкерер.

Нәсел газаплары искә төшкәч,
Дөресен генә әйтим, шүрлимен.
Шагыйрь булу гына җитмәгәнме,
Морзалыкка нигә үрлимен?
Киеп шигърияттнең чабатасын,
Килә минем көн-төн чабасым,
Килә милләтемне баетасым:
Рәмиевләр Дәрдмәнде кебек,
Уй-моң алтыннарын табасым...

*1996—1998*

## Сагынырбыз

Әгерҗенең төнге урманында
Ядкәр-истәлекләр алыштык.
Юмарт табигатьле Гариф Ахун
Бүләк итте миңа галстук.
Төннең үткәнен дә сизми калдык,
Нуры төште йөзгә ал таңның.
Ал галстук таккан, учак яккан
Балачакка мине кайтардың.
Зыялылар өчен, Гариф туган,
Чорлар һаман авыр булдылар.
Әтиемне, допрос алган чакта,
Галстугы белән будылар.
Син дә кайчагында боегасың,
Әйтмәсәң дә, Гариф, беләм бит:
Яра булып калган йөрәгеңдә
Бандит дучар иткән ятимлек.
Сулыш алулары авырая,
Төшкә генә керә иркенлек —
Зыялылар түгел, галстуклы
Зыянлылар итсә өстенлек.
Муеннарны кайчак бушаттылар,
Кайчагында каты кыстылар,
Килер еллар гүзәл булыр дигән
Зур хыяллар җилгә очтылар.
Их, чабасы килә ап-ак кардан
Галстукны ташлап җилләргә!
Балачагын бигрәк сагынган дип,
Сүз әйтмәсләр бездәй җүләргә.
Иркенлек тә киңлек... Рәхәт монда...
Саф һавада җиңел тын алдык.
Күпме генә безне бусалар да,
Буылмадык, бик күп сыналдык.
Якты сагыш белән сагынырбыз
Кышкы табигатьнең ак карын.
Каләмемне ак урманга манып
Язган җырым булсын ядкәрем...

*Әгерҗе,1999*

## Күктән — югарыдан карaганда

Сезнең белән яшәү бик рәхәт тә,
Кайчагында авыр да сыман.
Сез бит яралгансыз үзебезнең —
Ир затларның кабыргасыннан.
Хак Тәгалә даһи иҗатына
Бар нәфислек хисен салгандыр,
Безнең кабырганың иң нечкәсен,
Иң нәзеген сайлап алгандыр.
Ул, мөгаен, иң-иң түземлесе,
Иң-иң чыдамлысы булгандыр,
Иҗат иткәч, үзе гаҗәпләнеп,
Хәйран калып карап торгандыр.
Без аусак та, сез һаман да төп-төз,
Йомшак ягыбызны белгәнбез:
Ярый әле һич тә кызганмыйча,
Иң шәп кабырганы биргәнбез.
Чибәр кызлар, борын күтәрмәгез,
Онытмагыз, шуны белегез:
Безнең кабыргадан яралганга,
Талдин нечкә сезнең билегез.
Сезгә ачу килгән чакларда да
Ярдәм сорап Күккә бакмыйбыз,
Иң сөйкемле сөягебез итеп,
Кочакларда гына саклыйбыз.
Сез илаһи җаннар — безгә әрәм!
Сез бит Күктә генә яшәрлек!
Кайчак шүрлибез дә, Иҗатчыгыз
Үз янына кире дәшәр дип...
Ул бит салкыннарда шпал суккан
Хатыннарны күреп торадыр.
Җиде кабыргалы начальникка —
Ир-егеткә ләгънәт орадыр.
Күрәдер ул авыр йөкне, аттай,
Гүзәл затлар тартып йөргәнне,
Шуңа карамастан бездә ирләр
Патшалыгы хөкем сөргәнне.
Күкләр дәшсә үтенәбез: зинһар,
Җирне ташлап китә күрмәгез!
Сезнең белән генә көчле булган —
Безне ятим итә күрмәгез!

Шөбһә белән зәңгәр Күккә карап,
Без тиешбез шуны таныргa:
Сез бит, сез бит ирне генә түгел,
Җирне тота торган кабырга!
Күктән-югарыдан караганда,
Сез — йолдызлар булып янарлык!
Ә түбәндә — Җирдә — без — ирләрнең
Җиде кабыргасын санарлык!

*1998*

## Күктәге рәсемнәр

Кояш баеган тарафта
Даһи рәссам иҗаты.
Күңелне үзенә тарта
Күкнең беренче каты.
Күлләр, инешләр — тынлыкта,
Җилнең юк әсәре дә.
Тәмам ычкындым чынлыктан —
Мин күкләр тәэсирендә.
Әллә урман, әллә болыт,
Әллә рәсем, әллә чын.
Сихри күлгә аккош булып
Очыйм микән әллә соң?
Күкнең бихисап төсләрен
Аңлаталмас хәлдә мин.
Әллә кимеде хисләрем,
Үзем телсез әллә мин?
Җанга иңдереп бу мәлне,
Әйтә кебек бу рәсем:
«Адәм төшкәнгә кадәрге
Җирнең йөзен күрәсең».
Җанга җиңел!
Җиденче кат
Күкләргә күченерлек!
И Раббым, Җирдә гөнаһлар
Түгел шул кичерерлек...

*1988*

## Гөлләр сорасалар...

Татар шагыйрьләрен белмәүчеләр
Сорасалар: «Туфан кем ул?» — дип,
Мин әйтермен:
«Себер кышында да
Чәчәк аткан чыдам гөл ул»,— дип.
Сокландылар аның сафлыгына
Үзе иркәләгән гөлләр дә.
Төрмәләрдән аккош булып кайтты,
Ап-ак чәчәк иде күлләрдә.
Шагыйрьләргә нигә түзәлмәслек
Газапларны бирә соң Аллам?
Адәмнәрдән өмет өзмичә, Ул
Татар шагыйрьләрен сынаган.
Гөнаһлары өчен, Адәм-Һауа
Күктән сөрелеп, Җиргә киткәндер.
Ә Туфанны Адәм сөргененнән
Күкләр сөеп кабул иткәндер.
Гөлләр сорасалар:
«Туфан кайда?
Аны бездән кемнәр алды?» — дип,
Мин әйтермен:
«Җирдә генә түгел,
Күктә аккош булып калды»,— дип...

*Кармәт,2000*

## Илһамсыз чакларда

Күптән инде гармун тотканым юк,
Әллә нишләгәннәр җиз телләр:
Уйналмыйча озак яткангадыр,
Элеккечә көйле түгелләр.
Күптән инде каләм тотканым юк,
Аламын да туктап каламын.
Хис коесы әллә саектымы,
Тутыктымы әллә каләмем?
Гамьсез һәм мәнсезләр арасында
Бу дөньяда бармын шикелле.
Их, ятмаска иде тузан йотып,
Уйналмаган гармун шикелле.
И Илаһым, Син бит мине Җиргә
Шигъри җанлы итеп яраткан.
Аермачы Күкләр кодрәтеннән,
Могҗизалы серле халәттән...

*2000*

## Килəчəк кызына хат

Килеп җитте Кандалыйның
Сөю хатлары.
Гашыйк кызлар шигырьлəрен
Сөеп ятлады.
Күп кызларны сөю-гөнаһ
Саналмый кебек.
Мин дə бик күп гашыйк булдым
Кандалый кебек.
«Җырың яшəр»— диеп, күңел
Алдалый кебек.
Хыялым — тик бер хат язу
Кандалый кебек.
Ышанам һəм өмет баглыйм
Шигырь-җырларга.
Хатым китсен сез яшəгəн
Ерак елларга.
Сөю яшəр, хис тə яшəр,
Сизəм: алар нык!
Тик калырмы татар кызы
Мине аңларлык?
Җаныгызда бу хатыма
Табылса урын,
Сөенечтəн сезне кочып
Еласын җырым...

*1997*

## *Бу базарда*

Базарларда яңа байлар йөри.
Кемнәр алар: еллар ачыклар.
Пенсиянең соңгы тиеннәрен
Санап тора картлар-карчыклар.

Янда гына, янәшәдә генә
Күтәрелә затлы сарайлар.
Күзләремә карап хәер сорый
Апуш яшендәге малайлар.

Мин шуларның җырын тыңлап йөрим,
Күбәйделәр бу ай, бу кышны...
Асрамага берсе алыр микән
Бу базарда «Тукай-Апушны?»

*1997*

# «Ике йөз елдан соң... инкыйраз...»

*Гаяз Исхакый*

Төннәрен йоклатмый бу сорау.
Җавапсыз күп таңнар атарлар.

Бетәрме, яшәрме —
Ике йөз елдан соң татарлар?
Туфракка әйләнеп калганнар
Рух булып, борчылып яталар:
Бетәрме, яшәрме —
Ике йөз елдан соң татарлар?
Бу сорау борчымый оныкны,
Әлегә битараф, шат алар.
Борчуда аналар, аталар:
Иртәгә яшәрме татарлар?
Мин хөкем итәргә уйламыйм,
Бу хәлгә гаепле үзем дә.
Безнең бит язмышлар корылган
Күз яшен яшереп — түзүгә.
«Ике йөз елдан соң... инкыйраз...»
Татарым, акылга кил бераз.
Битараф калсак без — бүген үк
Тормышка ашачак бу фараз!
Ике йөз елдан соң сорауга
Җавап та бирүче табылмас,
Оныклар, туряннар онытыр,
Безне дә, телне дә сагынмас.
Киләчәк елларга калдырсак,
Җавапны чит-ятлар табарлар:
«Кайдадыр, кайчандыр
Булган, ди, ниндидер татарлар...»
Милләте яшәгән кадәре
Мәңгегә яшәргә туган ир —
Мөһаҗир... ул көтә. Ни көтә?
Дәш аңа, Исхакый туган җир!
Син даһи улыңа җавап бир,
Туачак буынга тапшырма,
Иртәгә яшәрме татарлар?
Әйт шуны, Казан һәм Яуширмә!
Иртәгә яшәрме татарлар?!

*июль, 2001*

* * *

Чәчләр агарды дип мактаналмыйм,
Ап-ак калалмады күңел дә.
Күп хыяллар, чынга ашалмыйча,
Югалдылар өмет күгемдә.
Сафлык калса әгәр бу җанымда —
Саклап калды аны җыр гына.
Гомеремнең соңгы тамчыларын
Көйгә салган чагым тын гына...

*2001*

* * *

Шәһәр топольлләре урамдагы
Кызлар кебек ярым шәрәләр.
Бу шәрәлек, ахры, туйдыргандыр,
Сөенешеп яфрак яралар.
Кызлар, кызлар, зинһар, сакланыгыз,
Очрашырга вакыт: кич җиткән.
Яз шәрабы — яңгыр тамчылары
Аек топольне дә исерткән.
Язга таба чабып барган чакта,
Тополь башын кисеп кем аткан?
Үлеп гашыйк булган яшь кыз сыман,
Шәрә тополь башын югалткан.

*2001*

## Кая ашыгасың, дөнья?

Тормыш агымына ияргә
Тырышам да калам тукталып.
Кая барам? Кая ашыгам мин?
Уйга чумам ялгыз тын калып.
Карап торам ярны назлый-назлый
Талгын гына аккан дулкынга.
Бу тормышның көйсез агышлары
Илтмәс микән соңгы упкынга?
Тормыш агымына иярми дип,
Тәнкыйтьчеләр, әйдә, язсыннар.
Үз итәм мин чишмә сагышларын,
Заман агышыннан ятсынам.
Бу дөньяны куа-куабыз да,
Тоталмыйча дөнья куябыз.
Төзәлмәслек хата-ялгышларны
Гомер азагында тоябыз.
Кая чабасың син, ашыгасың?
Юлың билгесез һәм ерактыр.
Дөнья, җаным, көйлә агышыңны,
Былбыл тавышларын тыңлап тор.

*2001*

# *Мин югалсам...*

*Вафирә Гыйззәтуллина истәлегенә*

Уттан-судан мине эзләмәгез,
Юлда булырмын,
Серле күңелемне ниләр тарта, —
Шунда булырмын.
Кошлар кебек мин бик ярсулы да,
Тын да булырмын,
Кайда сайрау, кайда челтерәүләр, —
Шунда булырмын.
Кирәк икән, гармун телләре дә,
Кыл да булырмын,
Кайда шатлык, кайда тирән хәсрәт, —
Шунда булырмын.
Мин югалсам, сулга каерылмам,
Уңда булырмын,
Җаным тынганда да аерылмам,
Юлда булырмын,
Җырда булырмын.

*2001*

# Җәйге таңда уяну

Бар тереклек арган-талган, яшәүдән туктаганмы?
Теге дөньяга киткәнме, әллә соң йоклаганмы?
Юк, бу — бары вакытлыча, беркадәр мәрткә киту.
Бер көн алга бару өчен, бер төнгә артка киту.
Анда кемнәр ни кыладыр, табигать калган «мин»сез.
Мин монда телсез һәм өнсез,— куркыныч һәм күңелсез.
Күктән күреп торучылар бу халәтне аңлатмас,
Уянгач та үзең уйла, сизен, йөрәк, аңлат, баш!
Бар гомерең йоклап узар, гамь белән уянмасаң,
Бу дөньяның фанилыгын җан белән тоялмасаң...
Нинди серле, нинди шатлык җәйге таңда уяну,
«Әле дә шөкер яшәештә мин бар!» диеп уйлану.
Иң саф хисләр, изге эшләр шул җәйге таңда ата.
Күкрәгеңдә беркемгә дә әйтелмәс серләр ята.
Баштан сыйпап талгын гына рәхәт җил исеп куя,
Әнкәеңнең иркәләве исеңә төшеп куя.
Арттырмыйм да, киметмим дә, җир оҗмахы шушыдыр.
Ахыры юк, бу — гомернең сабый чагы, башыдыр.
«Хәерле иртә!» диләрме, асыл кошлар җыр суза,
Бакчадагы гөл-чәчәкләр «Исәнме?» дип кул суза.
Зәңгәр томаннар аркылы Кояш нурларын коя,
Җир йөзенең көләчлеге бер җанга ничек сыя?!
Гомереңнең кыскалыгын искәртә бары гөлләр,
Беркайчан да килмәс кебек мәңгелек «мин»сез төннәр...

*2001*

# Әҗәл... үлгән

*(Төш)*

Шатлан, бие, тантана ит!
Әҗәл үлгән! Күмелгән!
Мондый олы сөенечне
Моңа кадәр кем күргән?
Төшкә дә кермәс хыялың
Инде тормышка ашты:
Ниһаять, кыска гомерең
Мәңгелеккә тоташты!
Йөрим, имеш, җырлап-биеп,
Башны Күкләргә чөеп:
«Шул Әҗәлдән — газраилдән
Котылдым инде!» — диеп.
Узам гасырлар буенча,
Еллар елга бәйләнде.
Яшәп аргач, сөенечем
Көенечкә әйләнде.
Инде тәмам картайганмын,
Хәлемне беркем белми.
Әҗәлне көтәм, чакырам, —
Ә ул килми дә килми.
Тәхетне дә, бәхетне дә
Явызлар басып алган.
Күпләр акылдан шашканнар,
Адәмнәр шашып калган.
Мин дә ялварам, кычкырам
Бәхетсез еллар аша:
«Китмә, китмә Җир йөзеннән,
Кил, Әҗәл, үлмә, яшә!»
Яшә, әмма тормыш җиле
Иссен тәнне иркәләп.
Килми тор, гүзәл җаннарны
Алып китмә иртәрәк.
Синең алда бар да тигез:
Кол, җиһангир, патша да,
Җиңәлми яу да, акча да,
Үлмә, Әҗәл, кайтсана!
Салкын туфрак. Ташта язу:
«Монда Әҗәл күмелгән».

Синнән башка бу дөньяга
Ни буласын кем белгән?
Кулда көрәк. Меңьяшәрләр
Теш кайрыйлар алдымда.
Чык, Әҗәлем, зинһар, безне
Мәңгелеккә калдырма!

*2001*

##Ниләр көйли Казансу?

Явыз Иван гаскәрләре Казанны алу алдыннан Камай морза, дары мичкәләрен бушатып, су тутырта. Элекке Камай утары әле дә аның исемендә.

Гасырларда кала Изгелек һәм
Үз халкыңа кылган яман эш.
Кол Шәрифләр мәчет булып калка...
Дары мичкәләре калган буш.
Үз кавеме, ятка әверелеп,
Явыз Иван белән туп аткан.
Үз-үзенә ышанычын татар,
Бәлки, шул чакларда югалткан.
Дары базларыннан сулар ага...
Ниләр көйли икән Казансу:
«Бүленүләр упкыннарга илтә,
Аерылулар бигрәк яман шул,
Һәлакәттән сабак алмасагыз,
Хәлләребез булыр һаман шул...»

*2001*

## Юк, ашыкма, Тарих...

*Марс Рәфыйков һәм Рудольф Нуриевка*

Очты Юрий Галәм ишетерлек
«Поехали!»— диеп, кычкырып.
И татарым, ниләр аска тарта,
Китәлмисең Җирдән ычкынып?
«Оч, татарым, канатларың ныклы»,
Дигән кебек, җилләр исәләр.
Күкләр дәшкәч кенә — Марсларның
Хыял канатларын кисәләр.
Илья Муромецтан калыштыкмы?
Нәсел-ыруыбыз Алып бит.
Безнең хакта Тарих әйтмәс микән:
«Оча алмый калган халык...»— дип?
Юк, ашыкма, Тарих, һәм уйлама
«Татарларга очу юлы юк...»
Сәнгать Галәмендә Күккә ашты
«Оча торган татар» — Нуриев!

*2001*

## Идел ярларыннан карап торам

Шәһри Казаныма карап торам,
Ераклардан балкый ак кала.
Күпме яу килгәнне кичергәнсең, —
Шуңа күрәдер син — сак кала.
Шатлыкларны хәсрәт алыштырган,
Булалмаган гел-гел шат кала.
Узган дәверләрнең фаҗигасе
Изге ташларында саклана.
Идел ярларыннан карап торам,
Җәйге таңда күңелем сафлана,
Йөрәк яраларын оныттырып,
Булсаң иде мәңге шат кала.

*2001*

# Атнабайның туган көнендә укылган шигырь

Бәет әйткән бабайларны
Бүген искә алыр чак.
Балачактан бертуганнар:
Күрдем — Сок, Ямады — Сак.

Авыллар якын иде бит,
Нигә без ерак булдык:
Әнкәбез дә каргамады, —
Нигә Сок һәм Сак булдык?
Милләтебез язмышына
Без, ахрысы, тап булдык.

Казаны да, Уфасы да
Безгә туган як бит ул.
Уфа үзе Сок булса,
Казан үзе Сак бит ул.
Сәяси максат аерган
Мин — Сак, ә син — Сок булдык.
Эчебез тулы ут булса да,
Тыштан — шаян, шук булдык.

Бала чаклар — үзе бәет...
Бер-беребезгә сак булдык.

Яшьлектә гөнаһлар да бардыр,
Әмма Җырда саф булдык.
Бабайларның рухлары да
Бүген разый, хуш булсын,
Туганлыкны аерып торган
Киртә-чикләр юк булсын.
Язмыш ялгышын төзәтик:
Бәхетле Сак-Сок булыйк,
Картлык көнендә булса да,
Әйдә, Әнгам, кушылыйк!

*1998*

# Татар бугазында — циклон...

*(Эфир дулкыннары хәбәре)*

Сахалинда татарларның
Бик азы гына калган.
Тарихи атама булып,
Бугазы гына калган.
Үткәнне искә төшерү
Гүя бик авыр аңа.
Әллә шуңа инде Бугаз
Котыра, давыллана.

Еракта калган Зурлыкның
Дулкыны ярсып килә.
Кечкенә татар иленең
Йөрәге әле тибә.
Башы — бугазында — циклон.
Кыйтганың бу ягында —
Давылның тик кайтавазы —
Татарның аягында.
Циклонга хәлсез татарның
Йөрәк тавышы кушылган, —
Аякта басып торса да,
Бугазыннан кысылган...

*2002*

## Базар эчендә — баянчы

Базар эчендә — баянчы.
Кайчандыр булган моряк.
Җырлый ярсып, кызгандырып:
«Врагу не сдается наш гордый «Варяг!»
Кайберәүләр үз хәлләрен
Аңлагандай үтәләр.
Салган икәнен дә белеп,
Акча салып китәләр.
Ертык тельняшка. Алдында
Бескозыркасы ята.
Россия дигән крейсер
Җырлап, исереп бата.
Базарда — шашкын музыка.
Ишетелә матәм кебек.
Шул крейсерга эләккән
Үзем дә батам кебек...

*2002*

# Мин дә шул илдән...

*Фирдәүсә Кәримовага*

Әллә нигә якын булып киттең,
Якташым да түгел син үзең.
Мулла Иле дигән авылдан син...
Мин дә шул Илдән бит, сеңелем.
Нәселемдә изге илаһ затлар,
Шаҗәрәмнең очы — мулладан.
Әлефне мин таяк дип тә белмим,
Дога укый белмим, мин надан.
Нәселемне минем таркатканнар,
Иманлыдан гаеп тапканнар,
Ә бабамны, мулла булган өчен,
Урыс авылында атканнар.
Бер туганым ята Фәрганәдә,
Икенчесе — Сәмаркандында.
Кемдер имансыз дип санаса да,
Мулла каны ага җанымда.
Тау ягыннан килеп чыккан сеңелем,
Без бит бер үк Илдән икәнбез.
Заман урманында адашканбыз,
Башка юлга кереп киткәнбез.
Мин — Шигырьдә... Ә син — мөгаллимә.
Бу иманга озак киленгән.
Күкрәгемдә бабам рухы тибә,
Мин дә, сеңелем, Мулла Иленнән!..

*1997*

## Унҗиде яшьлек карт

Яшь кызлар узса,
Җиле орынып,
Туктап кала да
Карый борылып.
Кулында — таяк,
Ап-ак чәч — башта.
Күзләре һаман
Унҗиде яшьтә.
Таяксыз инде
Йөри дә алмый.
Күңел — йөгерә,
Яшьлектән калмый.
Гәүдәсе — сорау
Кебек тормышка:
«Картлык ник озын,
Яшьлек бик кыска?..»

*1997*

## Калыйм...

Күзләрем күргән чагымда
күреп калыйм,
Аяклар йөргән чагында
йөреп калыйм,
Колакларым ишеткәндә
тыңлап калыйм,
Йөрәгемдә моң барында
җырлап калыйм,
Гармунда йә кылда калыйм,
Бер җырым белән булса да,
Анда түгел, монда калыйм...

*1997*

# Чоңгылларга таба...

«Фатих Кәрим, такта кисәгенә тотынып, башкалар белән ярга таба йөзә. Күбесе батып үлә...»

*Рафаэль Мостафин*

Кичке тын диңгезнең
Бар ямен боздылар:
Акырып-җырлашып,
Баржада уздылар.
Ишеттем бик күптән,
Онытмыйм хәзер дә:
Шагыйрьне батырган
Ул еллар хәтердә.
...Баржада —
тоткыннар.
Ул кая юл тота?
Диңгездә — өермә
Як-якка ыргыта.
Боерык бирелгән:
Баржаны яндыру,
Йөзләгән тоткынны
Батырып калдыру.
Барсы да онытылыр —
Дулкыннар йотар да,
Сөйләмәс конвойчы
Берничә татар да.
Беркем дә эзләмәс
Җинаять эзләрен,
Урысча-татарча
Сүгенү сүзләрен.
Кем исән калалсын
Һәлакәт-упкында?
Ялвару-кычкыру
Күмелә дулкында.
Трюмнар — бикләнгән,
Күрә тик диңгез-төн.
Сакчылар качалар.
Ут-ялкын... боз...
төтен...

Тәмугтан чыгарлык
Йә, кемдә бар йөрәк?
Кем исән калса да
Җитәлмәс — яр ерак.
...Җил тынган,
Су тынган.
Таң туган. Төн узган.
Тик бирәү котылган
Үлемнән, ут-боздан.
Җәһәннәм төбеннән
Тик бирәү калыккан.
Ул нинди кавемнән?
Ул нинди халыктан?
Җәлладлар батыра
Алмаган татарны.
Кәримнәр — чын ирләр,
Шагыйрьләр батармы?
Тик башка дошманнар
Үлемен күрәчәк:
Ул, барып, сугышка —
Чигенми үләчәк.
Ул анда алгандыр
Тоткыннар үчен дә,
Фашистка аткандыр
Батканнар өчен дә!
Читтәге каберендә
Гөл-чәчәк үсәчәк,
Нәфрәте һәм моңы
Җырына күчәчәк.
Дөреслек бер калка,
Салсаң да упкынга.
Таң калам Шагыйрьне
Тудырган токымга!
Шагыйрен батырган
Татарин өчен мин
Кызарам, хурланам,
Аңламыйм,
төшенмим...
Күп күргән татарым,
Мең баткан халык син,
Батырма, батма да,
Батсаң да — калык син!

...Кечкә тын диңгезнең
Бар ямен боздылар:
Акырып-җырлашып,
Баржада уздылар.
Сүгенү авазы
Еракта күмелде.
Узганны хәтерләп,
Шом басты күңелне.
Баржада барганнар
Кемнәрне батырыр?
Коткара алырлык
Бармы бер батыр ир?
Ватык баржа бара —
Маяксыз диңгездә
Чоңгылларга таба...
Ул баржада... без дә...

*1998*

## Йолдызлы бер төндә уйлану

Саумы сез, исәнме, туганнар:
Авылда туганнар,
Давылда туганнар,
Далада туганнар,
Калада туганнар...
Адәмнән-Һауадан туганнар?
Саумы сез, исәнме, туганнар:
Көндә туганнар,
Төндә туганнар,
Илдә туганнар,
Җирдә туганнар...
Адәмнән-Һауадан туганнар?
Саумы сез, исәнме, туганнар?
Әгәр дә булсагыз уйлана торганнар,
Бер уйлап карагыз:
Ник Күктән сөрелгән
Адәм һәм Һауабыз?
Яуларда туганнар,
Тауларда туганнар,
Тирмәдә туганнар,
Төрмәдә туганнар,
Адәмнән-Һауадан туганнар.
Саумы сез, исәнме, туганнар?
Ник, нигә аларны куганнар?
Алар бит җәннәттә торганнар...
Бер уйлап карагыз, туганнар.
Көндә туганнар,
Төндә туганнар,
Илдә туганнар,
Җирдә туганнар,
Адәмнән-Һауадан туганнар.
Без Күккә карыйк та бер төндә,
Текәлеп мәңгелек Иркенгә,
Уйланыйк караңгы бер төндә:
Нигә без бу Җирдә сөргендә?
Туганнар,
Якын туганнар,
Ерак туганнар,
Күкләргә карап
Елап туганнар...
Саумы сез, исәнме, туганнар!..

*1998*

## Гасыр чигендә

Узды көннәр,
Узды айлар,
Узды гасыр.
Ниләр генә
Күрмәдең син,
Газиз башым...

Тузды кием,
Тузды тәнем,
Тузды җаным...
Хыялландым
Күрермен дип,
Гасыр таңын.

Күрдем сугыш
Яшенен дә,
Күкрәвен дә,
Газапларым
Калсын гасыр
Күкрәгендә.

Бу йөрәгем
Әле дә сабыр,
Әле дә чыдам.
Әкрен генә
Гасыр чиген
Атлап чыгам,
Исән калган
Өметемне
Саклап чыгам.

Уйлап торам:
«Үзгәр, гасыр!» —
Дип әйтергә.
Ниятем бар:
Тар дөньяны
Киңәйтергә!

*2000*

# Тимер бишектә

Арча районы
Казанбаш мәктәбенең музеенда
тимер бишек саклана.

Кем ясаган икән бу бишекне?
Кемнең әткәсе?
Килгәндер ич аның баласына
Нидер әйтәсе:
«Кала күрмә, диеп, үскәч тә син
Тимер бишектә.
Үрмәләргә һәм чыгарга тырыш,
Балам, ничек тә!
Гамьсез йокыларга тала күрмә,
Шуңа күнегеп,
Көч куеп чык чиксез Иркенлеккә,
Үзең үрелеп!»

Йокламыйбыз микән без хәзер дә
Бишектә ятып?
Бер чыгасы иде шул читлектән,
Ничек тә ватып...

*2000*

## Казан ятимнәре

Шат балалар узды
Шаян сүзләр әйтеп,
Казан урамыннан
Көпчәк тәгәрәтеп.
Алар мине тирән
Уйга салып китте,
Тәгәрмәчләр эзе
Ерак алып китте.
...Иван тарафыннан
Юк ителгән Казан.
Исән калганнары
Кол ителгән Казан.
Атлар үтерелгән.
Арбалары — ватык.
Беркем китә алмас,
Инде арба тартып.
Бала-чагаларга
Шундый язмыш тигән:
Исән калган бары —
Тәгәрмәчтән түбән.
Максат — узганнарын,
Телен оныттыру.
Ә үзенең канын
Яңарттырып тору.
Кол — аның анасы,
Юк — аның атасы.
«Ваз кич иманыңнан,
Казан сиротасы».
Мәскәү арбасына
Утыртканнар аны.
Басып алсын җанын
Чиркәүләрнең чаңы!
Ятлар көен көйләп
Тәгәрәгән арба.
Казан сиротасын
Ниләр көтә алда?
Тусалар да анда
Кара морза булып,
Килеп чыга монда
Карамзиннар булып.

Бабалары туса
Котдус атлы булып,
Калкып чыга татар
Кутузовлар булып.
Тургеневлар кебек,
Телнең хакимнәре...
Менә кемнәр алар
«Казан ятимнәре»!
Каян икәнлеген
Күпләр яшергәндер.
Куприн, Державиннар —
Затлы нәселдәндер.
...Татар тәгәрмәче
Тәгәрәгән һаман.
Көлләр өеменнән
Калкып чыккан Казан.
Тәгәрмәчтән түбән
Апуш — ятим бала
Казан арбасында
Кая китеп бара?
«Кемнәр бу баланы
Асрамага ала?»
Кулдан-улга күчеп,
Тукай булып кала.
Һаман калкып торган
Казан ятимнәре —
Телнең солтаннары,
Рухның хакимнәре.
Сау булырмы Казан?
Югалмасмы хәтер?
Татар тәгәрмәчен
Кемнәр тәгәрәтер?
...Тәгәрмәчтән түбән
Шат балалар уйный.
Бар өметем шунда —
Алар ниләр уйлый?
Кая тәгәрәрләр,
Ятим булырлармы?
Әллә Тукай кебек
Хаким булырлармы?..

*2000*

## Авылыма кайттым...

Авылыма кайттым. Туган-үскән
Өйгә якынлашып киләмен.
Таныш урам җәеп куйган миңа
Чирәмнәрнең яшел киләмен.
Әти-әниемне кочакларга
Әзер үземнең дә кочагым.
Әйтер сүзләремне әйтеп калыйм,
Атлап кына бармыйм, очамын.
Гомеремдә үзем азмы тойдым
Иркә-назын хатын-кызларның.
Мин дә сөйдем. Әти-әнигә тик
«Саумы» дип әйтүдән узмадым.
Мин үзем дә инде өлкәнәйдем.
Сездән башка барыбер ятим мин.
Бу юлы мин бер дә тартынмыйча,
Кайнар сүзләремне әйтермен.
Капка ачык — мине көтәләрдер.
Тәрәзәдә гөлләр күренде.
Кочагымны җәйдем:
«Әнкәй! Әткәй!»
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шулчак татлы төшем бүленде.
Барысы да төшкә генә кергән.
Яшел чирәм дә юк. Өй дә юк.
Әткәй, әнкәй мәңге
кайтмый торган
Йортка киткән... Алар өйдә юк.
Иң-иң җылы сүзләр табар идем
Мөлдерәмә күңел тулса да.
Тик бер генә,
Тик бер генә кочаклыйсы иде
Төштә генә күреп булса да...

*1989*

* * *

Карап торасың син: «Кагылмаса
Ярар иде»,— дигән шик белән.
Синең белән күрешүгә кадәр
Кулларымны юдым чык белән.
Тормышыңда кемгә очрарсыңдыр,
Син бит көйсез язмыш иркендә.
Кулдан төшеп китсәң, бәллүр сыман,
Җыеп ала алмас беркем дә.
Синең фәрештәгә тиңлегеңне
Белми дисең мәллә, бик беләм.
Сөенечтән битләремне юдым
Керфек очындагы чык белән.

*1990*

* * *

Иркәләр дә, сылулар да бетмәс,
Туып тормаса да гел генә.
Башка Галиябану инде тумас —
Татарда ул бары бер генә.
Шушы таныш көйне җырлый-җырлый,
Мин дә бүрәнәгә абынам,
Заман хисләренә кагылам да,
Галиябану, сезне сагынам.
Еллар узган саен сагындырыр
Мәхәббәткә тугры корбаннар.
Килде Исмәгыйльләр, киллер булып,
Акча өчен ата торганнар...

*1998*

## Ямады

«Сез каян?» диеп сорасалар әгәр,
Без оялып башны имибез,
«Әйтүе дә бик уңайсыз инде,
Ямадыдан гына...» димибез.

Безне әрәм итми, адәм иткән
Серле бер авыл ул — Ямады.
Чит-ятларга бер дә сиздермибез, —
Булса да ул кырык ямаулы.
Безнекеләр бөтен тирә-якта
Ямаучылар белән дан алган.
Әткәйләрдән калган гимнастерка
Әнкәй кулы белән ямалган.
Якын күреп, каян килсәләр дә, —
Иң кадерле кунак саныйбыз,
Казан төбе әгәр тишек икән, —
Сер бирмибез, бик тиз ямыйбыз!
Үз җиребез үзебезгә якын.
Булмасак та яный торганнар,
Явыз ният белән килгәннәрнең
Колак төбен ямый торганнар!
Киленнәр дә бездән зарланмыйлар,
Кilә алмый безгә андыйлар.
Казанда да бер дә боекмыйлар, —
Тишек оекларны ямыйлар.
Хәерчеләр түгел, үзебезне
Иң бай кеше итеп санарлык,
Ямаулыклар һич бетәрлек түгел,
Җирнең бар ертыгын ямарлык!
Оялмадык, горурландык кына
Борынгылар биргән исемнән,
Ямадыны эзләп табалабыз
Болындагы чәчәк исеннән.
Йөрәк ертыкларын сиздермичә,
Без шаярдык, көлдек, уйнадык,
Ямауларны бездән соңгыларга
Калдырмаска диеп уйладык, —
Тик җыр калдырырга уйладык.

Ямаулыклар берчак онтылырлар,
Мәзәк булып кына калырлар,
Ямадыны ямаулардан түгел,
Без калдырган җырдан танырлар!

*1996*

## Юлбарыс һәм без

Нишләргә? Нихәл итәргә?
Куркыныч чиктән ашкан!
«Сак булыгыз! Читлегәннән
Юлбарыс чыгып качкан!»
Тукта! Чү!..

Җанвар өзгәләп ташлаган
Бары бер сукбай этне?!
Юк иткән ул йоклап яткан
Бер мескен, бер көчекне?!

Адәмнәргә ташланмаган,
Көчәйсә дә нәфрәте.
Җанында ярсып типкәндер
Ирексезлек хәсрәте.

Аңа — читлек газабыннан
Иректә яшәү артык!
Әйтәләр: «Яшәтү өчен,
Ядрәсез генә аттык...»

Ният йоклату иде дә
Аңа мәрхәмәт кылып, —
Пуля йөрәгенә кергән
Үтергеч ядрә булып.

...Омтылабыз чын иреккә,
Кайчак шашып, котырып...
Сикерәбез,— читлек биек —
Булмый качып котылып.

Килерме бер читлек ватып,
Иреккә чыгар көннәр?
Йокламыйча һәм үлмичә
Юлбарыс булыр кемнәр?!

*2001*

## *Су буенда су эзлим...*

Кулларымда ике чиләк:
Куш чиләк.
Чайкалалар, икесе дә
Буш чиләк.
Йөрим Идел буйларында, —
Сусадым.
Чүлдә йөргән дөяләргә
Охшадым.
Табигатем, мәрхәмәтле
Булсачы,
Су буенда сулар эзлим
Бер тамчы!
Яна тәнем, яна җаным,
Иреннәр.
Су юлын таба алмыйлар
Киленнәр.
Янгынчылар, ник йоклыйсыз,
Кайдасыз?
Ярдәм сорап кычкырсам да,
Файдасыз.
Бирегезче бер тамчы су...
Әлсерим.
Су буенда саилчедәй
Су сорыйм.
Эзли-эзли таптым аны,
Ул — киткән,
Юлы гына калган бары —
Су — кипкән.
Хәлсезләнеп, кайнар җилдә
Чайкалам.
Буш чиләкне яңгыратып,
Чаң кагам:
Төшме, өнме? Өнме, төшме?
Ни соң бу?
Бу — һәлакәт өндә юктыр
Дисеңме?

*2000*

## Хыянәт төне

«Алар бөтенесе тере,
сез күрмисез генә...»

*«Бәкара» сүрәсеннән.*

Чыгалар да гүрләреннән
Калкалар...
Кемнәр алар?
Илне, Җирне һәлакәттән
Коткарган ирләр алар!

Күмелгән йә күмелмәгән,
Йә туфрак, көлләр алар.
Каберләрдән күтәрелә
Шәүләләр...
Кемнәр?
Алар!

Суга баткан,
Утта янган,
«Киләчәк аңлар»,— диеп, —
«Сугыштан соң тумый калмас
Иң тыныч таңнар»,— диеп.

Әллә төшме? Әллә өнме?
Әллә көнме? Әллә төн?
Ил югалткан сәгадәтен,
Ил югалткан сәгатен.

Шәүләләр — асфальт урамда...
Кемнәр көлә? Кем елый?
Таң да түгел, кич тә түгел,
Төннәр көлә... Төн елый.

«Без киткәч тә бу дөньяга
Кемнәр туган? Кем килгән?
Гөлләр сулган. Җаннар туңган.
Көннәр, еллар тилергән!

Түзәлмичә, каберләрдән
Өскә калыктык бүген.
Без коткарган ил түгел бу, —
Кара төн каплый күген.

Ишетелми таныш моңнар.
Чит авазлар — тоташтан.
Айныклар — гамьсез йокыда.
Төн исергән, төн шашкан.

Кем буласыз? Ни кыласыз?
Кайсы кавем яшьләре?
Кем буласыз — кыйбласыз
Адашканнар гаскәре?

Бишекләрдә елап калган,
Инде хаким малайлар.
Тол карчыклар каршысында
Ник төзисез сарайлар?!

Карт аналар, ярдәм-шәфкать
Сорарлык хәлегез юк.
Күзләрдә яшь тә калмаган,
Еларлык хәлегез юк.

Исән-сау кайткан яудашлар,
Горур башларын иеп,
Йөриләр, гаепле сыман:
«Ник исән калдык?..» — диеп.

Урамда хәер сорашкан
Аяксызлар-кулсызлар,
Тик хәмердә шатлык тапкан
Бәхетсезләр, юлсызлар...

Кайларга бордың юлыңны,
Кайчандыр туры урам?
Фахишәләр һәм угрылар,
Сукбайлар тулы урам?

Талап һәм кадап китәрләр,
Без тере булсак әгәр.
Хәтта шәүләгә куркыныч —
Кулларда — пычак, хәнҗәр.

«Әле дә эшсез калмадык...» — дип,
Хатыннар бомба ясый,
Самолетлар үлем йөген
Илдәшләренә ташлый.

Йортта буласы балалар
Нигә сугышта — утта?
Берсе хәбәрсез югала,
Берсе кайта табутта.

Кем ул елый, төнне ярып,
Аваз сала дөньяга?
Ниләр күрер? Туганына
Үкенмәсме бу бала?

Төннәрен табыш алам дип,
Кемдер эш кырып ята,
Эзли торгач, эш табам дип,
Кемдер төш күреп ята.

Барыр юлга каршы төшеп,
Урамда кемнәр йөри?
Фәрештәләр Күккә ашкан,
Иблисләр-җеннәр йөри.

Уйладык без: бу — дөньяда
Иң соңгы сугыш булыр,
Балаларга, оныкларга
Бәхетле тормыш булыр...

Түзәлмичә, каберләрдән
Калыктык бүген өскә.
Әллә инде илебезне
Калдырдык үкенечкә?

Саклап калган илебезгә
Яный рухи кыямәт...
Шәһитләрнең хыялына
Кемнәр итте хыянәт?!

Без бит җиңеп үлгән идек,
Җиңелдегез нигә сез?
Капчык тотып, хәер сорап,
Җиңелгәнгә киләсез.

Берчак таң атармы, юкмы?
Беркем белми... әле төн...
Әллә томан, әллә төтен...
Гавам җуйган өметен.

Ай да, йолдызлар да качкан
Җиде төн уртасында
Бер генә өмет нурлана:
Мәчет манарасында.

Әллә шагыйрь, әллә галим,
Әллә залим... ут алган.
Кайсы җиңеп өстен чыгар?
Өн белән төш буталган.

Ник ябылган адәмнәргә
Күкнең кара пәрдәсе?
Гөнаһлары өчен Аллаһ
Ташлаганмы әллә соң?

Йоклап ятмагыз, торыгыз,
Урамнарга чыгыгыз,
Кара кыямәт төненең
Таңнарын аттырыгыз!

Ачларыбыз, тукларыбыз,
Җанаш, оныкларыбыз,
Шат булсагыз гына тыныч
Булыр йокыларыбыз...

Тик бер генә төнгә кайттык,
Китеп тә югалабыз,
Газаплы өметләр белән
Гүрләргә юл алабыз.

Узармы хыянәт төне,
Таралырмы томаннар?
Килсә чын кыямәт көне,
Ни кыларсыз, туганнар?»

Әллә төшме, әллә өнме?
Әллә көнме, әллә төн?
Ил югалткан сәгадәтен,
Тыныч яшәү гадәтен.

Киттеләр дә югалдылар...
Киттеләр...
Кемнәр алар?
Анда да җирне күтәреп
Торучы ирләр алар!

Анда да безне күтәреп
Торучы каһарманнар.

*2000*



*Кәефем юк, диеп тормагыз,*
*Җырлагыз.*
*Күңел тулганда да,*
*Өмет сулганда да*
*Җырлагыз,*
*Җырсыз гомер итеп сулмагыз!*

## *Озак яшисегез килсә...*

Җырлагыз...
Сәләтем юк, диеп тормагыз.
Авыр булганда да,
Юллар уңганда да
Җырлагыз,
Тавышым юк, диеп тормагыз.
Эчең пошканда да.
Дуслар кушканда да
Җырлагыз,
Кәефем юк, диеп тормагыз.
Җырлагыз,
Күңел тулганда да,
Өмет сулганда да
Җырлагыз,
Җырсыз гомер итеп, сулмагыз.
Җырлагыз,
Яшьлек узганда да,
Йөрәк сызганда да
Җырлагыз,
Башыгызны иеп тормагыз,
Җырлагыз,
Бәйрәм иткәндә дә,
Шатлык киткәндә дә,
Гомерегезне сузып җырлагыз,
Җырлагыз.
Тавышым юк, диеп тормагыз,
Тавыш беткәндә дә,
Гомер үткәндә дә,
Эчтән генә... түзеп, җырлагыз,
Җырлагыз,
Гомерләрне узып җырлагыз,
Җырлагыз,
Үзегезгә үзегез җырлагыз,
Җырлагыз...

*1995*

## Төнбоек*

Төнбоеклар, төнбоеклар
Күзләрен йомып йоклар.
Тик минем генә күзләрем
Сагынудан боеклар.

Төнбоекларга карасам,
Йөрәгем дулкынлана.
Сөйгәнеңне төнбоекка
Карап сагынырга кала.

Килер көтелгән минутлар,
Уяныр төнбоеклар.
Алар, кояшта елмаеп,
Безнең кавышуны котлар.

*1953*

* Л.Айтуганов музыкасы.

# Сине уйлап янам*

*(«Миләүшә» поэмасыннан)*

Җәйләүләрдә тугай,
Тугайларда тургай,
Җилләргә лә каршы баралмый.
Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман,
Күңелем эзли сине, табалмый.

Карурманга таба
Чишмә чыңлап ага,
Җил көчәйтә аның агышын.
Мин утырам тыңлап,
Шул сулардай чыңлап,
Агып китәр микән сагышым?

Җәйләүләрдә тугай,
Тугайларда тургай
Канатларын җилпи җилләрдә.
Сине уйлап янам,
Ник килмисең һаман,
Күңелләрең синең кемнәрдә?

*1954*

* С.Ибраһимов музыкасы.

## Яшьлек дустыма*

Ядкәр язам мин сиңа, дустым,
Китәм ерак якларга,
Яшьлегеңне искә төшерерсең,
Бик ямансу чакларда.
Онытма син, гел бергә йөрдек,
Аерылмас дус идек,
Каршыладык күпме таңнарны,
Бергә сөйдек ярларны.
Ядкәр булсын ялкынлы яшьлек,
Эзе калсын елларда,
Онытмаска сүзләр куешып без,
Кузгалабыз юлларга.
Җырла син дә бу моңлы җырны,
Көннәрең булсын нурлы,
Мәңге сакла дуслык сүзләрен:
Җирдә калсын эзләрең.

* М.Яруллин музыкасы.

## Зөфәр җыры*

*(«Таныш моңнар» поэмасыннан)*

Йомшак җилләр булып исәрмен дә
Тәрәзәңне килеп кагармын,
Мин кагармын, син качарсың, —
Йөрәгемә утлар ягармын.
Гөлчәчәкләр булып үсәрмен дә
Тәрәзәңә үрелеп карармын,
Мин карармын, син качарсың,—
Сөю ялкынында янармын.
Йолдыз булып күккә менәрмен дә
Өй турыңда балкып янармын,
Мин янармын, син качарсың,—
Төсең итеп кемгә багармын.

*1955*

* Ш.Мәҗитов музыкасы.

## Резидә җыры*

*(«Таныш моңнар» поэмасыннан)*

Резидәкәй, зәңгәр күлмәгең
Кайсы елгаларда чайкадың?
Синнән гүзәл ярлар күрмәдем мин,
Синнән гүзәл ярлар тапмадым.
Резидәкәй матур эзләрен
Шаулы урамнардан эзләдем,
Эзләдем, тик барыбер мин тапмадым,
Бер җырладым өзелеп, түзмәдем.
Сине эзләп сулар буйладым,
Синдә генә минем уйларым,
Резидәкәй бәгърем, ник дәшмисең,
Кайда синең зифа буйларың?

*1955*

* Ш.Мәҗитов музыкасы.

## Яшь наратлар*

«Яшь наратлар» көен җырлап киттең,
Көмеш кыңгыраулы пар атта.
Озатып кайтам сине, карый-карый
Бөдрәләнеп үскән наратка.

Басылмады йөрәк ярсулары,
Басылса да юллар тузаны.
Синең җырың шунда калган кебек,
Яшь наратка карап узамын.

Әле дә булса минем йөрәгемдә
Көмеш кыңгыраулар чыңлыйлар,
Урман буендагы яшь наратлар
Син калдырган көйне җырлыйлар.

*1959*

* Җ.Фәйзи музыкасы.

# Фәүзия җыры*

*(«Янар чәчәк» пьесасыннан)*

Нинди матур озын юлга чыктык,
Янар чәчәк иде юл башы.
Чәчәк сулган, синең йөрәгеңә
Ниләр булган, яшьлек юлдашым?

Яшьлегемне искә төшергәндәй,
Дәфтәр битен кечке җил ача.
Еракларда калган тавышыңны
Җил дә алып килми, ичмаса.

Мин югалттым янар чәчәгемне,
Күзләр җиткән, эзлим, табалмыйм.
Ут сал минем сүнгән йөрәгемә,
Синнән башка балкып яналмыйм.

*1955*

* М.Яруллин музыкасы.

## Кайтам инде*

Ямансулап болыннарны буйлама,
Оныткандыр инде, диеп уйлама.
Ничек итеп онытыйм мин ярымны,
Кара кашлы, назлы җанымны.

Ничек итеп онытыйм туган ягымны,
Анда узган алтын бала чагымны.
Сагындырды Агыйделнең камышы,
Челтерәп аккан чишмә тавышы.

Сагындырды сызылып таңнар атуы,
Әнкәемнең иркәләп уятуы.
Кайтам инде туып-үскән ягыма —
Кырларыма, тугайларыма...

*1958*

* С. Садыйкова музыкасы.

# Ике малай китә армиягә

Язгы ташуларда
Аккан бозга басып,
Икәү килә елга буйлатып,
Берсе җырлый шашып,
Изүләрен ачып,
Икенчесе килә уйнатып:
— Сау булыгыз, кызлар,
Сагынырсыз, кызлар,
Таң атканда инде булмабыз,
Сагынсагыз әгәр,
Без кайтканга кадәр
Шушы көйне отып җырлагыз.
Бозлар ага, бозлар,
Күрәсезме, кызлар,
Без китәбез инде, соң булыр...
Язгы җилләр исәр,
Исегезгә төшәр,
Бездән сезгә сәлам шул булыр.
Ил чикләре көтә,
Ике малай китә,
Шау-шу тынар әле боз киткәч,
Сау булыгыз, кызлар,
Сагынырсыз, кызлар,
Сагынырсыз әле без киткәч...
Язгы ташуларда
Аккан бозга басып,
Икәү килә елга буйлатып,
Берсе җырлый шашып,
Изүләрен ачып,
Икенчесе килә уйнатып...

*1960*

* Ә.Даутов музыкасы.

## Шофер*

Шофер,
Син машинаң белән
Ил байлыгын ташып йөртәсең.
Караңгы төндә дә,
Давыллы көндә дә
Барлык авырлыкларны
Җиңел үтәсең.
Шофер,
Тыңла мотор тавышын,
Карама җилгә, давыл, яңгырга.
Күпер юк, дип торма,
Яңа юллар эзлә,
Ятып калма кырда,
Эчең пошса, матур җыр җырла.
Шофер,
Очасың җил кебек,
Ак каеннар калалар җилпенеп.
Кырлар тыңлый синең
Дәртле җырларыңны,
Кыскарт тизрәк барыр
Ерак юлларыңны,
Шофер,
Иркәң кочагына
Очып кайт син,
Кайт син җилкенеп.

*1959*

* Ш.Мәҗитов музыкасы.

# Бөркет турында җыр*

*(«Бөркетләр кыяга оялый» комедиясеннән)*

Хәбәр булып
Килде болыт,
Кояш нурын каплады.
Давыл узды,
Оя тузды —
Бөркет дустын тапмады.
Ә баласы —
Күз карасы —
Сизмәде дә яшенне.
Ике канат,
Канап-канап,
Зур давылдан яшерде.
Очты бөркет,
Төште бөркет,
Йөрәгендә ярасы.
Яшь аралаш
Елмая ул:
Югарыда — баласы.
Ә баласы —
Күз карасы —
Сизмәде дә яшенне.
Ике канат,
Канап-канап,
Зур давылдан яшерде.

*1970*

*С.Садыйкова музыкасы.

## Уникe аккош*

Бу нинди аклык,
Бу нинди балкыш?
Аяз күкләрдә —
Унике аккош.
Илләргә кайта
Кошлар берьюлы —
Җәлилчеләрнең
Ахыргы җыры.
Илләр өстеннән,
Күлләрдән оча,
Егетләр туган
Җирләрдән оча.
Димнәрдән оча,
Сакмардан оча,
Илнең аклыгын
Сакларга куша.
Тирбәлә ул җыр
Яз, күзләрен дә
Халык күңеле
Диңгезләрендә.
Унике егет
Аккош юлында,
Алар гомере
Аккош җырында.
Аккошлар җырын
Аклыйсы иде,
Җирне саф килеш
Саклыйсы иде!
Саклыйсы иде!

*1972*

* Р.Яхин музыкасы.

## Серле чәчәк*

Исмеңне дә белмим,
Төсеңне дә белмим,
Хыялымда гына дәшәмен,
Кичен күзен йомып,
Иртән керфекләрен
Ача торган серле чәчәгем.

Таңга каршы чыгып,
Күпме еллар сине
Табу уе белән яшәдем,
Кичен күзен йомып,
Иртән керфекләрен
Ача торган серле чәчәгем.

Бер иртәне эзләп
Табармын да сине
Исемең белән сөеп дәшәрмен...
Юк, мин өзмәм сине,
Җилләр тидермичә,
Гомерем буе назлап яшәрмен,
Кичен күзен йомып,
Иртән керфекләрен
Ача торган серле чәчәгем...

*1972*

* М.Яруллин музыкасы.

## Каршы ал, туган калам![*]

Әниләр җылысы
Ят җирдә юк икән,
Казаным, Казаным!
Синнән дә ягымлы
Як җирдә юк икән,
Казаным, Казаным!

К у ш ы м т а:

Диңгезләрдән, тайгалардан,
Ерак-ераклардан,
Әй!
Изге моңнар тартты сиңа табан,
Каршы ал, туган калам!

Сөйгәнем шикелле
Мине дә көткәнсең,
Казаным, Казаным!
Син — туган ягымның
Йөрәге икәнсең,
Казаным, Казаным!

К у ш ы м т а.

Алдыңда баш иеп,
Кабатлыйм күңелдән:
Казаным, Казаным!
Аерылмам Иделдән,
Аерылмам Илемнән,
Казаным, Казаным!

К у ш ы м т а.

*1972*

* Л.Хәйретдинова музыкасы.

## Балачак чишмәсе*

Челтер-челтер, челтер-челтер
Болында
Челтерәп,
Чишмә ага, балачак
Турында
Җыр җырлап.
Җәйге көндә иелеп сулар
Эчкәндә
Без бергә,
Күрә идек икебезне
Рәсемдә —
Чишмәдә.
Чишмә күзе бик тирәннән
Ургыла,
Тын гына
Әйткән кебек:
«Ул гына юк
Янында,
Ул гына».
Чишмә күзе кебек иде
Күзләрең,
Аппагым,
Гомеремнең көзләрендә
Эзләдем,
Тапмадым.
Челтер-челтер акты-китте
Тиз генә
Балачак...
Их, тагын бер болындагы
Көзгегә
Карасак...
Күпме сулар акмаган ла,
Саф җилләр
Исмәгән,
Күзләреңнең чагылышын
Эзлимен
Чишмәдән.

---

* Р. Абдуллин музыкасы.

Көзге җилләр, сискәндереп,
Исмәгез
Таллыктан,
Челтер-челтер челтерәми
Чишмәбез, —
Саеккан.
Эзләребез табылмаслар:
Аңладым
Үзем дә...
Көзге җилләр кагылмаслар
Җандагы
Рәсмеңә.

*1961*

## Таң кызы җыры*

*(«Соңгы төн» трагедиясеннән)*

Таң җилләре чәчләремне
Уйнап сүтәләр,
Тын дулкыннар йөрәгемне
Назлап үтәләр.
Уйларымны белгән сыман,
Җилләр исәләр,
Алар минем җилкәнемне
Сиңа илтәләр.
Таң җилләре, алдан барып,
Җаның иркәләр,
Өзелеп сөю сәламнәрен
Хәбәр итәрләр.
Серле көчләр җилкәнемне
Сиңа илтәләр,
Төнбоеклар сөенечле
Таңны көтәләр.
Җылы нурлар төнбоекның
Яшен сөртәләр,
Сөю бәхетенә тусын
Таңнар, иртәләр...

*1982.*

* М.Яруллин музыкасы.

# Туган ягым каеннары*

*(«Олы юлның каены»ннан)*

Туган ягым каеннары калалар инде,
Озатыша баралар инде,
Йөрәгемдә яфракларын яралар инде,
Сагышларга салалар инде.

Каеннарым калмый һаман чабалар инде,
Ерагая аралар инде,
Киткән саен якыная баралар инде,
Сагынудан дәвалар инде.

Туган ягым каеннары калалар инде,
Кемнәр сөеп карарлар инде,
Гомерем буе миңа таба чабарлар инде,
Кайтмый һич тә калалмам инде.

*1983*

* М.Имашев музыкасы.

## Чит илләргә чыксаң...*

Китмә, диләр, бездә калып җырла...
Әллә инде аңлый алмыйлар:
Туган илдән киткән сандугачлар
Чит җирләрдә сайрый алмыйлар.

Мин сандугач түгел, җырлыйм өзелеп,
Туган якка уем тартылган.
Сандугачтай читтә саргайганчы,
Очып кайтам җырым артыннан.

Адашканнар, сагынып тилмергәннәр
Бу җырымнан эзләп тапсыннар,
Телсез-җырсыз калган сандугачлар
Туган илләренә кайтсыннар.

Мин сандугач түгел, җырлыйм өзелеп.
Илсез саргаюлар чын икән...
Чит илләргә чыксаң, озак торма,
Гыйбрәт алыр өчен чык икән.
Мин сандугач түгел, җырлыйм өзелеп,
Туган якка уем тартылган.
Сандугачтай читтә саргайганчы,
Очып кайтам җырым артыннан.

*1980*

*С.Садыйкова музыкасы.

## Ерактагы үзәннәр*

Кояшлы да, томанлы да
Ерактагы үзәннәр,
Туган җир үзәннәрендә
Көтә безне гүзәлләр.
Һәр көн саен якыная
Ерактагы үзәннәр,
Еракларны якынайта
Йөрәктәге гүзәлләр.
Ерак шикелле тоела
Якындагы үзәннәр,
Җанга якын мең һәм миллион
Чакрымдагы гүзәлләр.
Еракларда, томаннарда
Без яраткан үзәннәр,
Кайтырбыз бер, томаннарны
Таратырбыз, гүзәлләр!

*1984*

* З. Хәбибуллин музыкасы.

# Гашыйклар тавында*

*(Шул исемдәге әсәрдән)*

Ниндидер моңнар бар,
Ниндидер шомнар бар
Каеннар, имәннәр шавында,
Онытыйк шомнарны,
Каршылыйк таңнарны
Бергәләп Гашыйклар тавында.

Без — тауның башында,
Мәңгелек каршында —
Гашыйклар кавышкан урында.
Җанда — Ай нурлары,
Хисләр саф, югары:
Биектә — Киек Каз Юлында.

Син әле янымда.
Хушлашу таңында
Сүз бирик изге Жир алдында:
Аерылган көннәрдә
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында!

*1985*

* М.Имашев музыкасы.

# Яралы кош*

*(«Гашыйклар тавы»ннан)*

Кыр үрдәген аттым очкан чакта...
Җаным әрни көн-төн — ник аттым?
Хәзер үзем яралы кош сыман:
Кайтыр юлларымны югалттым.

«Туган якларыңа кайт! Кайт!» — диеп,
Киек кошлар тезелеп киткәндер...
«Кайта» диеп өзелеп көткәндер дә,
Көтә-көтә түземе беткәндер.

Яралы кош, бәлки, кайтып җитәр...
Мин язмыштан инде ычкынмам.
Танырсыңмы, юкмы — мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган...

*1985*

* М.Имашев музыкасы.

## Җиләккә дип барган идем...*

*(«Гашыйклар тавы»ннан)*

Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым,
Сине күргәч, сүзсез калдым,
Адаштым, дип алдаштым.

Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде,
Кырын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде.

Җиләклеккә бармам инде,
Бармам инде, адашмам,
Карурманда адаштым, дип,
Инде бүтән алдашмам...

*1985*

* В.Әхмәтшин музыкасы.

## Онытма мине*

*(«Гашыйклар тавы»ннан)*

Сакла мәңгегә истәлегемне,
Исә юл җиле, аерылу җиле.
Сау бул, саф гөлем,
Зәңгәр яшьлегем,
Онытма мине!
Онытмам сине!

Калыр еракта Гашыйклар иле,
Кагылыр килеп яшьлегем җиле.
Кайтыр моң булып,
Әйтер мин булып:
Онытма мине!
Онытмам сине!

Тормыш юлында, гомерем соңында
Яшьлек дәфтәрен актарсаң иде...
Күңелең үсәр,
Исеңә төшәр:
Онытма мине!
Онытмам сине!

*1992*

* И.Сафин музыкасы.

## Яшьлек узган сукмакларым*

Яшьлек узган сукмакларым,
Алып барасыз кая?
Яшь каеннар арасында
Балачагым елмая.
　　Хыялымда
　　Гел янымда
　　Онтылмас ярым атлый,
　　Хисләр кайта,
　　Төсләр кайта,
　　Яшьлегем генә кайтмый.
Яшьлегемнең юлдашлары:
Карт каеннар, юкәләр,
Яфракларын коя-коя,
Салкын көзгә илтәләр.
　　Хыялымда
　　Гел янымда
　　Онтылмас ярым атлый,
　　Хисләр кайта,
　　Төсләр кайта,
　　Яшьлегем генә кайтмый.
Яшьлек узган сукмакларым
Калды зәңгәр урманда.
Юксынам, эзлим, табалмыйм,
Балачагым, син кайда?
　　Хыялымда
　　Гел янымда
　　Онтылмас ярым атлый,
　　Хисләр кайта,
　　Төсләр кайта,
　　Яшьлегем генә кайтмый...

*1992*

* И.Мәҗитов музыкасы.

## Тузганак*

Кузгалаклы болыннар,
Тузганаклы болыннар,
Балачак узган урыннар,
Чәчем тузган урыннар.
        Кузгалаклы болыннардан
        Йөрим һаман узгалап,
        Җилләр искән, очкан-киткән —
        Балачагым — тузганак.
Сибелделәр чәчләрем,
Акты-китте яшьләрем,
Күрешергә килгән идем, —
Балачак, ник дәшмәдең?
        Кузгалаклы болыннардан
        Йөрим һаман узгалап,
        Җилләр искән, очкан-киткән —
        Балачагым — тузганак.
Эзлим туган җирләрдән,
Йөгереп менгән үрләрдән,
Кире җыеп алыр идем,
Мөмкин булса, җилләрдән...
        Кузгалаклы болыннардан
        Йөрим һаман узгалап,
        Җилләр искән, очкан-киткән —
        Балачагым — тузганак...

*1994*

* Р.Абдуллин музыкасы.

## Сөйгәнемнең туган көне*

*(Шул исемдәге драмадан)*

Калды ерак күзләремне
Шатлык моңы юган көне...
Җырлата да,
Елата да
Сөйгәнемнең туган көне.

Хәзер бигрәк күңелемнең
Мөлдерәмә тулган көне.
Зинһар, авыр
Кагылмагыз —
Сөйгәнемнең туган көне.

Юк һәм булмас минем өчен
Мәхәббәтнең сулган көне...
Яу кырында
Ятып калган
Сөйгәнемнең туган көне.

*1985*

* Ф.Әхмәтов музыкасы.

## Әллә күрешәбез, әллә юк...*

Башка төшкән кайгы-шатлыкларны
Әллә бүлешәбез, әллә юк...
Озат инде, озат,
Кайта алмам озак,
Әллә күрешәбез, әллә юк.

Бала вакыттагы хыялларга
Әллә ирешәбез, әллә юк...
Үрләр көтә алда,
Ниләр көтә анда,
Әллә күрешәбез, әллә юк...

Безгә дигән кырыс язмыш белән
Әллә килешәбез, әллә юк...
Кулда — җылың кала,
Юлда — җырым кала,
Әллә күрешәбез, әллә юк...

*1994*

* Г.Сәйфуллин музыкасы.

## Балачак хыяллары*

*(«Сөйгәнемнең туган көне»спектакленнән)*

Салават күпере сыман
Калса да балачагым,
Тоям гомерем буена
Озата барачагын.

Кайчак тирән уйга талам,
Карыймын да каерылып:
Балачагым хыялыннан
Калмадыммы аерылып?

Салават күпере сыман
Балачак хыяллары.
Балачагым хыяллары
Канатлар куяр әле.

Салават күпере сыман
Калса да балачагым,
Тоям гомерем буена
Озата барачагын.

*1985*

* Ф.Әхмәтов музыкасы.

## Әнкәемнең туган ягында*

Гомер таңнарында, җырлый-җырлый,
Ул чишмәгә карап юл алган.
Әнкәм җыры сыман челтери-челтери,
Чишмә җир астында югалган.
Хәзер инде башка кошлар сайрый
Ул су алган чишмә янында.
Җирнең йөзе шундый якты, нурлы
Әнкәемнең туган ягында.
Сагынуга һич тә түзәлмичә,
Колак салып җирне тыңладым,
Ишеттем мин чишмә чыңнарында
Әнкәемнең яшьлек җырларын...

*1985*

* Ф.Мортазин музыкасы.

## Кыр казлары артыннан*

*(Шул исемдәге драмадан)*

Кыр казлары артыннан
Биеклеккә тартылам.
Хыялыма китәр идем
Кыр казлары артыннан.

Кыр казлары артыннан
Китәр идем, тартынам,
Үз-үземне бәйләгәнмен
Хыялым канатыннан.

Кыр казлары артыннан
Очарга дип талпынам.
Тик очалмыйм, карап калам
Кыр казлары артыннан.

*1976*

* М.Имашев музыкасы.

## Мәтрүшкәләр*

Мәтрүшкәләр, кипкән мәтрүшкәләр
Ераклардан әнкәм җибәргән.
Яшьлегемнең моңсу чәчәкләре
Туган кырларымда тирбәлгән.

Тирән сагынудан уйчанланган
Күз карашым сезгә төбәлгән.
Әйтегезче миңа, мәтрүшкәләр,
Ни әйтергә әнкәм теләгән?

Мәтрүшкәләр мине уяттылар
Сискәндереп гамьсез төннәрдән:
«Гөл-чәчәкләр кебек кибәрсез сез
Өзелсәгәз туган җирләрдән».

*1972*

* А.Гыйләҗев музыкасы.

## Хуш инде*

Хуш инде. Мәңгегә
Хуш инде.
Китә яз, китә наз,
Кыш инде.
Тагын бер текәлеп
Карыймчы.
Рәсемеңне күңелемә
Алыймчы.
Ул китә. Кайтмаска
Дип китә.
...Соң килде мәхәббәт,
Ник китә?
Чаналар кузгалып
Киттеләр,
Йөрәкне сыздырып
Үттеләр.
Эзләрен кар-буран
Сылады.
Юлларга җил ятып
Елады.
Хуш инде. Мәңгегә
Хуш инде.
Китте яз... Буранлы
Кыш инде.

*1972*

* Ф.Мортазин музыкасы.

# Утыраек әле чак кына...*

*Рафаил һәм Туфанга*

Сез дә минем кебек үзгәргәнсез,
Сез дә минем кебек аргансыз.
Сез дә минем кебек, кош сайравын
Тыңлый-тыңлый, телсез калгансыз...
  Агыйделнең төнге сандугачы
  Сайрашырга безне чакыра.
  Китмик әле, дуслар, китмик әле,
  Утыраек тагын чак кына.
Сез дә, минем кебек, суга карап,
Бер көрсенеп, «Их!» дип куясыз...
Сез дә, минем кебек, гомерләрнең
Агып китүләрен тоясыз.
  Агыйделнең төнге сандугачы
  Серләшергә безне чакыра.
  Китмик әле, дуслар, китмик әле,
  Утыраек тагын чак кына.
Сез дә, минем кебек, уйга талган,
Сез дә минем кебек дәшмисез...
Сандугачның үзәкләрен өзеп,
Әкрен генә көйли башлыйсыз.
  Агыйделнең төнге сандугачы
  Уйланырга безне чакыра.
  Бу гомернең кыскалыгын тоеп,
  Утыраек әле чак кына,
  Китмик әле, дуслар, бу дөньядан,
  Безнең әле яшәр чак кына...

*1994*

* Р.Хәким музыкасы.

## Син мине бәхетсез итмәдең*

Беләм бит, күрәм бит, сизәм бит,
Син мондый киләчәк көтмәдең.
Рәнҗемә, кадерлем, ахрысы,
Мин сине бәхетле итмәдем.
Беләм бит, күрәм бит, сизәм бит,
Хыялың чигенә илтмәдем.
Рәнҗемә, кадерлем, ахрысы,
Мин сине бәхетле итмәдем.
Беләсең, күрәсең, сизәсең
Минем дә хыялның чикләрен.
Тын гына, кадерлем, түзәсең...
Син мине бәхетсез итмәдең.

*1991*

* Р.Хәким музыкасы.

# Гази батыр турында баллада

Рейхстагка беренчеләрдән булып байрак кадаган Гази Заһитовка, батырлыгын танып, илле алты елдан соң гына Герой исеме бирелде.

Сабантуйда баганага
Бик күпләр үрләгәннәр.
Гази җиңүче булса да,
Бүләген бирмәгәннәр.
Мәйдан уртасыннан китеп,
Бала Гази югалган.
Халык телендә барыбер
Җиңүче булып калган.
Канлы яуда рейхстагка
Бик күпләр үрләгәннәр.
Байракны Гази элсә дә,
Нигәдер күрмәгәннәр.
Сугыш мәйданыннан китеп,
Батыр Гази югалган.
Халык телендә барыбер
Җиңүче булып калган.
Белүчеләр, күрүчеләр
Өметне өзмәгәннәр.
Соңлап булса да, Хаклыкны
Тапканнар, эзләгәннәр.
Тормыш мәйданыннан китеп,—
Батыр Гази югалган.
Халык телендә барыбер
Җиңүче булып калган.

*2002*

# Моңлы бала*

Ник син бигрәк моңлы бала, дисез...
Сандугачлы талда үскәнгә,
Язмыш агачында тирбәләм дип,
Канатларым сынып төшкәнгә.

Ник син бигрәк моңлы бала, дисез...
Җилгә каршы ишкәк ишкәнгә,
Тормыш көймәсендә йөзә-йөзә,
Хәсрәт дәрьяларын эчкәнгә.

Ник син бигрәк моңлы бала, дисез...
Гомерем җилләр кебек искәнгә,
Җаннарымда сайрар сандугачым
Исләремә килеп төшкәнгә.

*2001*

* Ә.Шәрәфиев музыкасы.

## Юлчы чишмәсе*

Тукта, юлчы,
Кунак булчы,
Юлларда аргансыңдыр,
Челтер-челтер агышымны
Ишетеп калгансыңдыр.
    Эчми китмә юлчы чишмәсен,
    Туган җирнең җырчы чишмәсен.
Арган юлчы,
Битең ючы,
Тирәннән агып чыгам.
Табигатьнең серле көчен
Мин сезгә алып чыгам.
    Туган җирнең җырчы чишмәсен
    Бер юлчы да эчми китмәсен.
Калма, юлчы,
Арма, юлчы,
Бик еракка барасың.
Килә минем йөрәгеңә
Дәрман биреп агасым.
    Эчми китмә юлчы чишмәсен,
    Туган җирнең җырчы чишмәсен.
Исән булчы,
Сау бул, юлчы,
Сагышың — җилдәй иссен.
Тиз барырсың,
Челтер-челтер
Агышым — сиңа көчсен.
    Туган җирнең җырчы чишмәсен
    Бер юлчы да эчми китмәсен.

*2001*

---

* Ә.Шәрәфиев музыкасы.

## *Кайттым, әнкәй...**

Яулар тынгач, ерагайгач,
Сугышлардан аралар,
Тын гына кайта чит җирдә
Ятып калган балалар:
«Ач ишегең, кайттым, әнкәй,
Хәлләреңне белергә,
Бездән соң калган тормышның
Ниндилеген күрергә.
Саумы, әнкәй, исәнлекме,
Илләр-җирләр иминме?
Мәңгелек ут дияр идем
Синең һәрбер көнеңне.
Ышанычың — һәр көн чыккан
Кояшларга тиң икән,
Бер минут та онытмаган,
Мәңге көткән — син икән.
Тәрәзәңне чиртәм, әнкәй,
Мин кайттым ич, җил түгел,
Шул кадәре көтүләргә
Кайтмый һич мөмкин түгел.
Тик ашыкма ишегеңне
Тулы ачып куярга.
Мин бит, әнкәй, кайттым бары
Синең изге хыялда...
Синең изге хыялда...»

*1982*

* Р.Әхиярова музыкасы.

## Кырларда туган җырым*

Буразнада шытып чыккан,
Кырларда туган җырым...
Тургае белән каршылый
Моң белән тулган җирем.
    Буразнасын сагынып кайткан,
    Кырларда туган җырым,
    Игеннәрдә кырлар моңы,
    Мин алдым шулар моңын.
Буразнада шытып чыккан,
Кырларда туган җырым,
Җанда тургай җыры барда
Бай рухлы булыр Җирем.
    Буразнасын сагынып кайткан,
    Кырларда туган җырым,
    Игеннәрдә кырлар моңы,
    Мин алдым шулар моңын.

*1983*

* С.Шәмсина музыкасы.

## Шаян картлар җыры*

Көч бар чакта типтек инде
Бу дөньяның артына.
Хәзер дөнья безгә тибә
Китереп бар шартына.

К у ш ы м т а:

Аума, аума, атла туры,
Күтәр башың югары!
Киттек кызлар күзәтергә,
Урамда җил юк әле.

Кәефләр бик күтәренке...
Базар бәясе кебек.
Бик тиз узар, яшәп калыйк
Картлыкның кадерен белеп!

К у ш ы м т а.

Яшьлегемә йөгереп түгел,
Атлап та кайтмас идем,
Карчыктан да әйбәт ярны
Барыбер тапмас идем.

К у ш ы м т а.

Кемнәр әйтә, кем уфтана:
«Яшьлектән колак кактык...»
Картлыкның үзен яшәртеп,
Яшәве — үзе шатлык!

К у ш ы м т а.

*2000.*

* З.Гыйбадуллин музыкасы.

# Мин телим дусларга*

Мин телим дусларга
Көннәрнең яктысын,
Төннәрнең айлысын.
Күрмәсен башыгыз
Ялгызлык хәсрәтен,
Балалар кайгысын.

Кичерик ялгышны,
Үпкәне, шикләрне, —
Шул гына үтенеч.
Гомернең соңында
Телмәсен йөрәкне
Газаплы үкенеч.

Мин телим дусларга
Имәннәр ныклыгын,
Каеннар аклыгын.
Үтик без ирләрчә,
Тормышның зурлыгын,
Тормышның ваклыгын.

Мин телим дусларга:
Яшьлекнең сафлыгы
Саклансын җаннарда.
Гел шулай очрашыйк
Киләсе көннәрдә,
Хәерле таңнарда!
Сөенеп очрашыйк
Туасы елларда,
Бәхетле таңнарда!

*1996*

* Ф.Галимов музыкасы.

## Өзелмәс җыр*

Исәнме син, туган ягым,
Сагындырды җирең-күгең,
Чит җирләрдә һава-сулар
Синдәгедәй татлы түгел.
    Туган якның юллары да
    Өзелмәслек җырлар сыман,
    Балачагым чишмәләрдәй,
    Челтер-челтер чыгар сыман.
Сиңа булган омтылышым
Язгы судай ташып торды,
Кәккүкләрең, былбылларың
«Кайт! Кайт!» диеп ашыктырды.
    Туган якның юллары да
    Өзелмәслек җырлар сыман,
    Балачагым чишмәләрдәй
    Челтер-челтер чыгар сыман.
Исәнме син, туган ягым,
Сагындырды тау-ташларың,
Адашырлык хәлләрдә дә
Сине уйлап адашмадым.
    Туган якның юллары да
    Өзелмәслек җырлар сыман,
    Балачагым чишмәләрдәй
    Челтер-челтер чыгар сыман.
Исәнме син, туган ягым,
Без бит синдә оя корган,
Без үзебез чишмә инде
Диңгезләргә коя торган.
    Туган якның юллары да
    Өзелмәслек җырлар сыман,
    Балачагым чишмәләрдәй,
    Челтер-челтер чыгар сыман.

*1987*

* Р.Әхиярова музыкасы.

## Каен җиле

Каенлыкта
Җиләс иде.
Йөзләр якты,
Көләч иде.
    Юат әле,
    Каен җиле,
    Исмә, исмә,
    Кайгы җиле.
Ак каеннар
Төсле иде.
Хисле иде,
Көчле иде.
    Юат әле,
    Каен җиле,
    Исмә, исмә,
    Кайгы җиле.
Шомлы җилләр
Алып китте,
Хәсрәтләргә
Салып китте.
    Юат әле,
    Каен җиле,
    Исмә, исмә,
    Кайгы җиле.
Ак каеннар
Яшел иде.
Ул җанымда
Яши инде.
    Юат әле,
    Каен җиле,
    Исмә, исмә,
    Кайгы җиле.
Өзелеп сагынып
Җырлыйм инде.
Басылмасмы
Кайгы җиле.
    Юат әле,
    Каен җиле,
    Исмә, исмә,
    Кайгы җиле...

*2001*

## Ялгышасыз*

Канаты юк, димәсеннәр,
Миндә дә бар, бар канатлар,
Берсе — хыял, берсе — өмет:
Пар канатлар, пар канатлар.
    Тәндә җаным бар чагында,
    Иреннәрем гел кабатлар:
    Күтәрелик, очыйк әле,
    Бездә дә бар пар канатлар.

Кушымта:

Әллә мине яр сөймәгән дисезме?
Очынмаган, ярсымаган дисезме?
Сөю хисен кичермәгән дисезме?
Кайнар дәрттән исермәгән дисезме?
Акылыннан адашмаган дисезме?
Ычкынмаган һәм шашмаган дисезме?
Инде хәзер кабатланмас дисезме?
Мәхәббәттә кабат янмас дисезме?
Ялгышасыз...

Тарта зәңгәр ераклыклар,
Мин очамын, син карап кил,
Нигә безгә очмаска соң...
Оча хәтта ярканатлар.
    Тәндә җаным бар чагында,
    Иреннәрем гел кабатлар:
    Күтәрелик, очыйк әле.
    Бездә дә бар пар канатлар.

Кушымта.

Иярсеннәр дуслар, ятлар,
Таң калсыннар бар канатлар,
Өметсезләр канатында
Яралсыннар пар канатлар.
    Тәндә җаным бар чагында,
    Иреннәрем гел кабатлар:
    Күтәрелик, очыйк әле,
    Бездә дә бар пар канатлар.

Кушымта.

*1995*

* Р.Ханнанов музыкасы.



*Без тиешбез һичшиксез*
*Тиз баерга:*
*Иң кимендә айга бер*
*Елмаерга!*

## *Туган көндә туган шигырь*

«Әле дә тугансың» дип мактауларга
Чынлап ышанасың бугай син.
Адәм мыжгып торган бу дөньяга
Артык булып юкка тугансың.
Әгәр мин тумасам, яслеләрдә
Артып калыр иде бер урын.
Өч борынга ярты салган чакта,
Төшеп калыр иде бер борын.
Әгәр мин тумасам, төймәләре
Өзелмичә калыр иделәр,
Автобуста эшкә барган чакта,
Иркен сулыш алыр иделәр.
Җитмәгәнме берәү генә туса,
Шигырь сөйгән безнең нәселдән:
Әле дә Юзи тумый калган диеп,
Сөенерләр иде нәшерләр.
Әйтмәс иде кемдер: «Ник кирәк ул?
Бик тә җиткән Тукай, Такташлар»...
Татармы ул әллә башкортмы, дип,
Бәхәсләшмәс иде якташлар.
Тәнкыйтьчеләр: «Җырны шулай яз!»— дип,
Утырмаслар иде өйрәтеп.
Чиновниклар интекмәсләр иде
Һәр юлымнан налог түләтеп.
Мактау, котлау, некрологлар язып
Газапланмас иде иптәшләр,
«Бик вакытлы ычкынды» дип сөенеп,
Табутымны алып китмәсләр...
иде... иде... бик күп иделәр...
«Иде»ләргә бирешмәскә теләп,
Мин... туарга булдым, иптәшләр!
Яшим әле озын гомерлеләр
Арасында кордаш, үз булып,
Шактый бөкрәюгә карамастан,
Уклау йоткан кебек төз булып!
Яшәү дәрте арта, күңелеңне
«Мин яшь әле, яшь!» дип алдасаң.
Күптән сиксәнгә дә, туксанга да
Җитә идем... бераз салмасам.

Йөз яшемә алдан дәшеп куям
Бар дусларны, бар танышларны.
Мин күп яшәп интектерәм әле
Литфондларны, райсобесларны.
Яңа Бистәдә дә урын беткән,
Ә көткәннәр гафу итсеннәр,
Тагын пенсиягә чыгарсыннар,
Автобуста бушлай йөртсеннәр.
Яшим әле Әҗәл микроблары
Өмет өзеп, аяк сузганчы,
Йөрәк тибешләрен көйгә салып,
Тагын өч-дүрт гармун тузганчы!
Һәр ел саен сезнең исәнлеккә
Шәраб күтәрермен һаман мин.
Туган көндә туган шигыремне
«Алла бирсә!..» диеп тәмамлыйм.

*3 гыйнвар, 1998*

## Кар кешесе кыйссасы

Хәбәр сөйли Казанның бар кешесе:
Аккош күлендә йөргән Кар кешесе!
Шау-гөр килде Париж, Малмыж, Мамадыш:
Фән өчен бу — коточкыч зур казаныш!
Галим затлар: «Без аны тотыйк!»— диләр,
Наданнары: «Китсен, куркытыйк!»— диләр.
«Сабыр итик, ашыкмаек алай ук,
Язучылар берлегенә алаек!»
«Иң әүвәле Шаһинур барып кайтсын,
Чын мәгънәсендә олы рәхмәт әйтсен!»
Берәү әйтә: «Булсын ул академик!»
«Акчасы булмаса, пока бирмик!»
«Керәшендер, мишәрдер йә типтәрдер,
Юк, мин татар түгелмен дип киткәндер».
«Гөргеричә бер татарга өйләнсен!»
«Фамилиясен Гомәр Саттар өйрәнсен!»
«Өйләнүләр бер читтә калып торсын,
Миңнекәй башта башын алыштырсын!»
«Маликова шәфкате бара торсын,
Ярты кило карабодай тапшырсын!»
«Миргазиян хыялына ашкандыр,
Премия бирерләр дип качкандыр».
«Җибәрик без тикшерүнең иң зурын:
Мәгъсүм иптәш Насибуллин надзорын!»
«Ой, кызганыч, кышны ул ничек чыдар?»
«Бәлки, ул ышпион булып чыгар?»
Барчасы куркып һәм тынып калган.
Сүзне Заһид Мәхмүди алган:
«Казан сөйли! Мәхмүдине тыңлагыз!
Бер дә алай аптырашып тормагыз!
Барамын мин! Әйтәмен сезгә өзеп:
Бу — хыялый бәян өчен — шәп сюжет!
Бик тиз хәбәр дә килмәс үземнән,
Мин китәмен Кар кешесе эзеннән!
Мин барамын, әмма ләкин эштән соң,
Чөнки татарның акылы төштән соң.
Мөгаен, ул Кар кешесе — татардыр,
«Йомры баш»ка азык булып ятадыр...»
    Китте Заһид адымын кызулатып,
Бисмиллалы мәхмүдизмнар әйтеп.

Бара торгач, төште бугай эзенә,
Ап-ак шәүлә чалынды бер күзенә.
Бер карасаң — эзләре таныш кебек,
Бер карасаң — ул бераз салмыш кебек,
Бер карасаң — ул эзләр эре кебек,
Бер карасаң — олы бер бүре кебек.
Заһид куа, үзе нык тирләп куя,
Тимәсен дип, үзе дә шүрләп куя.
Кар кешесе!.. Хәлдән таеп егылган.
Тартып алды Заһид ак мыегыннан.
«Тукта, тукта, мин сине бик беләм ич:
Кар кешесе түгелсең... син — Мөдәррис!
Кайт, Әгъләмов, кире кайт Казаныңа!»
«Юк, кайтмыйм мин Тукайсыз базарыңа!»
«Базарда симечкә мае «Өлфәт» бар,
Ә «Чаян»да якын дусың Зөлфәт бар...»
«Юк, кайтмыйм эзләп килсә дә Фирая.
Газиз халкым, юл аласың син кая?
Югаласың әкрен-әкрен... шик тә юк.
Кибетеңдә мөселманча сөт тә юк.
Бик арзанга шәрабы, башкасы да юк,
Дуңгыз ите алырга акчасы да юк.
Хөкүмәттә безгә бер карар да юк,
Бер кәпәч алырлык гонорар да юк.
Кайтмыйм, анда көчләп фатир бирәләр,
Паспорт сорап этләр-бетләр өрәләр.
Ял итим дип килсәң берлек йортына,
Ркаиллар уразага тотына.
Гаффар банкетлардан банкетларга йөри,
Чакырмыйлар дип, мине дә өстери.
Рәсүл дуслар «коньяк эч!» дип кыстайлар,
Чират тора Кайсын, Давид, Мостайлар.
Бардым бер көн мин Бауман тарафына,
Очрадым йөзләгән кыз карашына.
Максатымдыр — хисләнеп шигырьләнү,
Түгел мәхәббәт белән шөгыльләнү.
Яннан гына Нәфисәләр узалар
Дигән идем... фахишәләр узалар.
Кирәкләрен бирер идем — сәмән юк,
Тукай йөргән «тәти йортлар» һаман юк.
Тән туңса да, мич башында ятмамын,
Шәймиев үзе килсә дә кайтмамын.
Урманымның барсам да кай ягына,

Таянамын Туфан карт таягына.
Кесәсендә мең сум акча калдырган.
Мөгаен, ул, мәрхүм, үзе ач торган.
Монда миңа чыпчык, песнәк — дус-туган,
Өстәлемдә — Дәүли эчкән тустаган.
Юк, ялынма, Заһиди, син китеп бар,
Аягымда — Сибгат биргән итекләр.
Кутуй әйтәлми иде: «Мөдәррис» дип,
Дәшә иде абзагызга «мудрец» дип.
Әдәбият эверелде базарга,
Исән булса, үләр иде Назар да.
Белми Казан хәзер кече-олыны.
Монда гына тоям хәзер җылыны.
Сәлам әйтмә анда йомры башларга.
Уйламыйм мин урманымны ташларга.
Монда килсен «Мирас», «Казан утлары»,
Өч йөз берлек белән литфондлары,
«Сарман» кафесы, язучы йортлары
Вә шампанның иң акчасыз сортлары...»

Кар кешесенә торды да карап.
Әйтте Заһид: «Шәп сюжет булды харап».
Ишетсен Казанның юк-бар кешесе:
Монда калам! Мин дә бит КАР КЕШЕСЕ!

Бу кыйссаның авторына Мөдәррис
Үпкәләмәс, үз хәлемне беләм ич.
Аякларым Мәхмүдинең эзендә.
Мин дә китәм. КАР КЕШЕСЕ ҮЗЕМ ДӘ...

*2001*

Искәрмә: Кыйссаның каһарманнары мин ихтирам иткән, юмор хисе булган шәхесләр — шагыйрьләр һәм язучылар күздә тотыла: Шаһинур Мостафин, Гәрәй Рәхим, Гомәр Саттар, Рәфыйк Миңнекәев, Мәдинә Маликова, Миргазиян Юныс, Мәгъсүм Насибуллин, Заһид Мәхмүди, Мөдәррис Әгъләм, Тукай, Зөлфәт, Фирая, Ркаил Зәйдулла, Әхәт Гаффар, Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Давид Көгелтинов, Мостай Кәрим, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Рөстәм Кутуй, Назар Нәҗми, Илдар Юзеев...

# *Күл кешесе кыйссасы*

**Кыйсса каһарманнары:**

Заһид Мәхмүди, Мөдәррис Әгъләм, Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Сәгыйт Рәмиев, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай, Владимир Ульянов-Ленин, Гаяз Исхакый, Фоат Галимуллин, Марсель Гали, Салих Сәйдәшев, Айдар Хәлим, Нобель, Гамил Афзал, Уитмен, Фәндәс Сафиуллин, Туфан Миңнуллин, Сәйфи Кудаш, Салават Фәтхетдинов, Рөстәм Миңнеханов, Рафаил Мостафин, Георгий Ибушев, Иван Грозный, Сөембикә, Мәһди, Ибн-Фадлан, Сергей Шойгу, Илдар Юзи һ.б...

Әйтте Заһид Аккош күленә багып,
Әгъләмовның өйсез ишеген ябып:
«Ятма монда и булма кире беткән.
Аккош күленең күптән сере беткән.
Туфаннан соң Аккош күле саекты.
Монда күчкәч, Фәйзуллин да ябыкты.
Ул — Рәмиев, син — Гафуриның ише,
Юк бары тик алтыны вә көмеше».
«Ну таптың да соң чагыштырыр кеше...
Көн-төн салдык... йә, бу йорт кемнең эше?»
«Пәлтәң дә юк музееңа куярлык,
Дустың Мостай килсә, сатып сыйларлык.
Кәчтүмең юк, бар тик тишек кесәсе.
Ул кесәдән җилләр генә исәсе.
Баетам мин сине, Әгъләм, баетам.
Булыр шәхси шоферың һәм «Тайота»ң.
Кайчагында Равилне утыртырсың,
«Таптыйм!» дип ГАИны куркытырсың.
Без тиешбез, һичшиксез, тиз баерга,
Иң кимендә айга бер елмаерга!
Ялгыштыгыз Ленин юлыннан барып,
Егылдыгыз барып җитмичә арып.
Җилфердәтеп мәхмүдизм байрагын,
Киттек эзләп тормышның баерагын!
Күп яттыгыз бөлеп тормыш төбендә,
Хәзинәбез ята Кабан күлендә!
Аны дошманнан яшергән хан бабам,
Җитте вакыт: төпкә төшәм дә табам!

Милләтнең шул байлыгын байрак итеп,
Һичшиксез алырбыз суверинетет!
(Уйлап куйды Әгъләмов ярсып китеп:
Кайтармаса бабаң сүгеп эт итеп.)
Мөстәкыйльлек бары тик минем юлдан!
(«Исхакый әйткәндәй: ике йөз елдан...)
«Литфондыбыз торалмый аягында?»
«Күп уйлангач, хәл иттем ул ягын да.
Путевкасын алып бирәм, тураер,
Ялталарда ял иткәч, матураер.
Хәзинәне күл төбеннән алырмын,
Хакимнәргә тагын сарай салырмын».
«Ник аларга, ник ятимнәргә түгел?
Шигырьдәге хәкимнәргә түгел?»
«И наданым, шуны да белмисеңме?»
«Укудан юкка куганнар дисеңме?»
«Ач авызың бераз җитди уйланып,
Куылган бит шулай ук В.Ульянов.
Берлектән куалсалар беркөнне,
Университетка бирербез исемеңне!
Ә хакимнәр, боегып, болай итәр:
Сарайларын сезләргә бүләк итәр.
Берсе иҗат йорты итеп тотылыр,
Галимуллин өй эзләүдән котылыр.
Берсе булыр йөзү өчен бассейн,
Фәйзуллинга тапшырырбыз бар суын.
Марсель Гали үзен бәхетле тояр:
«Ниһаять, биллиардер булдым!» дип куяр.
Юкка чыгып торганumманы түләп,
Сәйдәшкә һәйкәл салырмын бик теләп.
Әгәренки исән булса СССР,
Чуенын да бирер иде «Компрессор».
Башта шәпләп тамагың туйдырырмын,
Сиңа да, Әгъләм, һәйкәл куйдырырмын, —
Бик ябыгып башың-муеның калса,
Сәйдәшевтән артып чуеным калса.
Йомры башың һич ялтырамаслык булыр,
Макмырда кулың калтырамаслык булыр.
Уйлап куйдым «Шагыйрь — Әгъләм» позасын:
«Бурычка...» дип, Туфанга кул сузасың...»
«Зур дөньяга ник чыгалмыйм мин — татар?»
«Талант та зур, маңгай да киң... караш — тар.

Тик бер кеше белә татарның хәлен.
ООНга куймый калмас Айдар Хәлим.
Бүләк даулап Нобельгә җитми булмас,
Биш-алты мең долларны төртми булмас».
«Нәрсә карап яталардыр Нобельдә?»
Алалмады хәтта Афзал Гамил дә».
«Тырышмый шул Уитменга охшарга».
«Укымаган әдәби курсларда».
«Төзеп бирәм Милли университет!
Карап торсын Фәндәс тә исе китеп».
«Булмас микән Дәү Советны өйрәтеп,
Саф татарча үзебезчә сөйләтеп?»
«Бераз гына куркалардыр дип уйлыйм:
Урысчага күчәр дип Т.Миңнуллин.
«Ничек итеп ирешергә томнарга?»
«Кирәк бары Мәхмүдине тыңларга.
Нигә әле сайланганны күтәргә?
Һәр язучыны депутат итәргә!»
«Соңгы елда хәвефкә төштем әле:
Әдәбиятыбызның мөшкел хәле.
Исемсезләр лауреат булу өчен
Багышлыйдыр бар талантын һәм көчен».
«Мәсьәлә идарәдә каралганда,
Лауреат итик Берлеккә алганда.
Һәрбер әгъза булыр шулчак канәгать.
Тынычланыр әдип дигән җәмәгать».
«И Мөдәррис, төп максатка йә, киттек!
Баеганчы күп нәрсәне хәл иттек».
«И Мәхмүди, йомры башың шәп уйлый.
Ничек барыйк, кесәдә җилләр уйный.
Мостай дустан сорар идек, Уфам юк.
Бессрочный алыр идем — Туфан юк.
Үземдә кесә тулы хыял гына...
«Шул кесә шунда илтеп куяр менә.
Ияр арттан, Мәхмүдидән калышма,
Без барабыз супер автоярышка!
Син — Салават, мин — премьер Миңнехан.
Тукталышта машинага шофер хан!»
«Автоярыш Кабан күлендә икән!»
«Мин илтәм!» «Үзем илтәм!» «Бушлай илтәм!»
Җырлый-җырлый болар барды-барды да
Төшеп калды Кабан күле ярында.

«Күл буенда берәү йөри...?»
«Мостафин!»
«И Рафаил, буш хыялга оста син!
Күпме еллар чуаласың Кабанда,
Хәзинәне табалмыйсың һаман да.
Син, тәнкыйтьче абыебыз, болай ит:
Йолдыз ясап, Мөдәррисне Тукай ит!
Ким булмасын коньяктагы йолдыздан.
Ераккарак китеп кара бу боздан.
Ниятеңне тормышка ашырырмын,
Сәламеңне тегендә тапшырырмын!..»
«Ярдәм сорыйк, читтә калмас бу эштән,
Татарларга кайчак читләр булышкан.
Ярдәм сорыйк төрекләрдән и Буштан,
Керәшеннәр президенты Ибуштан».
«Мескәнлеккә барма, Әгъләм, и фәкыйрь,
Дәүләт түгел, без үзебез мөстәкыйль!
Сораудан да, алудан да файда юк,
Бу дөньяда бездән башка бай да юк!
Юк, түгелмен заманның Дон Кихоты.
Мин милләтнең хыялга бай Заһиты,
Байлыгының юкка чыгу шаһиты.
Эзлим: кайда бәхете, пайтәхете.
Мөдәррис тә түгел Санчо Пансасы,
Татарның ул күзендәге тамчысы.
Сорасалар әгәр бездән: «Сез кемнәр?»
«Без — байлыктан, ярлылыктан өстеннәр!»

Кабан күле могҗиза белән тулган.
Фәйзуллин да бөек уйларга чумган.
«Төп максатым — ераклыкка йөзүдер,
Боз астыннан чыкмый озак түзүдер».
Бүләк булсын олуг бәйрәм көненә —
Җөмһүриятнең мөстәкыйльлегенә!»
«Кемгә кирәк бу файдасыз буш шөгыль?
Лутчы яз син акчалы сай биш шигырь!
Тот, Әгъләмов, ошбу аркан очыннан,
Безнең баю башланадыр шушыннан!»
«Черек түгелме арканың, нык тоттым!»
«Арканзас штатыннан алдырттым.
Мировой бау, ишелмәгән ул комнан.
Рөхсәт сорап торасы юк обкомнан.

Мөрәҗәгать итәм туган халкыма,
Казанымның алдына вә артына.
Казан сөйли! Мәхмүдине тыңлагыз!
Бөгелсәгез бөгелегез, сынмагыз!
Хыялымны аркан итеп ишәмен,
Кыскасы, Кабан күленә төшәмен!
Зур тарихи миссиягә фән җигә:
Күл төбендә көтә мине хәзинә.
Явыз Иван калабызны яндырган,
Ханнар күлгә байлык салып калдырган.
Бирмәгән мөмкинлек хыял сайлыгы,
Яшерелгән анда милләт саулыгы.
Түксәләр дә күпме доллар, күпме көч,
Кабан күле күрсәткән гел бер кукиш!
Америкадан бер хәбәр бар безләргә:
Килмәкчеләр хәзинәне эзләргә.
Сизми калыр алар минем бу эшне,
Астан үзем күрсәтермен кукишны!
Мәхмүдине озатырга килегез,
Милләт гомерен озайтырга килегез!
(Хәтерләтеп сабантуйны-җыенны,
Күз йомганчы барча гавәм җыелды.)
Милләт өчен фида булсын бу җаным,
Сәфәремне датага багышладым:
Шәһре Казанның бер мең еллыгына,
Һәм дә дүрт йөз илле ел коллыгына.
Озатыгыз Сөембикә киткән кебек,
Һәм көтегез Мәһдине көткән кебек,
Ибне-Фадлан юл алгандай Болгарга,
Онытмагыз кулыгызны болгарга.
Кайталмасам, елап йөрмәгез тагын,
Коммунист дип саный күрмәгез тагын...
Хәзинәне кайтарырмын халыкка.
Һәйкәл тиеш — миңа түгел, Алыпка!
Йә, хәерле юл диеп дога кылдык.
Яшә, мәхмүдизм һәм мөстәкыйльлек!
Шул сүзләрне тантаналы әйтүгә,
Төште дә китте Мәхмүди бәкегә.
Күренеп калды бары бер йомры башы —
Акыл хезмәтендә тугры юлдашы.
Китте түбән ул озын аркан буйлап,
Ярты литр тир акты арка буйлап.

Калды Мөдәррис аркан очын тотып,
Ике йөз грамм бозлы су йотып.
Алабыз дип интервью Мөдәрристән,
Йөз журналист килде «Идел-Пресс»тан.
«Ошбу факт чынмы әллә миражмы?»
«Күтәрмәсме бераз беткән тиражны?»
«З.Мәхмүди кемне күмәр алтынга?»
«Казан ханы күчмәгәнме латинга?»
«Торсалар татарлар бик юаш булып,
Калмасלармы урыс йә чуаш булып?»
«Милләте бар микән паспортларында?»
«Тел хөкем итмиләрме судларында?»
«Ханнар белән шартнамә төзелмәсме?»
«Арканзасның арканы өзелмәсме?»

Килеп җитте хәтта телевидение:
Күрсәтергә вакыт җитте бит инде!
Очкын-утлар чәчри табан астыннан.
Бер хәбәр юк һаман Кабан астыннан.
«Мөселманнар, күл төбенә кем барыр?»
«Мәскәү үзе, бәлки, Шойгу коткарыр!»
Байлык төяргә меңләп «КамАЗ» килде.
Бер водолаз, бер противогаз килде.
Әйтте Әгъләм, шатланып: «Байлык чиртте!
Тын кал, гавәм, тарихи мизгел җитте!
Заһидыбыз күлнең төбендә кунган.
Хәбәр итте мобильный телефоннан!
Кушты Заһид, вакытым бар, но тыгыз:
Тарт арканны! Хәзинәне тартыгыз!»

Тотындылар меңләп адәм арканга,
Боз эреде тирләп-пешеп тартканга...
Бар да тарта: коллар, фәкыйрьләр тарта,
Әби-бабай, толлар, ятимнәр тарта.
Көчлеләр карап торды — папирос тартты.
Бер мең яшь татар, бер карт урыс тартты.
Хәзинәнең юлын бераз кыскартты,
Иң ахырдан ике йөз «КамАЗ» тартты.
Тарта торгач, һәммәсе хәлдән тайды,
Айдар Хәлим, хәтта «КамАЗ» янтайды.
Никтер һаман да өзелми — аркан нык.
Тарта торгач... килеп чыкты... зур сандык!

«Хәзинә!»— дип кычкырдылар кинәттән.
Байлыкның да иң олысы эләккән.
Кайсылары менәргә баскыч эзли,
Икенчесе ачарга ачкыч эзли.
Тотты Әгъләм арканлы микрофонны,
Сүз катты байкап халыкны — фонны:
«Каләм әһле, сезгә бу — сенсация!
Ясыйм боз өстендә презентация!
Хәзер мин мировой ачыш ясыйм.
Яшеренгән гасырлар серен ачыйм!»
Көтә халык бәхетен өмет итеп,
Боз өстендә банкет буласын көтеп.
Ачты Әгъләм сандыгының капкачын,
Күрде бар да Кабан-күлнең ак ташын.
Тик бер генә җөмлә язылган ташта:
«Россия белән тәңгәлләштер башта!»

Ауды халык... өмет бавы өзелгән.
Мин дә китәм Мәхмүдинең эзеннән...

*2002*

## Минем хәлне нигә аңламыйлар?

Карьерамда туктап калдым әле,
Барсы да шул кыргый базардан...
Сәркәтип тә булдым, хезмәткәр дә,
Узалмадым урынбасардан.
Юкка гына миннән шүрләделәр,
Берсенең дә урынын басмадым.
Зур урынга сайланасым килеп,
Көн-төн хыяллана башладым.
Әйтәм моны тыйнак кыенсынып.
Дәртле хыялыма буйсынып,
Сайлау җиткән саен, нишләтәсең,
Нәфес-иблис куя ымсынып.
Минем дә бик килә мохтаҗларга
Хисапсыз күп вәгъдә чәчәсем,
Янда гына йөргән түрәләргә
«Нихәл!» диеп кенә дәшәсем.
Хәлләремне никтер аңламыйлар:
Килә җайлы тормыш корасым,
Затлы вагоннарда бушлай йөреп,
Престижный йортта торасым.
Бик тә килә Төркиягә барып,
Рәхәт диңгезенә чумасым,
Түрәләрне башта тетеп салып,
Фатир алгач кына — тынасым.
Сессиядә рәхәт йомыла торган
Матур күзләрем дә бар минем,
Әйтелмичә калган һәм әйтелмәс
Усал сүзләрем дә бар минем.
Югыйсә бит дәрәҗәм дә шактый:
Шигырь бүлегендә — мөдирмен!
Бик күпләргә мәдхияләр язып,
Шигъри тостлар әйткән бер ирмен!
Нигә мине күрми узалар соң?
Уйлап ятам эштән кайткач та...
Рифма да бар, шигъри деталь дә бар...
Товар юк шул миндә, запчасть та...
Юк, депутат булмыйм, карьерамны
Күтәрермен шигырь эшендә.
Хатын хаклы: «Эшли алмаганны...
Кая халык... үзең өчен дә...»

Әйтәм моны тыйнак кыенсынып,
Дәртле хыялыма буйсынып:
Сайлау җиткән саен, нишләтәсең,
Нәфес-иблис куя ымсынып.
Замандашлар шагыйрьлеккә мине
Күрсәтсәләр ярар иде, дип,
Озын төннәр буе йоклый алмыйм,
Шигърияте үзе — парламент!
Минем дәүләтемдә — бар да шагыйрь,
Тукай — патша, Такташ — премьер.
Сайласагыз, Тукай дәүләтенең
Бер илчесе булыр идем мин!
Кандидат та, сайлаучы да булып,
Иң беренче үзем килермен,
Туры Тукай кебек төз булсын дип,
Мин үземә тавыш бирермен!

*1996*

## Безнекеләр!

Авылдаш ич безнең —
Саратов мулласы!
Ә берсе — Төмәндә
Юл төзү остасы!
Ә берсе — Уралда
Газ кертә өйләргә.
Ә берсе — Казанда
Җырлый шәп көйләргә!
Мәскәүнең бер бае —
Безнеке! Сынатмый!
Ә берсе — Марида!
Урманын ул саклый.
Энергетик безнең
Уфаның үзендә!
Ә берсе — су таба
Африка чүлендә!
О! Нинди горурлык!
Дөньяга чыгалдык!
...Тик көч юк мактанып,
Күкрәккә сугарлык:
Авылда — мулла юк,
Җүнле бер юл да юк.
Клубы — искергән,
Бер йорт юк газ кергән.
Агач юк кисәрлек,
Су да юк эчәрлек.
Асылыныйм дисәң —
Юк агач асылы,
Күл буена килсәң,
Юк батарлык суы.
Кибеттә — мәй генә,
Сатылмый чәй генә.
Ут сүнсә — шәм дә юк.
Сөйләргә — хәл дә юк...

*2001*

## Котыпка киткән егетләргә хат

Сәлам сезгә, татар егетләре,
Тау-тау бозларыгыз санынча,
Сезне көтеп зар-интизар булган
Нечкә билләрегез санынча.
Кызлар һаман туфля киеп йөри,
Кирәк түгел тун да, толып та.
Морж, моржихалар арасында
Хәлләр ничек анда — котыпта?
Яшисезме ун мең чакрымнарда,
Туңган Россияне җылытып,
Мич ягарга диеп, урман кискән
Туган җирегезне онытып?
Кара алтын өсләрендә яткан,
Утын яккан өйләр газ көтә.
Сездән башка бигрәк салкын диеп,
Күпме кызларыбыз наз көтә.
Өйгә тагын җылы бирмәделәр,
Толып та юк өскә кияргә.
Күршедә туй — бәйрәм. Рушания
Валентинга чыккан кияүгә.
«Туйга керергәме, юкмы?» диеп
Уйлап тора Юзи картыгыз.
Их, егетләр... тизрәк кайтыгыз!
Бозлар арасында ятмагыз сез,
Кызлар арасында ятыгыз!

*1999*

# Минем көнем

«Эчә белмәсәң — эчмә!»
Халык дөрес әйткән.
Ә мин — эчә беләм.
Тәҗрибәле күптән.
Эчәсем дә килми,
Бер дә эчмәс идем:
Балыкчылар көне —
Ул бит минем көнем.
Башка инде капмам,
Яшьлек узып бара.
Хатын бала тапкан —
Эчми түзеп кара!
Һәркөн дата, бәйрәм —
Эчүчеләр көне.
...Бүген эштән очтым....
Очучылар көне.

*1996*

## Тел остасы

Тел бистәләре күплектән
Штатны кыскарттылар.
«Телең бигрәк озын!» диеп,
Эштән алып аттылар.
Усал тәнкыйтьтән баш тартмам,
Штатсыз калсам да мин,
Телне барыбер кыскартмам,
Ыштансыз калсам да мин.

*1996*

## *Шайтанны сагыну*

«Тегеләй ит, болай ит!» дип,
Шайтаным котыртса да,
Кайвакытта төп башына
Шактый нык утыртса да,
«Азмыштан узмыш юк» диеп,
Аздырса да, кызмадым.
Кызларга кул сузганда да,
Чит ярларга сузмадым.
Иңбашта ике фәрештә
Сакларга тырыштылар.
Мәхәббәттә узынганда,
Эт итеп орыштылар.
Хәзер инде, өлкәнәйгәч,
Фәрештәгә табынам.
Тик барыбер яшьлегемнең
Шайтаннарын сагынам...

*2002*

## Сөйгән ярлар, гаеп итмәгез...

«Сөйгән ярың, Илдар, бармы?» — диеп,
Син сорыйсың, дускай, сорама...
Сөйгән ярым минем ике хәзер:
Берсе — Лира, берсе — Драма.
Әнә шулай гомер итүемнән
Хәтта көнләүчеләр бар, беләм.
Аңлар идегез сез хәлләремне,
Яшәсәгез ике яр белән.
Драманың бик ачуы килә,
(Белә үзе: сөям мин аны,)
Трагедия ясап, ташлап китә,
Җан дошманы итә Лираны.
Лира белән миңа шундый рәхәт:
Иркәләнәм, аңа табынам.
Тагын нидер җитми башлый җанга:
Тоям: Драманы сагынам.
Эзләп китәм, табам, гафу сорыйм,
Чамалыйм да урын-вакытны.
Лира тота безне, ызгыш китә
Өч кешеле, ике актлы!
Монысы гына әле җитмәгәнме,
(Мөмкинлекне минем киңәйтте,)
Шактый гына нәфис, тәҗрибәле
Проза ханым: «Көтәм...» — дип әйтте.
Барыргамы, юкмы?
Йөрәк әйтә:
«Бәлки, сөяр, бераз якын бар...»
Ни диярләр Лирам һәм Драмам,
Шулар өстенә бит хатын бар!
Барам, осталыкны сынап карыйм.
Лирам, Драмам, гаеп итмәгез,
Проза әгәр сөеп кабул итсә,
Бик тиз кайтмам, өзелеп көтмәгез!
Көнләшеп тә куям, дускай, синдәй
Тик бер ярны сөя алмадым...
Юк, үкенмим, хыянәтче диеп,
Куып чыгармады ярларым.
Җырлы гомерем ничек төгәлләнер?
Җансыз-ярсыз гына үтмәсен.
Драмалар булмас, дип әйтәлмим,
Көлке булып кына бетмәсен...

*1987*

## *Егетләрнең кызларга киңәше*

Кызлар, язны каршылыйсыз
Елмаеп һәм көлеп сез.
Кар астыннан калкып чыккан
Умырзая кебек сез.
Тәмам акылдан шаштыра
Сихерле күзләрегез,
Әйтелмәгән сүзләрегез
Һәм... шәрә тезләрегез.
Һәр егетне әсир итә
Ап-ак муеннарыгыз,
Бер чакрымнан тәэсир итә
Кайнар куеннарыгыз.
Кызлар, сез шундый сөйкемле,
Чибәр, мөлаем, нәфис.
Кайчак сезне шәрә килеш
Күрергә тели нәфес.
Чишенергә ашыкмагыз,
Тукта, туктап калыгыз,
Егетләрнең киңәшен дә
Бераз искә алыгыз.
Бөтенләй шәрә калсагыз:
«Бу түгел гөнаһ!»— диеп.
Бар егетләр катып калып,
Әйтерләр бер: «Ах!»— диеп.
Озатсын сезне сокланып,
Бар карашлар бер булып,
Ә күлмәк... күлмәк аслары
Калсын бөек сер булып.
Биш кат күлмәк кисәгез дә,
Сез мөлаем, сез матур.
Бер генә тапкыр әйтмәбез,
«Ах!» диярбез мең тапкыр!
Кызлар, сезне күрсәк әгәр,
Уйлый ярты баш кына.
Үтенәбез, чишенегез
Бары яртылаш кына!

*1998*

## Кияүгә чыгучы кызларга киңәш

Чыкмагыз, кызлар, кияүгә,
Чыкмагыз шагыйрьләргә,
Чыгыгыз сез эшкә оста —
Маһиргә — шоферларга.
«Кадак та кага белми»,— дип
Үкенмәгез соңыннан,
«Мине бәхетсез итте»,— дип,—
Үкермәгез соңыннан.
Әгәр шагыйрь гашыйк булса,
Карагыз кырын гына,
Сөймәгез сез шагыйрьләрне,
Сөегез җырын гына.
Әгәр шагыйрь шофер булса?
Кадак та кага белсә,
Изү чишеп, җырлый-җырлый,
Печән дә чаба белсә?
Әгәр шофер шагыйрь булса?
Шигырь дә яза белсә?
Андыйлар да сирәк кенә
Булгалый, Алла бирсә.
Чыгыгыз, кызлар, күңлегез,
Күзегез төбәлгәнгә,
Чыгыгыз, кызлар, кияүгә:
Үзегез теләгәнгә.
Бернидән дә курыкмагыз,
Мәхәббәт җанда йөрсә,
Кияүләрнең «во!» дигәнен
Табарсыз, Алла бирсә!
Чыгыгыз, кызлар, кияүгә...
Шофер булса да ярый...
Минем кебек, яшь чактагы
Шагыйрь булса да ярый...
Тынычлык, байлык кирәксә,
Әйтәм мин чынын гына:
Сөймәгез сез шагыйрьләрне,
Сөегез җырын гына!..

*1994*

## Көнләшәм...

«Көнләшмим...» дип әйтер идем,
Үз холкымны белмәсәм.
Бик әйбәт шигырь язсалар,
Үлә язып көнләшәм.
Дусларымның уңышына
Мин тыныч карый алмыйм.
Шәкертләремнән көнләшәм,
Әмма... тик... кара янмыйм.
Төннәр буе уйлап ятам.
Йокыга талган шәһәр.
«Хурлап та булмый, зурлап та...
Үтерде мине, каһәр!..»
Таң атуга үз-үзенә
Хөкем чыгара күңел:
«Үзең булдыксыз булуга
Ул бит гаепле түгел!»
Тегене күрү белән үк,
Тәбрикләп кулын кысам.
«Төнлә йоклатмадың, брат,
Котлыйм. Сокланам. Ышан!»
Шул вакытта мин үземне
Бик көчле итеп тоям,
Җиңеләеп, илһамланып,
Бер шигырь язып куям.
Шулай көнләшеп яшәүне
Сездән яшереп йөрим.
Үземә һәм көндәшләргә
Газаплы җиңү телим!

*1994*

## Банкир белән Мөнкир

Хезмәт хакын сорап
Инде ничә тапкыр
Киләләр. Ишек төбендә —
Мөнкир белән Банкир!
Кем соң алыштырды?
Кая киткән Нәнкир?
Көчсез булып чыкты
Хәзер монда Банкир!

Чират төркем-төркем.
Үтә алмый беркем.
Кулларында — гөрзи!
Банкир белән Мөнкир.
Ришвәт төртеп карыйк —
Усал йөзләр балкыр...

Мыек та селкетми
Мөнкир белән Банкир!
Патша үзе килсен!
Бәлки, акча артыр...
Сезгә патша хәзер —
Мөнкир белән Банкир!

Үзебезнең акча!
Бир син безгә! Бир! Бир!
— Тот капчыгыңны! — ди
Банкир белән Мөнкир.

— Капчык тотар идек —
Мөмкинлекләр бик киң —
Капчыклык акча юк —
Бирми Банкир-Мөнкир!

Яңа байлар килә:
— Пажалста, бар, кер!
...Оҗмах ишегендә —
Мөнкир белән Банкир!

— Бу шигырьгә түләү
Тиештер бит, бар, кер!
Башка тондырдылар
Мөнкир белән Банкир...

*1999*

## *Куян елында бүре хәлләре...*

Юлбарысның комбинаты банкрот булган.
Тоткан да ул бүреләрне эштән куган.
Нишләргә соң бүреләргә? Эшләр харап.
Киткән болар карурманга таба карап.
Сөенгәннәр ут янына якын килгәч,
Казан аскан Кәҗә, Сарыкны күргәч.

«Әйтмәгез дә иң ахыргы сүзегезне,
Юк итәбез йә ботка, йә үзегезне!»
Кәҗә әйткән: «Сез берни дә оталмассыз!»
Сарык әйткән: «Безне барыбер йоталмассыз!»
Кәҗә әйткән: «Без бит вак та төяк кенә».
Сарык әйткән: «Тире белән сөяк кенә!»
Кәҗә әйткән: «Хәмер дә юк, водка да юк!»
Сарык әйткән: «Казанда — су, ботка да юк!
Беләсездер: календарьда — куян елы,
Казандагы трамвайда — куян тулы!

Бар куяннар трамвайга — эчкә кергән.
Ә бүреләр, тотарга дип, эшкә кергән.
Тотар идең — берсенең дә билеты юк.
Йотар идең — месkeннәрнең бер ите юк.
Риза булыр иде алар коллыкка да,
Кирәк түгел бу мәхлуклар циркка да.

Корсакларда сандугачлар-кошлар сайрый,
Соңгы чиктә болар мондый юлны сайлый:
Алларында ята ике тишек бүрек,
Шәфкатьлеләр акча салыр, бәлки, күреп.
Берсе бии, берсе — тальян гармун суза,
Тик барсы да яннарыннан күрми уза.
Трамвайлар туктап калган. Бу ни булган?
Ачлык игълан итүчеләр урам тулган.
Барсы шунда — ваграклар да, эреләр дә,
Юлбарыс та, куяннар да, бүреләр дә...
Шунда йөри Кәҗә-Сарык ишеләр дә...

Мондый хәлләр булмасын тик кешеләрдә...

*1998*

## *Их, бар иде...*

«Их, бар иде яшь чаклар!» дип,
Язмыйм мин мемуарлар,
Әгәр язсам мемуарлар,
Картайган дип уйларлар.
Киләчәктә Алла бирсә
Гомерләр, исәнлекләр,
«Их, бар иде карт чаклар!» дип
Язармын истәлекләр....

*2001*

## Хәмрулин маҗаралары

Беркем әйтәлмәс мине «милләтче» диеп,
Йөрмәдем беркайчан да чеплашка киеп.
Барган идем Казанның Фин кибетенә,
Очрадым татарның бер этенә.
Алдым да салдым урысның аракысын,
Типтем дә очырдым теге сабакысын.
Киттем янә дә болгарски кызыл алып,
Фин белән сугышканнар өчен кызарып.
Тагын да өстәдем хохолның горилкасын,
Барып үпкәнмен зоопарк горилласын.
Эспиранто дигән урамда йөргәнмен,
Шул телдә сөйләшеп, метрога кергәнмен.
«Хальт!» кычкырып немец марҗасын кочканмын,
«Уважаешь?!» диеп, эфиопны кысканмын.
Авыз иткәнмен чуаш анкаласыннан,
Чыгып киткәнмен татар башкаласыннан.
Эчкәннәрем бар да интерлашканнар,
Вак милләтчеләр миннән куркып качканнар.
Төрек кибетендә дә коньяк алганмын,
Татарның «К»сы йомшак дип зарланганмын.
Җиткәнмен американски бер штатка,
Ну, малай, салганмын мировой масштабта!
Кайда соң мин? Стамбулдамы? Лондондамы?
Тукта, мин андамы, әллә мин мондамы?
Ни эчәм мин? «Чистай таңнары»мы? «Джин»мы?
Алдымда кемнәр йөри: шайтанмы, җенме?
Төтен, сасы ис... Юк ич беркем, чортым да.
Ятам дисәм, первый сорт кунак йортында...
Үз Казанымда йөргәнмен адашып.
Самасыр чүплегендә ятам саташып...

*1998*

## Жалюзи

Тәрәзәмдә юк жалюзи.
Уйлыйсыздыр: «Жәл Юзи...»
Исеме дә, җисеме дә
Чит илдән килгән бар да.
Ник кирәк миңа жалюзи,
Татарда пәрдә барда.

# Базарда

— Хәлең ничек?
— Түзәрлек.
Хәлем бар җеп өзәрлек.
— Кесә ничек?
— Кесә тишек.
Сизмим бер авырлык та.
— Ник текмисең?
— Акча юк шул
Энә-җеп алырлык та...

*2001*

## Өч иптәш

Гәрәй, Гөргери һәм Рәхим —
Өч иптәш чыккан юлга.
Язу күреп туктаганнар
Карап уңга вә сулга:
«Уңга китсәң — юлыгырсың
Аюның явызына,
Сулга китсәң — эләгерсең
Нәкъ бүре авызына».
Гәрәй җырлап та җибәргән:
«Минем бабам — аючы!»
Гөргери бик тиз кушылган:
«Аю сатып баючы!»
Аю, таныш җыр ишетеп,
Күңеле хуш булган, ди,
«Мин дә сезнең белән!» — диеп,
Бу җырга кушылган, ди.
Ә Рәхим:
«Минем үз җырым,
Минем үз бабам,— дигән,—
Мин бүреле якка китәм,
Үз юлым табам», — дигән.
«Минем бабам бүрече! — дип,—
Тиредән тун тегүче!» — дип,
Җыру җырлап барса да,
Тешләрен ыржайтып, бүре
Басып торган каршыда.
Рәхим, мескенкәй, бүленеп,
Киткән ялгызы гына
Һәм туп-туры барып кергән
Бүренең авызына.

*2002*

# *Татар кешесе*

*Гәрәй Рәхимгә*

Федотовкада туган,
Нәни чанада шуган,
Олы Казанга чумган
Татар кешесе.
Мәскәүне дә айкаган,
Уфаны да байкаган,
Казанында кайнаган
Татар кешесе.
Сакалын да үстергән,
Акылын да үстергән,
Болгар җилен истергән
Татар кешесе.
Керәшенчә өйләнгән,
Татарча да өйләнгән,
«Люблю» дип тә сөйләнгән
Татар кешесе.
Дәү советта сыналган,
Бик дәү генә чин алган,
Закон язып чиләнгән
Татар кешесе.
Беркем әйтми «акылсыз»,
Яши алмый законсыз,
Яши алмый хатынсыз
Татар кешесе.
Депутаттан да артык
Бара ул йөкләр тартып,
Һәркем әйтә яратып:
Татар кешесе!

*2002*

# *Ничек бүләек?*

«Бер алманы бишкә бүләек».

*Разил Вәлиев*

Алма пеште матур көрәеп,
Бу алманы кемгә бирәек?
Туган көнен котлап киләек,
Ниләр эшләгәнен беләек,
Бер алманы кемгә бирәек?

Бер алманы бишкә бүләек:
Шагыйрь Вәлиевкә бирәек.
Икенчесен кемгә бирәек?
Драматург Разил Вәлигә,
Халык депутаты Разилгә,
Китап миллиардеры Разилгә...
Бишенчесен кемгә бирәек?
Пенклубчы Разил Вәлигә!
Пенклубка без дә керәек,
Берлеккә дә саулык теләек,
Бер алманы бишкә бүләек,
Тик Берлекне бишкә бүлмәек,
Бер Берлекне бишкә бүлмәек!

*1997*

# Шагыйрь булу гына җитми...

«Көннәр ямьле булсын өчен,
Әни кирәк, әни кирәк...»

*Роберт Миңнуллин*

Әни генә җитми әле,
Җил-яңгырдан саклар өчен,
Әти кирәк, әти кирәк.
Әти генә җитми әле,
Ашлар тәмле булсын өчен,
Шигырь кирәк, шигырь кирәк,
Дөнья ямьле булсын өчен,
Роберт кебек шагыйрь кирәк!
Шагыйрь булу гына житми,
Депутат та булу кирәк,
Ике йөкне тарту өчен,
Эшчән ат та булу кирәк.
Моның өчен иң кимендә,
Илле яшьтә булу кирәк,
Җилле эштә булу кирәк
Һәм Илештә туу кирәк,
Һәм Казанга шуу кирәк,
Сөндә юу гына җитми,
Иделдә дә юу кирәк,
Моның өчен рухи яктан
Казанда да туу кирәк,
Миңнуллинны Уфада да,
Казанда да юу кирәк.

*1998*

# Ике балык

*(Әлегә мәсәл)*

Яшәгән, ди, олуг диңгездә
ике балык,
йөзгәннәр колач салып.
Куш булмасалар да,
дус булганнар
гүя туганнар,
уйнаганнар,
бер-берсен куганнар.
Берзаман
болар арасында
чын-чынлап көрәш башланып,
диңгез тарайган,
берсенең каласы килгән — Баш балык.
Шуны гына көткән Акула,
тыныч кына,
көрәштә откан:
көчсезләнгән бу икәүне
тоткан да йоткан.
Акула —
тук булган,
тегеләр — юк булган.
Ялгышырсың, бу әсәр
мәсәл генә, дисәң...
Бу балыклар —
әлегә исән...

*2001*

## Миннән шәфкать көтмәгез!

Үз өемдә йөрим арысландай,
Ә урамга чыксам — куян мин.
Әйтерсең лә йөзләп бүре куа,
Җәяүләсәм бик тә уяу мин.
Эте-бете чаба машинада,
Җәяү йөрүчегә — хәл авыр.
«Шөкер, бүген исән калдым» диеп,
Сөенә-сөенә кайтып барамын.
Өйдән чыксам, усал этләр өрә,
Бигрәк азындылар шул алар,
Инде бай хуҗалары белән бергә
«Мерседес»ка утырып куалар.
Рәхмәт сезгә, шофер әфәнделәр,
Әлегә мине мәрхүм итмисез.
Әллә Алла, әллә сез саклыйсыз,
Мине һаман таптап китмисез.
Мескен куян кебек качам сездән,
Ничә еллар инде кудыгыз,
Җиде катлы итеп сүгенүдә
Сез остазым минем булдыгыз.
Рульләрегез әллә минем өчен
Мәрхәмәтле, уңай боргычлы,
Шулай озын-озак яшәвемә
Мин бары тик сезгә бурычлы!
Рәхмәт инде сезгә, шофер дуслар,
Сез узганда — ГАИ йокласын,
Салып йөргән чакта — тотса тотсын,
Аек булган чакта тотмасын!
Кичерегез, шофер энекәшләр,
Ачу килеп каты бәрелсәм.
Һич үкенмәс идем тере-исән
Җир астына барып керәлсәм,
Метро дигәннәрен күрәлсәм.
Куян булып озак яши алмам,
Исән чакта әле, тередә
Мин үзем дә, ахры, әйләнермен
Сездән усалырак бүregә!
Тик беразга гына, зинһар өчен,
Күрми калып таптап китмәгез,
Инспектор булып эшкә керәм,
Миннән рәхим-шәфкать көтмәгез!

*2001*

## Остазлар һәм шәкертләр

Мин тормышта өйрәтүгә
Мохтаҗмын.
Шәкерте мин хөрмәтле өч
Остазның.
Мине эчәргә өйрәтте
Өч остаз.
Өлкәнәеп өчесе дә
Булды таз.
Бер читтәрәк торсын хәзер
Өч остаз:
Шәкертләргә — үзем остаз.
Үзем — таз...

*2002*

## Барып кайтыйк әле яшьлеккә...

Ал кулыңа, яшьтәш, тальяныңны,
Бер... егерме яшькә төшик тә,
Янда карчык юктан файдаланып,
Барып кайтыйк әле яшьлеккә!
Чыңлый-чыңлый ияртеп китсен безне
Тузмас гармуныңның җиз теле.
Картлык тынлыгында — без акыллы,
Яшьлек давылында — без тиле!
Бывший сөйгән ярлар елый-елый
Җырга кушылып озатып калсыннар,
«Калдырмагыз безне картлыкта!» дип,
Көй артыннан ияреп барсыннар.
Исеңдәме, яшьтәш, оныттыңмы,
Нишли идек әле яшь чакта?
Кунак кызын, билләреннән кочып,
Бер йоклатыйк әле кочакта.
Уйна әле яшь чактагы көйне!
Юк, монысы артык салмак көй.
Әти-әниләре куна киткән,
Көтеп тора безне аулагый!
Әллә төшә инде башыбызга
Аксыллыгы яуган карларның...
Безнең көйне басып, твист бии
Оныклары... сөйгән ярларның.
Сулар аккан, эссе җилләр искән,
Яшьлегебез монда башланган.
Ул эзләрне инде еллар күмгән,
Атлап барам салкын ташлардан.
Озын көйгә җырлыйм әкрен генә,
Биеп булмый, йөрәк тузган шул.
Тукта, дустым, бераз сулыш алыйк,
Яшьлегебез йөгереп узган шул!..
Безнекечә түгел кайгылар да,
Безнекечә түгел шатлык та...
Бу яшьлектә безне аңламыйлар.
Киттек, әйдә, кайтып картлыкка!
Үзләренә бик әйтмичә генә,
Кадерен белеп яшик карчыкның.
Үзенең шатлыкларын, үз көйләрен.

Үз яшьлеген табыйк картлыкның.
Картлык, картлык,
Юкка тиләләнмә,
Иплəп кенә үзеңә кайт атлап.
Яшьлек, яшьлек,
Күпме омтылсаң да,
Булмый икән сине кабатлап.
Гаҗәпләнмә күреп күзләремдә
Яшьләр түгел, кайнар таң чыгын...
Сау-исәнме, яшьлек мәхәббәтем,
Картлык мәхәббәтем — карчыгым!

*1999*

## Аумас һәйкәл

Танылган скульптор Эрнст Неизвестный аракыга һәйкәл салырга җыена.

Мондый хәбәрне ишеткәч,
Кем салмый кала ала?!
Ата-бала, кала-сала
Ниһаять, һәйкәл сала!
Неизвестный батырларча
Бөек эшкә алынган.
Аракыбыз болай да бит
Бар дөньяга танылган.
Соң булса да, чын Геройга
Борылдылар йөз белән.
Атакаларга күтәрде
Наркомски йөз грамм!
Эчкән солдат кыюлыгын
Онытмыйлар һич кенә.
Чигенмәде, егылса да,
Ауды дошман өстенә.
Анның Җиңүгә өлеше
Артык «Катюша»лардан.
Дошманнар куркып качкандыр
Тезелгән шешәләрдән.
Эчте аны һәрбер милләт:
Татары һәм урысы.
Ул — Рәсәй өчен сугышның
Генералиссимусы!
Батырлыкка ул әйдәде
Сугышларсыз чорда да,
Саф көмешкәгә әйләнде
Өйдә дә һәм кырда да.
Этилны Иделгә салып,
Казанда кайнатасың:
Көт Кабанның спирт булып,
Күктән пилмән явасын!
Этил суы ага торсын,
Егетләр ава торсын,
Су урнына эчә татар
Казанның аракысын.
Бу һәйкәлне күргән саен
Килеп торыр саласы.

Шәп сугышырга өйрәнер
Урамның һәр баласы!
Киләчәктә Россияне
Шул һәйкәлдән таныйрлар.
«Булган шундый бабайлар!» дип,
Шаккатып мактаныйрлар.
Салыйк шуның хөрмәтенә
Аягүрә, тураеп:
Без аусак та, һәйкәл аумас,
Булыр бердәнбер аек!

*2002*

## Алдау... бетте!

Бүгеннән соң алдануга,
Алдауга чик куелыр.
Алдакчы һәрбер авызга
Йозаклы бик куелыр!

Моннан ары юк ителер
Усал, явызлар көне,
Ябылып, гамәлдән чыгар
Ачык авызлар көне.

«Алдадым!» — диеп, сөенеп,
Инде беркем шатланмас,
«Алдандым...» — диеп, көенеп,
Елаулар кабатланмас.

Егетләр хәмер дигәннең
Тамчысын да капмаслар,
Кызлар кияүгә баргач ук
Йөгерешеп кайтмаслар.

Берәүне алдап, кәкере
Каенга терәтмәсләр,
Ыштраф түләмәгән өчен
Ыштраф түләтмәсләр.

Моннан соң беркем беркемне
Төп башына утыртмас,
«Ал пычкыңны, төп башын да
Кисеп ат!» — дип котыртмас.

Пенсияләр арткан саен,
Бәяләр төшә барыр,
Дәүләттән арткан акчалар
Кесәгә күчә барыр.

Моннан ары һәрбер адәм
Алдамый яшәп чыдар,
«Алдашуны бетерергә!»
Дигән Указ да чыгар.

Бүген, ниһаять, халыкның
Хәлләрен аңлау көне.
Рәхәтләнеп алдап калыйк,
Иң соңгы алдау көне!

## Бәдертдин гармун уйный

Таш урамда гармун уйный
Тили-тили... Бәдертдин.
Һәммәсе көлә аңардан:
«Тиле... тиле Бәдертдин!»
Бәдертдиннең кулларында
Тальянски гармуны,
Тили-тили генә түгел,—
Бәдертдиннең бар моңы!
Сезнеңчә ул тили-тили,
Бәдри уйнарга тели,
Бәдертдин уйнарга тели,
Ник тыңламыйсың, тиле!
Үзебезнең көй бит инде
«Уел» да, «Арча»быз да,
Тили-тили генә түгел,
Тыңлагыз барчагыз да!
Күрекләренә көч килә,
Гармунны да җәллә син,
Баламишкин бабаңнарны
Оныттыңмы әллә син?
Гармун уйнаучы егетнең
Исемнәре Бәдертдин,
Бәгырьләрем өзеләдер:
Көйләргә кадер бетте!
Бара Бәдри проспекттан:
«Киң урамнар тар иде,
Киң урамнарны тарайтып,
Йөргән чаклар бар иде!»
Туктый Бәдри: нигә болар
Йөрәкне аңламыйлар,
Авылдан чыккан адәмнәр
Авылны санламыйлар?
Оялталар Бәдертдинне
Акыллы киңәш биреп:
«Ташла авыл тальянкасын,
Йөрмә кеше көлдереп!»
— Акылдан шашкан!
— Хулиган!

— Тач бүре кебек улый!
Бәдри күз яшен яшереп,
Гармунын кочып елый,
Гармунын кочып елый да,
Җырларын тезә-тезә,
Китә тротуар буйлатып,
Күреген өзә-өзә:
«Гармункаем, уфтанасың,
Ташлар, дисеңме әллә?
Бәдертдиннең йөрәгендә
Ташлар, дисеңме әллә?
Әйт шуны!»

*1982*

## *Бәдертдин оркестры*

Безгә эләкмәгән иде, —
Болар уйнап карарлар.
Алып кайттым малайларга
Музыкальный товарлар:
Кыңгыраулы — саратский,
Кыңгыраусыз — вятский,
Тальян — итальянский,
Ә баян — советский...
«Монысы сиңа — саратский,
Монысы сиңа — полбаян».
Ни ишетәм:
— Их син, папа!..
— Нигә кирәк ул баян?
Үзем дә уйнап күрсәтәм:
— Тыңлагыз, көе менә!
(Әйләнеп тә карамыйлар
Музтовар өеменә.)
— Бу көйне безнең авылда
Менә шулай тарталар!
(Алар тәрәзәне ачып,
Магнитофон акырталар.)
Ә гармуннар-җаныкайлар —
Гел ятим калган сыман,
Утыралар моңаешып,
Үтмәгән товар сыман...
Бар икән ич бу дөньяда:
Безне санламаганнар,
Лично үземнең өйдә дә
Җанны аңламаганнар...
Әллә инде җырладым мин,
Әллә инде еладым,
Гармун моңына ияреп,
Кайтты яшьлек елларым...
Уйнаучысы да мин — үзем,
Җырлаучысы да —үзем,
Кул чабучы булмаса да,
Тыңлаучысы да — үзем.

Кулларымда — бишәр гармун:
Кадерен белми уллар,
Без кадерен белер идек —
Гармунсыз үтте еллар!
Алам гармунга кызыгып
Йөргән еллар үчен дә...
Уйныйм мине аңламаган
Малайларым өчен дә!
Гел моңаеп кына торма,
Җиффәр бию көйләрен:
Һоп! Бас! Әйдә! Әнә шулай!
Биет урам көйләрен!
Дөрес, Бәдертдин, син үзең
Фәйзи Биккинин түгел,
Әмма ярсып уйнаганда,
Биккининнан ким түгел!
...Малайларым көне буе
Магнитофон акырткannar,
Күршеләр милицияне
Өемә чакырткannar.
Әллә ярсып уйнавымның
Тәэсире тиеп китте,
Милиция минем көйгә
Үзе дә... биеп китте.
Балконга чыгып карасам:
Тамаша анда — халык!
Бәдертдиннең оркестрын
Тыңлыйлар хәйран калып.
Мин дә концертны тәмамлап,
Хөрмәтләп башны идем:
«Рәхмәт, балалар, җанымны
Аңлаган өчен!» — дидем.

*1981*

## Сафураның Бәдертдинне көтүе

Һай, җаным, минем толымнар
Озын, чем-кара иде,
Артымнан өч-дүрт Бәдертдин
Ияреп бара иде.
Һай, минем зифа буйларым
Нечкә иде талдан да,
Таллар да көнләшә иде
Иелеп су алганда.
Һай, зәһәр лә телең, дисез,
Татлы иде балдан да,
Тәмсезләнә иде бары
Бәдри үбеп алганда.
Кайнар кочакларда гына
Йөртерлек бәхет идем...
Вакытында өйгә кайтмый
Картайтты Бәдертдинем.
Бу күзләрем ямьсезләнде
Бәдрине көтә-көтә,
Татлы телем тәмсезләнде
Бәдрине тетә-тетә.
Кайтып кына керсен: иблис!
Кыяфәтсез... имансыз...
Көтәм... гомерем буе көтәм...
Яши алмыйм мин ансыз!

*1982*

## Бәдертдиннең Бәкердән Сафурага язган хаты

Синең белән озак яшәп бөкрәйгәч,
Бик ябыккач, син, Сафура, көрәйгәч,
Муен кызларга борылмый башлагач,
Караучы юк, дип, кырынмый башлагач,
Бу дөньяның рәхәтләре ычкынгач,
Кочаклагач, «Ай!» да «Вай!» дип кычкыргач,—
«Ай-вай!»лардан докторлар да туйдылар,
Санаторийга илттеләр дә куйдылар.
Истә әле: пычракка батып кайткач,
Битне юып, яныңа менеп яткач,
Куган идең: «Минем янга ятма!» — дип,—
Пычракка батсаң, өйгә кайтма!» — дип.
Бу юлы мин шәп пычракка очрадым,
Яраттым мин, карчык, Бәкер пычрагын.
Кая керсәң, кызлар каршы алалар,
Кап-кара брезент биләүгә салалар.
Бик теләсәң, култыклап та кертәләр,
Тирләмәсәң дә маңгай тирен сөртәләр.
Пычракларда уйга чумып ятасың,
Иплэп кенә кызларга күз атасың.
Массажистка арканы сөеп тора,
Санитарка бүлмәмдә биеп тора.
Бәдертдинне монда бик зурайттылар,
Гәүдәне дә шәм кебек турайттылар.
Бәдри хәзер һәр иртәне кырына,
Кая тели — муен шунда борыла.
Билем өчен, кырчык, котың очса да,
«Ай-һай!» димәм, йөз кыз килеп кысса да!
Гимнастика ясаганда кул... нитә...
Сизми кала... кызларга тиеп китә.
Әйткән идең: «Сиңа соң кем карасын!..»
Сизеп йөрим күп ханымнар карашын.
Истә һаман: «Янга ятма! — дигәнең,—
Пычракка батсаң, кайтма!» — дигәнең.
Телеграмм сук: синең янга кайтыйммы?
Әллә Бәкер пычрагында ятыйммы?

*1983*

## Бәдертдин туйда

Шушы ике тәлинкәне
Кияү белән киленгә,
Үзебездән артмаса да,
Туры килә бирергә.
Савыт-саба шалтырамый
Тормый, анысы, бездә дә...
Әмма алар, очып китеп,
Тими беребезгә дә.
Мин соңлап кайтсам, Сафура
Тәлинкәгә тотына:
Бәдертдин абзыегызның
Коты җитә ботына.
Ә Сафура тәлинкәне
Тота да миңа ата...
Ә мин нишлим? Уйлыйсыздыр:
Бәдри тәлинкә вата?
Юк, энекәш, тормыш бармый
Орып та ватып кына...
Тәлинкәне ипләп кенә,
Сөеп-яратып кына
Кире ыргытам... Уйлыйсыз:
Талаш и тартыш китә?
Юк!
Көлә-көлә, уйный-уйный,
Тәлинкә атыш китә...
Калганын сөйләп тә тормыйм:
Кочаклау-үбеш китә,
Сөенечне-кайгыларны
Урталай бүлеш китә.
Шуңа күрә өебездә
Әле Аллага шөкер,
Читләре дә кителмәгән,
Бөтен тәлинкә бөтен!
Тост әйтү иртәдер кияү
И килен өммәтенә,
Эчик моны Сафура һәм
Бәдертдин хөрмәтенә!
Гомумән дә, моннан соң да
Тәлинкә ватыш бетсен,
Килен кияүне нәкъ минем
Сафурам кебек көтсен!

*1981*

## Бәдертдин хәмерне ташлый

Эчми яшәү, ай-һай, авыр!
Әмма нәфесне тыям.
Юк! Юк! Тәүбә! Кыстамагыз!
«Волга»га акча җыям!
Моңсу гына карап узам
Вино кибетләреннән,
Өмет өзеп, кул селтәгез
Инде, егетләр, миннән!
Получканы тулысынча
Өйгә кайтарып куям —
Сафураның үз кулына.
«Волга»га акча җыям!
Эштән чыгам. Сизеп торам:
Шешәдәшләр көтәләр.
Өч борынга керә-керә,
Эштән чыгып бетәләр.
Уңга-сулга карамыйча,
Бәдертдин оча гына
Сафураның сагынылган
Җып-җылы кочагына!
Эштә — тәртип, өйдә — тыныч,
Сафура да канәгать:
Гомеремдә тәүге тапкыр
Гашыйк булды, җәмәгать!
Иске дуслар, мәсьәләне,
Давай, без болай куйыйк:
Ирләр һәммәбез җыелып,
«Волга»га акча җыйыйк!
Аракы, коньяк, винолар
Алучыларны көтсен,
Айлар көтсен, еллар көтсен,
Тәмам саргаеп бетсен!
Айныткычлар иң актыккы
Клиентны сагынсыннар,
Исерүләрен үтенеп,
Ирләргә ялынсыннар.
Шәраб-хәмер сатучылар
Эшсез торып калсыннар,
«Пажалста, эч инде...» — дип,
Артыбыздан барсыннар.

Хатыннар: «Чара күр!» — диеп,
Начальникка китсеннәр,
«Ирем эчми...» — дип кайгырып,
Ябыгышып бетсеннәр.
Милиционерлар һәр аекка
Бик зур штраф салсыннар,
Җыелышып, өч борынга
Ярты... кефир салсыннар.
Тик бер исерекне эзләп,
Эзтабарлар чапсыннар,
«Кызыл китап»ка кертергә
Рәсемен генә тапсыннар.
«Волга»ны сатып алыйк та,
Аннары карап карыйк,
Уңга-сулга авышмыйча,
Туп-туры алга барыйк!
ГАИлар карап калсыннар
Кайгырып, яныпкөеп:
Каһәр суккыры Бәдертдин
Эшсез калдырды, диеп...

*1981*

## Чемпион Бәдертдин

Гарык булдым Сафурадан,
Эт итеп тирги, малай,
Кызган табага бастыра,
Кисә дә иги, малай.
«Уңмадым мин син җүнсездән...
Башкаларның ирләре
Эчми, тартмый, акча суга,
Юк килмәгән җирләре!
Буш вакытын спорт белән
Шөгыльләнеп үткәрә,
Йә шпион, йә чемпион,
Йә штанга күтәрә...»
«Булды, мәйтәм, бәхилләшәм
Хәмер и спирт белән,
Дуслык шартнамәсе төзим,
Ниһаять, спорт белән!»
Әйтте Сафура: «Бәдертдин,
Тыңла, карышма гына,
Мин дә карарга килермен
Спорт ярышларына».
Эштән чыгып, штанганы
Күтәрергә барышым!
Күпме, нәрсә күтәргәнмен,
Хәтерләмим анысын...
Кыскасы, җәйге иртәдә
Айныткычта уяндым.
Чалбар, күлмәк юкка чыккан...
Үз-үземнән оялдым.
Урамнан ничек кайтырга?
Башымны кашып торам.
Кыска ыштан белән генә
Идәндә басып торам.
Килде махмырлы башыма
Гениальный бер фикер:
«Син бит спортчы, Бәдертдин,
Чап, йөгер, атла, сикер!»
Исәп-хисапны өздем дә
Йөгерә-атлый киттем,
Марафон адымы белән
Урамнар буйлап киттем.

Атлый-атлый, чаба-чаба,
Баштан да спирт чыга.
Хөрмәт белән юл бирәләр
Бәдертдин спортчыга.
Бу ни бу? Берни аңламыйм.
Минем кебекләр арткан...
Марафон адымы белән
Киләләр минем арттан.
Болар да минем шикелле
Айныткычтан кайтамы?
Алай дисәң, «Спорт» дигән
Майка кигән байтагы.
Кем уйлаган ирешермен дип
Шундый да зур уңышка:
Иң беренче килгәнмен ич
Йөгерүдә финишка!
Сайлап алдым спортның да
Иң авыр, иң кыенын.
Сафура үбә, кочаклый:
«Бәдертдин... чемпионым!..»

*1996*

# *Илдар Юзеев*

*(Биографик белешмә)*

Шагыйрь һәм драматург Илдар Гафур улы Юзеев 1933 елның 3 гыйнварында Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында укытучы гаиләсендә туган. Шунда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1950—1954 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала. Хезмәт юлын журналистикадан башлый: 1954—1966 елларда «Пионер» (хәзерге «Ялкын») республика балалар журналында җаваплы секретарь, аннары бер ел «Чаян» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1967—1971 елларда — Татарстан язучылар берлегенең әдәби консультанты. 1972—1973 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлап кайткач, өч ел — «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөдире. 1977—1987 елларда Татарстан Язучылар берлегендә яшь авторлар белән эшләү бүлеге мөдире — идарә рәисе урынбасары вазифасын башкара.

1968 елдан бирле Татарстан, 1979 елдан РСФСР язучылары берлеге идарәсе әгъзасы булып тора. Ул шулай ук 1976—1983 елларда Азия һәм Африка илләре язучылары белән багланыш буенча Совет комитеты әгъзасы эшләрен башкара. СССР язучыларының VII нче (1981), VIII нче (1986) съездларында катнаша.

Төрле елларда Татарстан язучылар берлегенең шагыйрьләр остаханәсен җитәкли.

Поэмалары һәм балладалары өчен ул, шагыйрьләрдән беренче буларак, 1968 елда Татарстанның Муса Җәлил исемендәге, ә 1960 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләкләренә лаек була.

И.Юзеевның драма әсәрләре татар сәхнәсендә генә түгел, башка милли театр сәхнәләрендә дә куелды. Әдәбият һәм театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, аңа 1979 елда Татарстанның, ә 1983 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән исем бирелде.

Әдәбиятны үстерүдәге хезмәтләре өчен СССР Верховный Советының Указы нигезендә 1986 елда «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә 1993 елда Татарстанның халык шагыйре дигән исем бирелде.

## Эчтәлек


Алгы сафтагы шагыйрь. *Хәсән Туфан* . . . . . . . . . . . . . . 7
Янар чәчәкләрнең яктысы. *Сибгат Хәким* . . . . . . . . . . 8
Драматургиядә дә шагыйрь. *Азат Әхмәдуллин* . . . . . . . . 9
Яшьлекләрнең яшьтәше. *Зөлфәт* . . . . . . . . . . . . . . . . . 10

I

Җырлар бирәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Җырлап уздым урман арасын . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Ә син... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Сәйдәш урамында уйлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Авторучка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Һаман көтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Кайтмый... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
«Җилфердәтеп ефәк яулыгыңны...» . . . . . . . . . . . . . . 22
«Сөйгәнеңнең күзе нинди?..» . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
«Бер яшь миләш үсә иде...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Егет күңеле далада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
«Буран...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Авылым легендасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Тып-тын иртә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Васыятен эзлим Кәримнең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
«Ялтага бар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
«Җитмеш яшьлек Заһидулла абзый...» . . . . . . . . . . . . 35
Ертылган рәсем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Светлана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
«Сандугачлар сайраталар иде...» . . . . . . . . . . . . . . . 38
«Күңелем минем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Илһам килгәндә һәм киткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Мин сине нигә яратам? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
«Һәрнәрсәгә карыйм исем китеп...» . . . . . . . . . . . . . . 42
«Әйтегез...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Табыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Юк, мин яши алмыйм алай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Борчылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Уфтану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Шом . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
«Мәхәббәт, нишләттең син мине?..» . . . . . . . . . . . . . . 49
Ни ясар тимерче? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Бер сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
«Шушы урамнардан атлап киттем...» . . . . . . . . . . . . . 52
Бәрәңге чәчәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
«Аннан бирле күпме...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
«Хушыгыз...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
«Балалыкка кире кайтыйм әле...» . . . . . . . . . . . . . . . 56
«Иптәшләре шелтә бирделәр дә...» . . . . . . . . . . . . . . 57
«Үз-үзеңне эзләп...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Канкай углы Бәхтияр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
«Үз дәрәҗәсен...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Калдыр, аккош, каурыеңны... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

Шагыйрь Мөхәммәдьяр . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Шагыйрьләр нигә картаймый? . . . . . . . . . . . . . 65
«Атлап киләм...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Гармунсыз авыл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
«Акчарлакның туган җире...» . . . . . . . . . . . . . 69
«Күнеккәнбез...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
«Икеләнми киттек...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Унөченче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Бакчачы турында баллада . . . . . . . . . . . . . . . 74
Моң турында баллада . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Ай сонатасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
«Мәхәббәтнең кире кайтмас...» . . . . . . . . . . . 82
«Әй, Кеше, кайларга юл тоттың?..» . . . . . . . . . 83
«Өзелмә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
«Хуш, бәхил бул...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Нишләдем?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
«Гаиләдә төпчек бала...» . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Суга баткан бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Әнисез нигез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
«Кара диңгез суларының...» . . . . . . . . . . . . . . 90
И туган як... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Калмадыммы?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Тамсын ул ... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Кыска шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Бул! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Шигъриятнең хәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Такташым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Хәсән Туфан фатихасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
«Сине эзлим һаман...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Киттек, Сибгат абый! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Югалмаган дуска . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Юлдашым, тукта... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Асфальт юлдан ат бара . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Нихәл, күрше!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Аксакаллар мәҗлесендә булдым . . . . . . . . . . . 114
Үзгәрүчеләргә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Төннәр кебек зәңгәр сагышларым . . . . . . . . . 116
Табыйк шундый бер җыр! . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Бер җырладым... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Табигать туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Тау ягы гүзәле Әлфинур . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Бер кочак җылы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Тормыш ул — серле бер могҗиза . . . . . . . . . . 122
Су астында калган гүзәллек . . . . . . . . . . . . . . 123
Челтери дә чыга... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Сезгә мин ни әйтим? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125

«Көтмәдем...» . . . 126
Килеп сөялдең каенга . . . 127
Әнкәйгә бишек җыры . . . 128
«Юк инде гамьсез шаяру...» . . . 130
Болытлар артында Кояш бар! . . . 131
Ян, күңел! . . . 132
Уйныйк әле быргыларны... . . . 133
Кәҗә белән Сарык елында әйтелгән тост . . . 134
«Астрономнар ничә еллар инде...» . . . 136
«Әллә нигә йөрәк яна...» . . . 137
Хәтерләү . . . 138
«Тауның ташын алып китим мәллә?» . . . 139
Шигырь көе . . . 140
«Татарча туабыз...» . . . 141
Йөрәге сызлаган дустыма . . . 142
Аккан сулар, искән җилләр... . . . 143
Аксакал нәсыйхәте . . . 144
«Ап-ак карга ятып...» . . . 145
«Тормышыңны матурлаган...» . . . 146
Без . . . 147
Өлкәнәйгән бер хис . . . 148
«Аңа хәзер берни кирәк түгел...» . . . 149
Уйлыйсыздыр . . . 150
«Ычкынырмын, ахры...» . . . 151
Кошлар юлы . . . 152
Хәсрәтле җыр . . . 153
Кайчагында . . . 154
«Тормыш бит ул...» . . . 155
Акланма, шагыйрь... . . . 156
Мин нигә гафил булдым? . . . 157
Ул үткән юллар . . . 158
«Безме? Без — ул...» . . . 159
«Ник тыйнаклык?..» . . . 160
Кайда минем утлы төннәрем?.. . . . 161
«Шатлыкларым чиксез...» . . . 162
Сораулар . . . 163
Яңавыл этәче . . . 164
Куларбамны тартып узган чакта . . . 165
Янган чәчәк . . . 166
«Җир йөзендә тәүге тапкыр...» . . . 168
«Кагылма, зинһар...» . . . 169
«Мин фәрештә түгел...» . . . 170
Җан юлдашым . . . 171
Читләрнең үз бәясе . . . 172
«Мин гашыйкмын...» . . . 173
«Минем юаш табигатем...» . . . 174

Оялдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
«Бәла-каза...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
«Нишлисең бит...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
«Мәҗлестән соң...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
«Хакыйкатьне тулы ачалмыйча...» . . . . . . . . . . . . . 179
«Беркатлы дип уйламагыз...» . . . . . . . . . . . . . . . 180
«Хәерче, гарип-гораба...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
«Бала чагымда очындым...» . . . . . . . . . . . . . . . . 182
«Таныш, үземнең җырымны...» . . . . . . . . . . . . . . 183
Китү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
«Мине дошман күргән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
«Кайтып килә Кояш баешыннан...» . . . . . . . . . . . . 186
«Чыгармыйм күз яшьләрен мин...» . . . . . . . . . . . . 187
«Авырлыклар тулы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Кешене иярткән этләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Бурлаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
«Олы җанлы шагыйрь-әдипләргә...» . . . . . . . . . . . 191
«Әзерлиләр заман давылының...» . . . . . . . . . . . . 192
«Ул даһины...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 193
Үзгәрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Сагышлы мирас . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
«Указлы шагыйрь булганчы...» . . . . . . . . . . . . . . 196
«Үз теләгем белән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
«Әллә инде Күктән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
«Искитәрлек булмаса да...» . . . . . . . . . . . . . . . 199
Иярләштек... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200
«Озын төннәр йокламадың...» . . . . . . . . . . . . . . 201
Илһамга ничә яшь? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Без . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203
Сөембикә манарасы янында . . . . . . . . . . . . . . . . 204
«Барабыз вагон эчендә...» . . . . . . . . . . . . . . . . 205
Соңгы гармун . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Татар шагыйрьләренә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
Абыйларсыз калган юлларда . . . . . . . . . . . . . . . 212
«Хәтеремдә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Таулар күкрәгеннән чыккан җыр . . . . . . . . . . . . . 214
Гомерләрең уза, былбылкаем... . . . . . . . . . . . . . . 215
«Өй алдында үскән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
Гасыр кичкән чакта... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
Кайраучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 218
«Әллә безнең өчен...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
«Берүзем җиде төн уртасында...» . . . . . . . . . . . . . 220
Китәм, диден... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
Август чәчәкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Язлар килә монда иртәрәк . . . . . . . . . . . . . . . . 223
«Рәсемеңне ясыйм...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224

Урта Кирмән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
Тагын бер дәрәҗә тактылар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226
Сагынырбыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
Күктән — югарыдан караганда . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Күктәге рәсемнәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
Гөлләр сорасалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Илһамсыз чакларда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
Киләчәк кызына хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
Бу базарда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
«Ике йөз елдан соң... инкыйраз...» . . . . . . . . . . . . . . 236
«Чәчләр агарды дип...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
«Шәһәр топольләре...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
Кая ашыгасың, дөнья? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
Мин югалсам... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Җәйге таңда уяну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
Әҗәл... үлгән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
Ниләр көйли Казансу? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244
Юк, ашыкма, Тарих... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 245
Идел ярларыннан карап торам . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Атнабайның туган көнендә укылган шигырь . . . . . . . . . 247
Татар бугазында — циклон... . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
Базар эчендә — баянчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 249
Мин дә шул илдән... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Унҗиде яшьлек карт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Калыйм... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Чоңгылларга таба... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 253
Йолдызлы бер төндә уйлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
Гасыр чигендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 257
Тимер бишектә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
Казан ятимнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 259
Авылыма кайттым... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 261
«Карап торасың син...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 262
Иркәләр дә, сылулар да бетмәс... . . . . . . . . . . . . . . . 263
Ямады . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
Юлбарыс һәм без . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 266
Су буенда су эзлим... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 267
Хыянәт төне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268

## II

Озак яшисегез килсә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
Төнбоек. *Л. Айтуганов музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . 276
Сине уйлап янам. *С. Ибраһимов музыкасы* . . . . . . . . . 277
Яшьлек дустыма. *М. Яруллин музыкасы* . . . . . . . . . . 278
Зөфәр җыры. *Ш. Мәҗитов музыкасы* . . . . . . . . . . . . 279
Резидә җыры. *Ш. Мәҗитов музыкасы* . . . . . . . . . . . . 280
Яшь наратлар. *Җ. Фәйзи музыкасы* . . . . . . . . . . . . . 281

Фәүзия җыры. *М. Яруллин музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . 282
Кайтам инде. *С. Садыйкова музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . 283
Ике малай китә армиягә. *Ә. Даутов музыкасы* . . . . . . . . 284
Шофер. *Ш. Мәҗитов музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 285
Бөркет турында җыр. *С. Садыйкова музыкасы* . . . . . . . . . 286
Унике аккош. *Р. Яхин музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
Серле чәчәк. *М. Яруллин музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . . 288
Каршы ал, туган калам! *Л. Хәйретдинова музыкасы* . . . . . . 289
Балачак чишмәсе. *Р. Абдуллин музыкасы* . . . . . . . . . . . . 290
Таң кызы җыры. *М. Яруллин музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . 292
Туган ягым каеннары. *М. Имашев музыкасы* . . . . . . . . . . 293
Чит илләргә чыксаң... *С. Садыйкова музыкасы* . . . . . . . . . 294
Ерактагы үзәннәр. *З. Хәбибуллин музыкасы* . . . . . . . . . . 295
Гашыйклар тавында. *М. Имашев музыкасы* . . . . . . . . . . . 296
Яралы кош. *М. Имашев музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . . . 297
Җиләккә дип барган идем... *В. Әхмәтшин музыкасы* . . . . . . 298
Онытма мине. *И. Сафин музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . . . 299
Яшьлек узган сукмакларым. *И. Мәҗитов музыкасы* . . . . . . 300
Тузганак. *Р. Абдуллин музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 301
Сөйгәнемнең туган көне. *Ф. Әхмәтов музыкасы* . . . . . . . . 302
Әллә күрешәбез, әллә юк... *Г. Сәйфуллин музыкасы* . . . . . . 303
Балачак хыяллары. *Ф. Әхмәтов музыкасы* . . . . . . . . . . . . 304
Әнкәемнең туган ягында. *Ф. Мортазин музыкасы* . . . . . . . . 305
Кыр казлары артыннан. *М. Имашев музыкасы* . . . . . . . . . 306
Мәтрүшкәләр. *А. Гыйләҗев музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . 307
Хуш инде. *Ф. Мортазин* музыкасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 308
Утыраек әле чак кына... *Р. Хәким музыкасы* . . . . . . . . . . 309
Син мине бәхетсез итмәдең. *Р. Хәким музыкасы* . . . . . . . . 310
Гази батыр турында баллада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 311
Моңлы бала. *Ә. Шәрәфиев музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . 312
Юлчы чишмәсе. *Ә. Шәрәфиев музыкасы* . . . . . . . . . . . . . 313
Кайттым, әнкәй... *Р. Әхиярова музыкасы* . . . . . . . . . . . . . 314
Кырларда туган җырым. *С. Шәмсина музыкасы* . . . . . . . . 315
Шаян картлар җыры. *З. Гыйбадуллин музыкасы* . . . . . . . . 316
Мин телим дусларга. *Ф. Галимов музыкасы* . . . . . . . . . . . 317
Өзелмәс җыр. *Р. Әхиярова музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . 318
Каен җиле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 319
Ялгышасыз. *Р. Ханнанов музыкасы* . . . . . . . . . . . . . . . . 320

**III**

Туган көндә туган шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 323
Кар кешесе кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 325
Күл кешесе кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328
Минем хәлне нигә аңламыйлар? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 335
Безнекеләр! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 337
Котыпка киткән егетләргә хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 338
Минем көнем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 339

Тел остасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340
Шайтанны сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 341
Сөйгән ярлар, гаеп итмәгез... . . . . . . . . . . . . . . . . 342
Егетләрнең кызларга киңәше . . . . . . . . . . . . . . . . 343
Кияүгә чыгучы кызларга киңәш . . . . . . . . . . . . . . 344
Көнләшәм... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 345
Банкир белән Мөнкир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 346
Куян елында бүре хәлләре... . . . . . . . . . . . . . . . . 347
Их, бар иде... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 348
Хәмруллин маҗаралары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 349
Жалюзи . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 350
Базарда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 351
Өч иптәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 352
Татар кешесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 353
Ничек бүләек? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 354
Шагыйрь булу гына җитми... . . . . . . . . . . . . . . . . 355
Ике балык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 356
Миннән шәфкать көтмәгез! . . . . . . . . . . . . . . . . . 357
Остазлар һәм шәкертләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 358
Барып кайтыйк әле яшьлеккә... . . . . . . . . . . . . . . 359
Аумас һәйкәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 361
Алдау... бетте! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 363
Бәдертдин гармун уйный . . . . . . . . . . . . . . . . . . 365
Бәдертдин оркестры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 367
Сафураның Бәдертдинне көтүе . . . . . . . . . . . . . . 369
Бәдертдиннең Бәкердән Сафурага язган хаты . . . . . . . . . 370
Бәдертдин туйда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 371
Бәдертдин хәмерне ташлый . . . . . . . . . . . . . . . . . 372
Чемпион Бәдертдин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 374

Литературно-художественное издание

Ильдар Юзеев

*(Юзеев Ильдар Гафурович)*

**Избранные произведения
в пяти томах**

**Том 1**

*(на татарском языке)*

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 17.10.2002. Форматы 84×108 1/32.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 20,16+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 20,48.
Нәшер-хисап табагы 13,40+форз.0,36. Тиражы 3000.
Заказ Б-547.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур.,2.